МАРСЕЛЬ ӘХМӘТҖАНОВ

# XVII–XVIII ГАСЫР ТАТАР ТАШБИЛГЕЛӘРЕ

КАЗАН – 2011

ББК 63.3(2Рос=Тат)
Ә 86

***Әхмәтҗанов М.И.***
**XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре.** – Казан, 2011. – 260 б.

© Әхмәтҗанов М.И., 2011

# ЭЧТӘЛЕК


**Кереш сүз** ..... 8

**Беренче бүлек**
**XVII гасыр Касыйм шәһәрендәге Иске Бистә зиратында табылган татар ташбилгеләре текстлары**

Кереш ..... 19
№ 1 Касыйм шәһәренең Иске Бистә зиратыннан табылган ташбилге ..... 23
№ 2 Икенче ташбилге тексты ..... 24
№ 3 Өченче ташбилге тексты ..... 25
№ 4 Дүртенче ташбилге тексты ..... 26
№ 5 Касыйм шәһәре Иске Бистә зиратында сакланган бишенче таш тексты ..... 27
№ 6 Касыйм шәһәре Иске Бистә зиратында сакланган алтынчы таш тексты ..... 28
№ 7 Касыйм шәһәре Иске Бистә татар зиратыннан алынган җиденче таш тексты ..... 29
№ 8 Касыйм шәһәренең Иске Бистә зиратындагы Әфган хан дөрбәсендәге эпитафик язма ..... 30
№ 9 Касыйм шәһәре Иске Бистәдәге Әфган хан дөрбәсендәге ташбилгеләр ..... 31
№ 10 Дөрбә эчендәге икенче таш – Түкә солтан ташбилгесе ..... 34
№ 11 Ай ханым эпитафик язмаларының профессор Корш укыган тексты ..... 36

**Икенче бүлек**
**Чуаш республикасы төбәкләрендә сакланган XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре текстлары**

Кереш ..... 30
№ 1 Урмар төбәге Биш авылы ташбилгесе тексты ..... 40
№ 2 Шемурша төбәге Турун ташбилгесе тексты ..... 40
№ 3 Ямаш авылы ташбилгесе тексты ..... 41
№ 4 Урмар авылында сакланган беренче ташбилге тексты ..... 42
№ 5 Урмар авылында сакланган икенче ташбилге ..... 42
№ 6 Урмар авылында сакланган өченче ташбилге ..... 42
№ 7 Урмар авылында табылган дүртенче ташбилге ..... 42
№ 8 Канаш төбәге Шигали авылы ташбилгесе тексты ..... 43
№ 9 Канаш төбәге Шигали авылы ташбилгесе тексты ..... 43
№ 10 Ямаш авылында табылган ташбилге тексты ..... 44
№ 11 Масловка авылы ташбилгесе тексты ..... 45
№ 12 Урмар төбәге Кавал авылында табылган беренче ташбилге тексты ..... 45
№ 13 Козловка төбәге Масловка авылы (беренче) ташбилгесе тексты ..... 46
№ 14 Урмар төбәге Кавал авылында сакланган икенче ташбилге ..... 47
№ 15 Кавал авылында табылган өченче ташбилге ..... 47
№ 16 Масловка авылында табылган икенче ташбилге ..... 47
№ 17 Масловка авылында табылган өченче ташбилге ..... 48
№ 18 Яльчик төбәге Байгылыч авылы ташы ..... 48

**Өченче бүлек**
**Татарстан Республикасы Казан регионы, XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре текстлары**

Кереш ..... 49
№ 1 Әтнә төбәге Иске Өҗем авылы ташбилгесе тексты ..... 52

№ 2 Татарстан Республикасы Яшел Үзән төбәге Татар Танае авылы ташбилгесе .. 53
№ 3 Арча төбәге Түбән Мәтәскә авылы ташбилгесе ..................................... 53
№ 4 Арча төбәге Кадрәк авылының беренче ташбилгесе тексты ....................... 54
№ 5 Әтнә төбәге, Иске Кишет авылыннан алынган ташбилге тексты ................... 55
№ 6 Яшел Үзән төбәге Норлат авылы ташбилгесе тексты ................................ 56
№ 7 Лаеш төбәге Имәнкискә авылында сакланган XVII йөз ташбилгесе тексты .... 57
№ 8 Яшел Үзән төбәге Олы Шырдан авылы, № 2нче ташбилге тексты ................. 58
№ 9 Саба төбәге Олы Нырты авылы зиратыннан ............................................ 59
№ 10 Мамадыш төбәге Дусай авылындагы әүлия ташы язмасы тексты ................. 60
№ 11 Теләче төбәге Максабаш авылы ташбилгесе тексты ................................ 61
№ 12 Кукмара төбәге Өлги авылында сакланган ташбилге тексты ...................... 62
№ 13 Питрәч төбәге Тау Иле авылы зиратыннан алынган ташбилге тексты ........... 63
№ 14 Арча төбәге Кәче Иле авылы зираты ташбилгесе тексты .......................... 64
№ 15 Олы Мәнгәр авылы иле ташбилгесе тексты ............................................ 65
№ 16 Арча төбәге ташы ............................................................................ 66
№ 17 Яшел Үзән төбәге Олы Шырдан авылы зираты ...................................... 67
№ 18 Биектау төбәге, Туктамыш авылы зираты ташбилгесе тексты ................... 68
№ 19 Мамадыш төбәге Олыяз авылы янында саклanучы борынга
ташбилгесе тексты ................................................................................ 69
№ 20 Кайдан табылуы турында мәгълүм булмаган XVIII йөз татар
ташбилгесе тексты ................................................................................ 70
№ 21 Биектау төбәге Ташлы Кавал авылы уртасында, юл кырыендагы
ташбилге тексты ................................................................................... 71
№ 22 Питрәч төбәге Чыты авылы ташбилгесе тексты ..................................... 72
№ 23 Яшел Үзән төбәге Бакырчы (Әрә Бакырчысы) авылы
ташбилгесе тексты. Беренче таш .............................................................. 73
№ 24 Бакырчы (Әрә Бакырчысы) авылы. Икенче ташбилге тексты ..................... 73
№ 25 Яшел Үзән төбәге, Норлат авылы зираты ташбилгесе тексты ................... 74
№ 26 Биектау төбәге Сая авылы ................................................................ 75
№ 27 Биектау төбәге Өлә-Казаклар авылындагы беренче ташбилгенең тексты ...... 76
№ 28 Биектау төбәге Өлә-Казаклар авылы зиратыннан икенче
ташбилгенең тексты .............................................................................. 78
№ 29 Яшел Үзән төбәге Мулла Иле зираты ташбилгесе .................................. 80
№ 30 Әтнә төбәге Югары Бәрәскә авылы зиратындагы дөрбә эчендәге
ташбилге тексты ................................................................................... 81
№ 31 Малмыж төбәге, Яңа Смәил авылы зираты ташбилгесе тексты ................. 83

**<u>Дүртенче бүлек</u>**

**Минзәлә регионы XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре текстлары**

Кереш .................................................................................................. 84
№ 1 Минзәлә төбәге, Бикбау авылы иске зиратындагы беренче ташбилге тексты . 86
№ 2 Әгерже төбәге, Салагыш авылы «Әүлия ташы» ташбилге тексты .................. 87
№ 3 Минзәлә төбәге, Гөлек авылы «Изгеләр зираты» ташбилге тексты ............... 89
№ 4 Менделеев төбәге, Песәй авылы зираты ташбилгесе тексты ....................... 90
№ 5 Мөслим төбәге, Катмыш авылы янындагы иске зират,
беренче ташбилге тексты ....................................................................... 93

№ 6 Катмыш зираты, икенче ташбилге тексты ... 93
№ 7 Мөслим төбәге, Катмыш зиратындагы өченче ташбилге ... 94
№ 8 Мөслим төбәге, Катмыш зиратындагы дүртенче ташбилге ... 94
№ 9 Менделеев төбәге, Турай авылы зираты (беренче) ташбилгесе тексты ... 94
№ 10 Менделеев төбәге, Турай авылы зиратындагы икенче борынгы ташбилге тексты ... 96
№ 11 Катмыш зираты, бишенче ташбилге тексты ... 97
№ 12 Алабуга төбәге, Иске Юраш авылы ташбилгесе тексты ... 98
№ 13 Катмыш зираты, алтынчы ташбилге тексты ... 99
№ 14 Әгерҗе төбәге, Иске Эсләк ташбилгесе тексты ... 100
№ 15 Әгерҗе төбәге, Ырыс авылы зиратындагы XVII гасыр ташбилге тексты ... 101
№ 16 Катмыш зираты, җиденче ташбилге тексты ... 103
№ 17 Катмыш зираты, сигезенче ташбилге тексты ... 103
№ 18 Актаныш төбәге, Әҗәкүл авылы зиратындагы ташбилге ... 104
№ 19 Минзәлә төбәге, Гөлек авылы «Изгеләр зираты» ташбилге тексты ... 105
№ 20 Әгерҗе төбәге, Салагыш авылы эчендәге зираттагы ташбилге тексты ... 106
№ 21 Катмыш зираты, тугызынчы ташбилге тексты ... 108
№ 22 Минзәлә төбәге, Бикбау авылы кырындагы икенче ташбилге тексты ... 108
№ 23 Менделеев төбәге, Бәзәкә авылы кырындагы XVII гасыр ташбилгесе тексты ... 109
№ 24 Әгерҗе төбәге, Наҗар авылы ташбилгесе тексты ... 111
№ 25 Әгерҗе төбәге Кодаш авылы ташбилгесе тексты ... 112
№ 26 Менделеев төбәге Туйгуҗа авылындагы борынгы эпитафия тексты ... 113
№ 27 Менделеев төбәге, Татар Әхтиялы авылы ташбилгесе тексты ... 115
№ 28 Әгерҗе төбәге, Яңа Акгуҗа авылы зиратындагы ташбилге тексты ... 115
№ 29 Әгерҗе төбәге, Иж Бәйки авылы янындагы иске зират ташы фрагменты (әүлия ташы) тексты ... 116
№ 30 Мөслим төбәге, Катмыш зираты ташбилгеләре Унынчы ташбилге ... 116
№ 31 Катмыш зираты, унберенче ташбилге ... 117
№ 32 Катмыш зираты, уникенче ташбилге ... 117
№ 33 Катмыш зираты, унөченче ташбилге тексты ... 117
№ 34 Катмыш зираты, ундүртенче ташбилге ... 118
№ 35 Әгерҗе төбәге, Көчек авылы зиратындагы борынгы ташбилге ... 118
№ 36 Катмыш зираты, унбишенче ташбилге тексты ... 118
№ 37 Әлмәт төбәге, Габдерахман авылы зираты ташбилгесе ... 119
№ 38 Азнакай төбәге, Чалпы авылының иске урнында табылган ташбилге тексты ... 120
№ 39 Азнакай төбәге, Митрәй зиратыннан беренче ташбилге тексты ... 121
№ 40 Азнакай төбәге, Митрәй авылы зираты икенче ташбилге тексты ... 122
№ 41 Ютазы төбәге, Бәйрәкә авылы иске зираты ташбилгесе тексты ... 123
№ 42 Әлмәт төбәге, Колшәрип авылы ташбилгесе тексты ... 124
№ 43 Азнакай төбәге, Сарлы авылы борынгы ташбилгесе тексты ... 125
№ 44 Әлмәт төбәге, Клементейкино авылы иске зиратындагы ташбилге тексты ... 126
№ 45 Азнакай төбәге, Әсәй авылы иске зираты Чәүкә төбәге кабер ташбилгесе тексты ... 127

№ 46 Әлмәт төбәге, Кама Исмәгыйль авылы ташбилгесе ........................................ 128
№ 47 Азнакай төбәге, Чалпы авылы иске зиратындагы ташбилге тексты ............. 128
№ 48 Әлмәт төбәге, Габдерахман авылы зираты ташбилгесе .................................. 129

## Бишенче бүлек
## Урта Урал һәм Көнбатыш Себердәге татарларда XVII–XVIII гасырдагы ташбилгеләрнең текстлары

Кереш ........................................................................................................................ 130
№ 1 Благовар төбәге,Төркәй авылы татар зираты ташбилге тексты ....................... 132
№ 2 Йөрүзән елгасы тамагы ярында булган иске зират ташбилгесе тексты .......... 132
№ 3 Аскын төбәге, Кыйгазы авылы иске зиратындагы беренче ташбилге тексты 133
№ 4 Чишмә төбәге, Түбән Тирмә ташбилгесе тексты ............................................. 134
№ 5 Чишмә станциясе янындагы борынгы татар зираты ташбилгесе тексты ........ 135
№ 6 Чишмә станциясе кырыендагы татар зиратыннан икенче ташбилге тексты .. 136
№ 7 Чишмә станциясе зиратындагы өченче ташбилгенең тексты ......................... 137
№ 8 Чишмә станциясе янындагы татар зиратындагы дүртенче ташбилге тексты . 137
№ 9 Чишмә станциясе иске зиратындагы Амангилде углы Шалтыйк байның ташбилгесе тексты ........................................................................................................ 138
№ 10 Чишмә станциясе иске зиратындагы Мөхәммәдкол углы Йамаш байның ташбилгесе тексты ................................................................... 139
№ 11 Чишмә станциясе янындагы иске зираттагы Йамаш углы Нуркәй батырның кабер ташы (1695/1696) тексты ........................................ 140
№ 12 Чишмә төбәге Чишмә стациясе янындагы зират ташы тексты ...................... 141
№ 13 Чишмә станциясе янындагы зират ташбилгесе тексты .................................. 142
№ 14 Чишмә станциясе янындагы иске зират ташбилгесе тексты .......................... 143
№ 15 Кушнаренко төбәге, Мәүлет авылы зираты ташбилгесе тексты .................... 144
№ 16 Чишмә станциясе янындагы татар зираты ташбилгесе тексты ...................... 145
№ 17 Чишмә станциясе кырында иске татар зиратында сакланган Тиләкәй Акчура углы кабер ташы тексты ...................................................... 146
№ 18 Чакмагыш төбәге, Иске Бәшир авылының иске зиратыннан Тимербулат Муса углы ташы (1766–1796) тексты ........................................ 147
№ 19 Иске Бәшир авылы зиратыннан кенәз Муса Җәнәкәев (1739–1804) кабер ташыннан текст ......................................................................................... 148
№ 20 Кыйгазыда табылган икенче ташбилге тексты ................................................ 149
№ 21 Тубыл музеенда саклanучы XVII гасыр ташбилгесе тексты ......................... 149
№ 22 Курган өлкәсе, Сафакүл төбәге, Мансур авылы зираты ташбилгесе тексты 151

## Алтынчы бүлек
## Оренбург төбәге һәм Каргалы (Сәгыйдь) бистәсе ташбилгеләре текстлары

Кереш ........................................................................................................................ 152
№ 1 Каргалы (Сәгыйдь бистәсе) Хәдиҗә Бикә ташбилгесе тексты ......................... 156
№ 2 Каргалы татар зиратындагы Габделкәрим бине Балтай ташбилге тексты ...... 157
№ 3 Эстәрлебаш төбәге Ибрай авылы зираты, Рәхмәтулла Мөхәммәдрәхим углы ташбилгесе (1770 ел) ................................................................................... 160
№ 4 Каргалы (Сәгыйдь) бистәсенең беренче зиратындагы Искәндәр һәм Әбүбәкер ташбилгесе тексты .................................................................... 162

№ 5 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Габдеррәфигъ бине мулла Габдулла әл-Каргалы ташбилгесе (1776 ел) ... 163
№ 6 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Гыйлемша Мирсәгыйди ташбилгесе (1779 ел) ... 164
№ 7 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Габидулла бине Габдерәхим ташбилгесе (1781–1782 ел) ... 165
№ 8 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Миңлемөхәммәд Бикинҗә углы ташбилгесе (1784–1785 ел) ... 165
№ 9 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Мөхәммәдшәриф Нәзир углы ташбилгесе (1784–1785) ... 166
№ 10 Федоровка районы, Балыклы авылы зираты, Булатай Мансур углы ташбилгесе (1785 ел) ... 166
№ 11 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Ишнийаз бине Ширнийаз ташбилгесе (1790–91 ел) ... 168
№ 12 Оренбург өлкәсе, Сакмар районы Үрге Чебенле авылы, Бөхәббәт бинте Биктимер ташбилгесе (1791–1792 ел) ... 168
№ 13 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Хөсәенҗан бине Габделхәлим ташбилгесе (1794–1795 ел) ... 169
№ 14 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Бикчәнтәй бине Габделгазиз ташбилгесе (1795 ел) ... 170
№ 15 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Габделмөлек бине Исмәгыйль ташбилгесе (1795–1796 ел) ... 171
№ 16 Оренбург Карагалысы борынгы зираты, Сәйфула бине Хөснулла ташбилгесе (1797–1798 ел) ... 171
№ 17 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Габдулла бине Мөхәммәдшәриф ташбилгесе (1798 ел) ... 172
№ 18 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Мөхәммәдсадыйк бине Мөхәммәдшәриф ташбилгесе (1798 ел) ... 172
№ 19 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Муса углы Бәдри ташбилгесе (1799 ел) ... 173
№ 20 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Мулла Әлмөхәммәд әл-Кирмани ташбилгесе (1800 ел) ... 173
№ 21 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Мөхәммәдсиддыйк бине Мөхәммәдшәриф ташбилгесе (1800 ел) ... 174
№ 22 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Зәйнелгабидин бине Мулла Әлмөхәммәд ташбилгесе (1801 ел) ... 175
№ 23 Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Исхак бине Габдлекәрим ташбилгесе (1802 ел) ... 175
№ 24 Каргалы бистәсе, иске зираты ташбилгесе тексты ... 176
№ 25 Оренбург губернасы, Гаянәямак авылы кырындагы ташбилге ... 177
**Йомгак** ... 178
**Ташбилгеләр сурәтләреннән үрнәкләр** ... 181

# КЕРЕШ СҮЗ

Татар мәдәниятының бер кыйммәтле тарихи истәлекләр төркемен тәшкил иткән кабер ташлары халкыбыз яшәгән һәрбер төбәктә мәгълүм.

Идел-Урал буйларында, Кырым, Кавказ якларындагы кала һәм салаларда алар татар цивилизациясенең бер уникаль күренеше буларак яхшы мәгълүм.

Аларның барлыкка килү дәвере Алтын Урда дәүләте тарихы белән бәйле. Әлбәттә, беренче мөселман төрки кабер ташларының үрнәкләре инде Алтын Урда дәүләте төзелгән 1243 елга хәтле үк булганнар.

Кыргызстан тарихчылары язуына караганда, әүвәлдә Караханилар дәүләте биләгән җирләрдә беренче мөселман эпитафия үрнәкләре булган ташбилгеләр милади 1161\62 елдан куела башлаган[1]. Аларның язмалары гарәп язуының куфи стилендә башкарылган. Шул ук дәверләрдән эпитафик язмаларның нәсех, сөлс һәм дивани ысулы белән язылганнары да мәгълүм[2].

Язмаларны «кайрак» дип аталган валуннарга һәм дә известь таштан кисеп эшләнгән плитәләргә язылганлыгы теркәлгән[3].

Бу ташлардагы эпитафик язма текст михраб рәвешендә ясалган кысалар эченә урнаштырылган[4]. Аларның текстлары да татар эпитафик язмалары структурасына якын, мәсәлән:

**1 таш текстта**

1. Һазә кабер
2. Гомәр бине Ә
3. бү Бәкер Гаффар Аллаһу
4. ля вәлү әд-дия[5].

***Аның татар теленә тәрҗемәсе:***

1. Бу кабер
2. Гомәр бине
3. Әбү-Бәкернеке. Аллаһ кичерсен
4. аны һәм туганнарын.

**2 таш тексты**

1. Һазә кабер
2. Хуҗа бине Әхмәд
3. Гаффар Аллаһу вә ләвә әд-дия
4. Лә Илаһе Алла, Мөхәммәд рәсүл Аллаһ һ.б.[6]

Икенче яктан караганда, эпитафик текстлар гарәп телендә генә язылганнар. Мондый күренеш XIII гасыр Алтын Урда дәвере ташларында да саклана.

Кыргызстанда бу заманнарда табылган эпитафик материаллар гарәп язуына кадәр төрки руник язуда да күп санда табылганы мәгълүм[7].

Югарыда китерелгән мәгълүматлар гарәп язулы эпитафик язмалар төрки руник текстларга алмашка килгән дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

XIII нче гасырның соңгы егерме елында Алтын Урда дәүләтенең Болгар Олысы җирләрендә дә кабер өсләренә язулы кабер ташлары барлыкка килү күренеше күзәтелә. Шунысы игътибарга лаек, алар текст структурасы ягыннан ниндидер гади таш билгеләрдән эволюция кичереп барлыкка килү чорын үтмичә, барлыкка килү дәверендә үк катлаулы структуралы текстлар рәвешендә сакланганнар. Тагы да өстәп түбәндәге үзенчәлекләрен кабаттан искәртү урынлы булыр. Алардагы язмалар күпчелек очракта куфи язуы һәм гарәп телендә, кимрәк дәрәҗәдә сөлес язуы һәм гарәп телендә башкарылганнар. XIII гасыр ахырында инде бу Алтын Урда дәвере ташларында гарәп һәм болгар теле элементлары, гарәп һәм татар теле элементларында язу тенденциясе башлана.

Әлеге эпитафик истәлекләрнең килеп чыгышын Алтын Урда тарихы белән бәйләп караганда гына аңлашыла.

Билгеле булганча, Алтын Урда дәүләте оешкан вакытында ук төрки мөселман дәүләте буларак тарихка килеп керә. Анда монгол элементы, хан сараенда гына булган булса кирәк. Чөнки бу дәүләтнең башлангычы дәверендә үк аның элитасының исемнәре төрки телләр материалыннан ясалганлыгы һәм аларның мөселманнар булып Ширван, Хорасан, Төрекмән, Кәрдар, Татар, Шәмәхә, Җәнд, Фирганә кебек урыннардан чыгуларын күрсәткән тәхәллүсләреннән күренә[8].

Эпитафик текстлар буенча танылган белгеч-галим Һ.В. Йосыповның күзәтүләренә караганда Идел буендагы язмалар плитәләр өстенә XIII–XIX гасырларда уеп һәм күпертеп язылганнар[9].

Кыргызстанда табылган XII гасыр гарәп язулы эпитафик текстларның уеп язылганлыгы күренә[10].

Идел буйларында язу өчен кыен булган кайракка (валуннарга) караганда, эшкәртү өчен җиңел булган известь ташлары чыганак-

лары күп булу һәйкәлләр ясау өчен аның төп материал буларак иң уңайлысы булып танылганлыгына сәбәп булган.

Инде XIII гасыр ахырына таба Батый хан гаскәрләре белән Караханилар, Хәрәзем, Фирганә якларыннан килгән мөселман татарларның картаеп, бакый дөньяга китү вакытлары җитү сәбәпле, аларның кабер өсләренә Урта Азиядән килгән йола буенча эпитафик һәйкәлләр кую дәвере башлана.

Әлбәттә, Алтын Урда дәвере – татар мөселман эпиграфик культурасының ныклы традицион архитектура тибы барлыкка килү дәвере белән үзенчәлекле.

Алтын Урда чорында анда нигездә төрки дөньяда борынгы дәверләрдән бирле мәгълүм булган вертикаль хәлдә торучы һәйкәлләр төп форма булып калган. Аның үрнәкләре Идел-Урал, Кырым, Кавказ якларында шул рәвештә мәгълүм. Дөрес, бөтен Алтын Урда традициясендә урын алмаган горизонталь таш билгеләр Әстерхан, Кырым якларында яңа дәверләргә хәтле мәгълүм булып торалар.

XV гасырда татар эпитафик һәйкәлләр культурасы беркадәр сүнүгә йөз тота. XV йөзгә кергәч эшләнгән ташбилгеләр инде элекке классик ташлардан форма, бизәлеш һәм каллиграфия сәнгате үрнәкләре булу ягыннан нык калышалар. Шул ук вакытта Казан ханлыгы дәвере башланган XV йөз уртасыннан бу юнәлештә яңа тип эпитафия сәнгате үрнәкләре барлыкка килү юнәлешендә хәрәкәт бара.

Казан ханлыгы 1552 елда тәре йөртүчеләр кулы белән җимерелсә дә, аның эпитафия сәнгате традициясе үзенең төп сәнгать үзенчәлекләрен Казан, Касыйм һәм башка төбәкләрдә XVII гасыр ахыры һәм XVIII гасыр башына кадәр тотрыклы саклап килә.

Татар эпиграфика сәнгате, аның беренче махсус белгече Һарун Вәли улы Йосыпов тарафыннан XIII–XVI йөзләр материалында нигезле рәвештә өйрәнелеп килендe. Ләкин галим, гәрчә аның хезмәтләрендә чыганаклар тарихи проблемасы XIX гасыр башына хәтле өлешчә генә яктыртылса да, XVII гасыр ташбилгеләре нигезендә бу юнәлештә зур гомумиләштерүләр ясарга өлгермәде. Галим XVII–XIX гасыр татар эпитафика сәнгатенең таралыш һәм яшәеш дәверләрен ачыкларга өлгермәде.

Без, бу куелган хезмәтебездә, татар эпиграфика сәнгатенең XVII–XVIII йөзләр ахырына хәтле таралыш һәм сакланыш проб-

лемаларына ачыклык кертүне чишүне бурыч итеп куйдык. Моның өчен тарихи басма, кулъязма чыганаклар һәм кыр экспедицияләре материалларына таяндык.

Ташбилгеләрнең тарихи таралышын инде XIX гасырда ук аерым тарихчылар, телчеләр, җирле крайны өйрәнүчеләр барларга, аларны укып фәнни әйләнешкә кертү хезмәтенә керешәләр.

Алар арасында без урыс һәм татар тарихчыларыннан В.В. Вельяминов-Зернов (1830–1904), С.М. Шпилевский (1833–1907), Хөсәен Фәезханов (1828–1966), Н.И. Шишкин, Хөсәен Фәезханов (1828–1866), Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889), Каюм Насыйри (1825–1902), Ризаэддин бине Фәхретдин, Н.Ф. Катанов (1862–1922), Н.И. Ашмарин (1870–1933), С.Е. Малов (1880–1957), Гали Рәхим (1892–1943), Һарун Йосыпов (1914–1968), Әхмәт Булатов (1901–1982), Фәрит Хәкимҗанов һ.б. күрәбез.

Санап үтелгән галимнәрдән абсолют күпчелеге бары тик Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәвере эпитафияләре тарихы белән кызыксындылар. Алардан тик К.Насыйри, Һ.В. Йосыпов һәм Гали Рәхим генә XVII–XVIII гасырлардагы истәлекләргә игътибар итә башладылар.

Археограф буларак без дә татар эпитафия истәлекләре белән кызыксынып, фәнни экспедицияләргә 1973 елдан даими чыгып татар зират культурасын өйрәнүгә керештек. Безнең тарафтан Татарстанның дистәләрчә районнары, шәһәрләреннән Казан, Чистай, Буа, Әлмәт, Минзәлә, Арча, Лениногорск, Азнакай, Норлат зиратлары ташлары өйрәнелде. Шулай ук Касыйм, С.-Петербург, Оренбург, Екатеринбург, Чиләбе, Сакмар, Уфа, Троицк, Оренбург Каргалысы, Бәрәнге шәһәр каберлекләре һәм бу өлкәләрдәге кайбер татар авылларында фәнни тикшеренү эшләре алып бардык. Соңгы елларда яшь галимнәрдән Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев, Нурулла Гариф һәм Венер Усмановлар татар эпитафик истәлекләрен өйрәнү буенча җитди эшләр алып баралар.

Шушы күп санлы галимнәрнең һәм үзебезнең хезмәтләре берләштереп татар эпитафиясенең XVII–XVIII гасырдагы таралыша һәм аларның тарихи кыйммәтләре хакында гомумиләштергән фикергә татарны өйрәнү фәнендә бүген зур ихтыяҗ килеп туды.

Эш шунда ки, бүгенге татар тарихчыларының бу өлкәгә кергә һөнәри әзерлекләре һәм нигезле белемнәре юк. Шунлыктан бүгенге көндә узган гасырлар тарихын язганда кыйммәтле чыга-

нак буларак таянырга яраган эпитафия текстлары урнына «бер, ике... кабер ташы бар» дип кенә язылган мәкалә һәм китаплар килеп чыга. Шундыйларның берсе итеп бу ел басылып чыккан урыс телендәге Арча төбәге тарихына кагылышлы мәкаләләр җыентыгын күрсәтергә кирәк. Тагын да бер проблема бүгенге татар тарихчылары һәм археологларның шактый өлеше татар телендә сөйләшсә дә, алар моңа кадәр чыккан дистәләрчә эпитафияләргә, шәҗәрәләргә кагылышлы татар телендә басылып килгән чыганакларны белмиләр. Бик кызганыч әлбәттә, эшләр бу килеш барганда җәмәгатьчелек аларның бу кимчелеген бик тиз тотып алыр һәм андый тарихчыларны профанлыкта гаепли башларга мөмкиннәр.

XVII–XVIII гасыр эпитафик истәлекләрен барлап чыккач, үз тарихыбызга һәм милләт булып оешту тарихына кагылышлы кызыклы ачышларга ирешәсең.

Бөтен тупланган хәтле истәлекләрнең исәбен ачыклагач (әлбәттә, алар тагын да күбрәк булганнар). Бүгенге көндә XVII–XVIII гасырлардан сакланып калган 160-лап ташбилгеләрнең барлыгы расланды[1].

Без аларны тарихи чорлар, географик өлкәләргә бүлдек. Аларның беренчесе Касыйм шәһәре районы, икенчесе Казан тирәсе һәм башкалар. Таблицада ул түбәндәгечә чагыла:

| | **Регион атамалары** | **Эпитафияләр саны** | **Эпитафияләр куелган вакыт хронологиясе** |
|---|---|---|---|
| **1.** | Касыйм шәһәре | **11** | 1600–1652 |
| **2.** | Чуаш төбәге | **18** | 1683–1745 |
| **3.** | Казан регионы | **31** | 1611–1785 |
| **4.** | Минзәлә, Әгерҗе, Актаныш, Мөслим, Азнакай, Менделеев, Алабуга, Әлмәт, Мамадыш | **46** | 1656–1796 еллар |
| **5.** | Урта Урал, Көнбатыш Себер регионы | **22** | 1686–1763 |
| **6.** | Оренбург регионы | **23** | 1752–1801 ел |
| | Барысы | **160** | 1600–1804 |

[1] Бу хисапка коллегаларыбыз Р.Мәрдәнов һәм И.Һадиев тарафыннан Әгерҗе төбәгендә табылган 8, Кукмара төбәгендә табылган ике XVII–XVIII гасыр ташбилгеләре дә исәпкә алынмады. Әлеге яңа тыбышлар бу хезмәткә керә алмый калдылар. – *М.Ә.*

Ташларның XVII нче гасырда куелганнары Касыйм ягыннан Тубылга хәтле бер төрле архитектура-декоратив рәвештә, тел ягыннан татар телендә һәм эпитафик текст структурасы ягыннан бер төрле.

Бу факт татар халкының инде XVII гасырда ук бер милләт буларак оешкан хәлдә яшәгәнлегенә дәлил.

XVII гасыр ахырында Русиядә Петр I-нең дәүләт сәясәте урыслаштыру һәм башка халыкларны көчләп христиан диненә кертү юлына баскач, татар халкының мәдәниятенә генә түгел, үзенә дә физик юк ителү куркынычы яный башлый. Татар балаларын ул заманнарда 11–12 яшьтән гаскәри хезмәткә алдыру, татарларны сугышның иң кайнар нокталарына җибәреп кырдыру татар югары катлавының чукынырга теләмәгән өлешен мөлкәтеннән мәхрүм итү, татарларга металл, таш, ювелирлык һөнәрләре белән шөгыльләнүдән тыю аркасында милләтебездә кабер ташлары эшләүчеләр династияләре өзелә. Татар зиратларында XVIII гасырның 60-нчы елларына кадәр эпитафик ташлар куйдыру бик чикләнә, дөрбәләр дә корылмый башлый. Ләкин бу традицияләр бөтенләй юкка чыкмый, югалганнар урынына яңа осталар династияләре чыгып борынгы традицияләрне яңартуга хәзерлек бара.

Типологик Касыйм һәм Казан ханлыгы эпитафияләренә тәңгәл килгән кабер ташларының Уфа, Чишмә станциясе һәм Тубыл шәһәре җирләрендә XVII гасыр ахырларында да барлыкка килүе, бу җирләргә Казан һәм Касыйм якларыннан XVII нче гасырның беренче яртысында ук шактый күп санда татарларның күчеп утыруларының дәлиле. Аларның бу якларга күчүләре шәҗәрә материаллары белән дә раслана. Мәсәлән, Кара бәк нәселләре һәм Меңнәр кабиләсе вәкилләре җирләр биләп Ык, Дим, Зәй буйларына XVII гасырның беренче яртысында Нугай Урдасы, Себер ханлыгы биләмәләренә күчеп барганнар. Яңа җирләргә күчеп барып, картайгач, алар дөньядан үтеп киткәч, традиция буенча каберләре өсләренә известь таштан һәм комташтан эшләнгән традицион кабер ташларын аларның бакый йортлары өстенә дә эшләтеп куйганнар.

Шунысы игътибарга лаек, Уфа регионында куелган кабер ташларының 21-ннән 17-се 1686–1708 еллар арасында куелган ташлар һәм алар типологик яктан барсы да бер төсле һәм моннан тыш Минзәлә төбәгендәге 30-дан артык һәйкәл белән тәңгәл киләләр.

Тагын да бер кызыклы факт, татар эпитафияләренең Казан һәм Минзәлә төбәкләрендә эшләнгән һәйкәлләренең күпчелеге Килмөхәммәд бине Ишман дигән оста кулы тарафыннан XVII гасыр ахырында эшләнгәннәр. Килмөхәммәд үзе эшләгән ташларга имзасын да «Килмөхәммәд бине Ишман», яки «Килмөхәммәд Ишман углы» дип язып куйган. Аның кулы белән эшләнгән, эшләнеп имза куелган ташларның саны илле берәмлекләр чамасына җитә. Моннан тыш аның бер шәкертенең эше Уфа-Чишмә якларында сакланган.

XVII гасыр урталарында ташлар язып куйган янә өч останың исемнәре мәгълүм. Аланың эшләре Әгерҗе төбәге Салагышта (1658\9 ел) һәм Минзәлә төбәге Бикбау авылы зиратларында (1656\7 елда) сакланып калган. Салагышта эше сакланган останың исееме Тиләш углы Дусмәт Хафиз, Бикбау ташының бер остасы Дәвеш хафиз, бу зиратта сакланган икенче 1688\89 еллардагы ташка «Остаз углы Аккуҗад язды» дип имза куелган. Моның остазы нәкъ шул Килмөхәммәд булган дип фикерләргә кала. Чөнки Аккуҗадның эшләре Килмөхәммәднекенә бик охшаш.

Археографик экспедицияләр нәтиҗәләре күрсәткәнчә XVII гасырдан калган татар кульязмалары бик аз. Шунлыктан бу дәвер кабер ташлары XVII гасырдагы татар халкының язу культурасы тарихы күрсәткече дә булып торалар.

XVII гасырдан калган кабер ташларының бер өлеше бүгенге яшәп килгән авылларның зиратларында саклана. Мәсәлән, Әгерҗе ягындагы Салагыш, Турай, Ырыс, Иске Эсләк, Актаныш ягындагы Әҗәкүл ташы, Чишмә станциясе зираты һәм дә Тау ягы төбәгендәге ташлар һ.б. Шулай ук хәзерге авыллардан шактый ераклыкта, ялгыз сакланган ташлар да бар. Мәсәлән, Алабуга төбәге Бәзәкә ташы, Әгерҗе төбәгендәге Балтач исемле кешенең ташы һ.б. Ташларның сакланышы XX гасырның икенче яртысында бик начарланды. Мәсәлән, хәзерге Мөслим төбәге Тугаш авылы зиратында 1929 елда оештырылган академик археографик экспедиция хисабында XVII йөздән калган ике таш күргәнлекләре языла. 1997 елгы эзләнүләр вакытында анда бер таш та табылмады. Әҗәкүл авылы зиратында картларның сөйләүләре буенча (1997 елда) ике борынгы таш булып, хәзер аларның берсе генә сакланган. Әгерҗе төбәге Кодаш, Ырыс, Иске Эсләк, Иж Бәйки авылларында 1977 елларда булган ташлар, Мөслим төбәгенең

Катмыш зиратында шул ук вакытларда булган 15 ташның тик буш урыннары гына калган һ.б. Урыннарда татар халкының тарихи истәлекләре язмышы белән властьта утырган бәндәләр кызыксынмыйлар. Бары тик җирле халык эченнән чыккан аерым кешеләр тырышлыгы белән генә борынгы кабер ташларының бик азына сакланып калырга мөмкин була. Мәсәлән, Мамадыш төбәгеннән Рөстәм Шәехов дигән бер яшь егетнең гаиләсе Олыяз кырындагы XVII гасыр ташын егылып яткан урыннан бастырып, чистартып язуларын хәзерге хәрефкә күчертеп саклау өчен шартлар тудырды. Шулай ук Эхтиял авылыннан да шундый бер кеше теләк күрсәтеп йөргән иде күптән түгел, ләкин аның эшенең нәтиҗәсе безгә мәгълүм түгел.

Борынгы ташларның сакланышын кайгырту ул үзеңнең бабаларың өчен «Коръән» укыту кебек саваплы эш. Бәлкем шулай бабалар каберләрен онытканлыктан бүгенге татар авылларына да каһәр төшеп, юкка чыга баралардыр. Менә дөньяда «ассирияле» дигән кечкенә, аз санлы халык бар. Алар дәүләтчелекләрен моннан 2500 ел элек югалтсалар да үзләренең телләрен һәм исемнәрен бик нык саклап йөриләр. Үзләрен бик горур тоталар, кол булырга омтылмыйлар. Нәселен хөрмәтләп, югары сәнгате, тарихы булган татар халкы да югалырга тиеш түгел. Безнең бабаларыбыз бу җирләргә яңа эрага хәтле күп элек килгәннәр, без күңелләрдә алар хәтерен дә саклап яшәргә тиеш.

Бу хезмәт өчен материаллар 1973 елгы археографик экспедиция вакытында шулай ук туплана башлады. Шул вакытлардан соң безгә берничә йөз татар авыллары зиратлары белән танышырга туры килде.

1976–1977 елларда без Әгерҗе, хәзерге Менделеев, Алабуга, Мамадыш, Азнакай, Ютазы якларында кульязма китаплар туплау белән бер рәттән кабер ташларын да өйрәнеп аларның текстларын язып алдык. Бу табышларыбызны өйрәнеп, аларның эчтәлеге турында бер фәнни мәкаләбез дә басылган иде[11].

Азнакай төбәгендәге Чалпы, Урсай авыллары зиратларның бер өлеш материалы 2001 елда чыккан китабыбызга керде[12].

Әтнә төбәге Олы Мәнгәр авылы зираты кабер ташлары[13], Арча төбәге кабер ташлары хакындагы хезмәтләр басылды[14].

Моннан тыш Татарстанның Биектау[15], Лаеш төбәкләре[16] эпитафияләренә багышланган мәкаләләр дөнья күрде.

Яңа XXI гасырга кергәч безнең тарафтан Ахун[17], Касыйм[18], Әлмәт[19], Оренбург, Каргалы[20], Чишмә[21] һ.б. урыннардагы татар зиратларын өйрәнү нәтиҗәсендә язылган мәкаләләр басылдылар.

Экспедицияләргә чыгуның беренче елларында безнең кулда яхшы фотоаппаратлар булмаганлыктан, барлык һәйкәлләрнең дә сурәтләрен алып булмады. Менә хәзерге елларда бик уңайлы фотоаппаратлар чыгып без Касыйм, Каргалы, Оренбург, Уфа, Чиләбе, Екатеринбург, Троицк кебек борынгы мәдәни үзәкләребез зиратларыннан бик бай материал туплап кайттык, аларның кайберләре бу китапта файдаланылды (Азнакай, Әлмәт төбәге, Каргалы, Курган өлкәсе, Чишмә станциясе һ.б.).

Бу китапка барлык XVII–XVIII гасыр кабер ташлары керетелеп бетте дип әйтеп булмый. Монда берничә төбәкләрнең зиратларын тикшереп чыгасы бар әле. Мәсәлән, Арча, Балтач, Стәрлебаш һ.б. якларда аерым зиратларны ныклабрак өйрәнергә кирәк.

Безнең коллегаларыбызның да татар эпитафик тарихын тикшерү, өйрәнү эшендә активлыгы артты. Мәсәлән, тарих фәннәре кандидаты Раиф Мәрдәнов[22], Ирек Һадиев, Җәмил Мөхәммәтшин[23], Касимова Д.Г.[24], Нурулла Гариф[25], Венер Усманов[26] һ.б. яңа ачышларын бәйян иткән мәкаләләре, китаплары басылу, татар кабер ташларын өйрәнүдә алгара барышны күрсәтәләр. Шул ук вакытта кабер ташларының декоратив, архитектура сәнгате объектлары буларак өйрәнелү буенча эшләрнең арта баруы, хәтта кандидатлык диссертацияләре яклау[27] кебек гамәлләр дә булыр дип уйлыбыз.

Бу китапны компьютерда җыючылар: А.Хакимуллина, Л.Байбулатова.

***Марсель Әхмәтҗанов,***
***филология фәннәре докторы.***
***Казан, 2010. 28.XI.***

# Искәрмәләр

[1] Джумагулов Ч. Эпиграфика Киргизии. Выпуск 3. – Фрунзе: Изд-во «Илим», 1987. – С.60.

[2] Там же. – С.60.

[3] Там же. – С.63.; Чанышев М. Кытайда татар мәгарифе тарихы. – Казан: «Җыен» нәшр., «Идел-Пресс» нәшр., 2007. – Б.29–30.

[4] Там же. – С.63.

[5] Там же. – С.63.

[6] Там же. – С.64–67.

[7] Там же. – С.21–38.

[8] Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. – М.: Изд-во «Наука», 1978. – С.89.

[9] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.; Изд-во АН СССР, 1960. – С.38.

[10] Джумагулов Ч. Эпиграфика Киргизии. Выпуск 3. – Фрунзе: Изд-во «Илим», 1987. – С.30, 64 и др.

[11] Ахметзянов М.И. О лексике татарских эпитафий XVII–XVIII вв. // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983. – С.75–83.

[12] Әхмәтҗанов М.И. Меңъеллык татар нәселе. – Казан: «Мәгариф», 2001. – Б.42, 43 һәм төсле кушымта материаллары.

[13] Әхмәтҗанов М.И. Олы Мәнгәр авылы тарихы. – Казан: Идел-Пресс, 2000. – Б.26–28.

[14] Әхмәтҗанов М.И. Арча төбәгенең эпиграфик истәлекләре // Арча төбәге тарихы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1996. – Б.39–52.

[15] Әхмәтҗанов М.И. Биектау төбәгенең XIII–XVII гасырлардан калган татар эпиграфикасы // Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. – Казань, 1999. – Б.90–97.

[16] Ахметзянов М.И. Тайны эпитафий // История Лаишевского края. – 1997. – С.114–117.

[17] Әхмәтҗанов М.И. Ахун авылы зиратлары // Әхмәтҗанов М.И., Солтанов Вәли. Азун авылының шәҗәрә китабы. – Казан: Gumanitariya, 2004. – Б.131–175.

[18] Ахметзянов М.И. Эпитафийные памятники касимовских татар // М.И. Ахметзянов, Ф.Л. Шарифуллина. Касимовские татары. – Казань: «Магариф», 2010. – С.100–119; Әхмәтҗанов М.И. Касыйм шәһәре зираты эпитафик поэзиясе // Әдәби мирас һәм текстология. – Казан, 2008. – Б.82–90; Әхмәтҗанов М.И. Касыйм шәһәрендәге татар дөрбәләре // Татарская археология. – 2006. - № 1–2. – Б.197–217.

[19] Әхмәтҗанов М. Үлгәннәрнең каберен бел. – Казан: «Мәгариф», 2000. – 159 б.

[20] Әхмәтҗанов М. Татар Каргалысы (Сәгыйдь бистәсе) дөрбәләре // Татарская археология. – Казань. – 2006. № 3–4. – Б.213–226.

[21] Әхмәтҗанов М.И. Мең кабиләсе этнонимы чагылган кабер ташлары // М.И. Әхмәтҗанов. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. –Казан: «Мәгариф», 2002. – Б.123–132.

[22] Мәрданов Р., Һадиев И. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: «Тамга» нәшрияты, 2008. – 148 б.

[23] Мухаметшин Дж.Г. Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. – Казань, 2008. – 132 с.

[24] Касимова Д.Г. Семейная обрядность чепецких татар (середина XIX – XX вв.). – Ижевск, 2003. – 300 с.

[25] Гариф Нурулла. Казан ханлыгы чоры ташъязмалары. – QAZAN, 2010. – 128 б.

[26] Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр. 1 нче китап. – Уфа, 2005. – 168 б.; Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр. Икенче китап. – Эстәрлетамак, 2005. – 366 б.; Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр. Өченче китап. – Сакмара: Сакмарская типография, 2008. – 500 б.

[27] Хисамиева Г.К. Надгробие в контексте национальной культуры (на материале Юго-Востока Татарстана). – Автореферат диссертации на соискание ученой степени кандидата культорологии. – М. 2007 – 25 с.

# БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

## XVII гасыр Касыйм шәһәрендәге Иске Бистә зиратында табылган татар ташбилгеләре текстлары

### Кереш

Касыйм ханлыгы 1450 елларда оешкан булса да, анда XV гасырдан калган бер эпиграфик истәлек тә мәгълүм түгел.

Мәгълүматлар һәм халык телендә сакланган риваятьләргә караганда Касыйм ханлыгында озак еллар буе авыл җирләрендә зиратлар булмаганга охшый. Мәсәлән, Әҗи авылы халкы үзләрендә булган мәетләрен Касыйм шәһәрендәге Иске Бистә зиратына илтеп күмә торган булганнар. Хәтта XVII гасыр уртасында да Әфган хан Мәскәүдә үлгәч, аның гәүдәсен Иске Бистә зиратына алып кайтып күмгәннәр. Ялган Дмитрий II Ураз Мөхәммәд ханны 1610 елда Калуга янында үтереп, гәүдәсен Ока елгасына ташлый. Татарлар аның гәүдәсен эзләп табып, шулай ук Касыймдагы Иске Бистәдәге зиратка алып кайтып күмәләр.

Касыйм ханлыгында татар халкының саны чагыштырмача аз булганлыктанмы, ул заманнардан калган татар зират урыннары хәзергә тәгаенләнмәгәнлектән, алар хакында әлегә конкрет бер фикер әйтеп булмый. Шулай да, безгә соңгы елларда (2004–2005 еллар) Касыйм шәһәрендәге Иске Бистә, Яңа зиратларны, Шырын (Подлибки) авылы зиратындагы истәлекләр белән танышырга туры килде. Соңыннан 2008 елда Рязань өлкәсенең татар авыллары әлегә сакланган Сасово, Ермишино авыллары зиратларын өйрәнергә туры килде. Ләкин без Касыймдагы Иске Бистә зиратыннан башка, татар авылларында булган XV–XVIII гасыр зират эзләрен таба алмадык. Моның өчен әлбәттә археологик эзләнүләр ясарга кирәк.

Мәсәлән, Сасово төбәгендә XV–XVI гасырларга караган Тимген дигән борынгы каланың балчыктан өеп ясалган әлегә бик биек

үрләре булу, анда билгесез каберлекләр дә булуына да, аларның табылуына ышаныч уята. Эш шунда ки, Тимген каласы урнын әле бу җирләрдә XV–XVI гасырларда яшәмәгән славяннарга бәйләргә тырышу идеологиядә ярылып ята. Ә тикшерергә теләү юк, казый башласаң җир астыннан да татар сөякләре килеп чыгу ихтималы зур. Шуңа күрә казып тормый, өйрәнми генә тарихны славянлаштыру бара. Шунлыктан Тимген каласын XIV–XV йөзләрдә Сарайдан күчеп килгән берәр татар бәге салганлыкка нигез өмет зур. Әгәр Тимген кала урны X–XI гасырлардан калган булса, аның үрләре бүгенге хәтле үк биек булмас иде. Аннан соң бит славяннорманнар җирдән үр ясау эше белән мавыкмаганнар да, алар нигездә таш диварлар корганнар.

Тимген каласы стратегик яктан бик белеп, аңлап төзелгән, ул Цна елгасының биек ярында, елгадагы хәрәкәтне кулда тотар өчен дә уңайлы итеп «Казанка» елгасы буендагы Арча, Иске Казан калалары кебек тау башында балчык үрләр белән әйләндереп алып төзелгән.

Тимгеннең үрләр эчендәге мәйданында төрле чокыр урыннары күренә, ләкин таштан яки кирпечтән салынган зур монументаль бина нигезләре беленми. Күрәсең, бу вакытлы бер ныгытма хәлендә корылып, озын гомерле кала булып китмәгәндер. Хәер, аның елга ярына килеп чыга торган җир асты юлы очы беркадәр җимерелгән хәлдә күренеп тора.

Бу якларда борынгы таш билгеләре булган, тарихлы зиратлар да искә алынмый. Бердәнбер борынгы эпитафияләр булган урын дип, әлегә Касыйм шәһәрен генә атарга мөмкин. Анда XVI гасырның икенче яртысы һәм XVII гасырның беренче яртысында әле эпитафия үрнәкләре булган, ләкин алар Касыйм ягында, фәкать Шаһ Гали дөрбәсе янындагы һәм Иске Бистәдә генә булу мөмкинлеге нигезле һәм ышанычлырак. Дөрес, Рязань өлкәсе крайны өйрәнүчеләрнең берсе XVI гасырның соңгы чирегендә Төмән (Темников) шәһәре янында, Ботак мирза үлемен (1564 ел) хәбәр иткән бер кабер ташы булуы хакында фәнни әдәбиятта бер искәрмә бар[1].

[1] Татарские князья и их княжества. – Нижний Новгород: Издательский дом «Медина», 2008. – С.28.

Рязань өлкәсенең Касыйм, Ермишин районнарында тупланган кайбер мәгълүматларга караганда бу як татарларының булган мәетләрен Касыйм шәһәренә, Иске Бистә зиратына илтеп күмүләре хакында тарихи хәбәрләр сөйләнүен баштарак искә алдык инде.

Безнең бу өлкәдәге Сасово, Ермишино, Касыйм районнарындагы мөселман татар зиратларын өйрәнү буенча уздырылган фәнни эпиграфик экспедицияләр материалы раслаганча, барлык татар мөселман зиратларындагы кабер ташлары фәкать XIX йөзнең соңгы чирегеннән генә күренә башлыйлар. Ихтимал, XVII–XVIII гасыр кабер ташлары Касыймнан читтәге татар авылларында бөтенләй мәгълүм дә түгелдер.

Бу регион тарихы буенча дүрт томлык китап язган В.В. Вельяминов-Зернов кулында да аңа уңай җавап бирерлек чыганаклар юк.

Касыйм ханлыгының үзәге булган Касыйм шәһәре һәм аңа бәйле районда татарларның гомуми саны 1719–1860 еллар арасында 5797 кешедән 4778 гә кала[1]. Этнография фәне законнары буенча ул 5797 кеше 1860 елга 40 мең чамасына җитәргә тиеш бит. Димәк, татар халкының яшәеше өчен 1620–1860 еллар арасындагы дәвер коточкыч авыр булып, халык үлеп бетүгә йөз тоткан һәм анда аның кабер ташлары куярлык матди хәле булмаган.

Бу процессның эпитафияләр кую өлкәсендәге халәтен Касыйм регионы белән ул вакыттагы Казан регионы статистик күрсәткечтән дә чамаларга мөмкин. Касыйм регионында 1600–1800 еллар арасында куелган бары 12 эпитафик текст сакланса, Казан регионында 50 дән артык истәлек, Минзәлә регионында 45 таш, Оренбург төбәгендә 23 таш мәгълүм. Шул ук вакытта Оренбург, Казан һәм Минзәлә якларына Касыйм якларыннан чыккан татарларның шәҗәрәләр, кабер ташлары язмалары буенча мәгълүмат шактый санда күренә. Бу күренеш кызыклы, ләкин аның статистикасы махсус өйрәнелүне сорый.

Йәнә дә бер кызыклы факт түбәндәгедән гыйбарәт. Касыйм ханлыгындагы 1560–1620 нче еллар арасына куелган классик татар эпитафия үрнәкләре сәнгате стиленең Казан ханлыгында һәм аннан соң 1630 нчы елларгача куелган татар эпитафик таш билгеләре белән зур тышкы уртаклыклары булса да, беркадәр идеологик аермалары да бар...

---

[1] Шарифуллина Ф.Л. Касимовские татары. – Рязань, 2004. – С.121.

Касыйм ханлыгында 1560–1620 нче елларда куелган эпитафик истәлекләр үзләренең габарит үлчәүләре белән Казан ягыныкыннан күзгә ташланып аерыла. Касыйм ягы эпитафиясен ясау өчен, аның яхшы сыйфатлы таш чыганаклары булмаган күрәсең, ул материал ак ук түгел – саргылтрак известь таш, Казан ягында, гомумән Оренбург якларында, яхшы сыйфатлы ак известь-доломит ташлар XIII–XIV гасырлардан ук мәгълүм булган. Аларның сакланышы да яхшырак.

Касыйм ханлыгы биләмәләре булган җирләрдә классик стильдәге татар эпитафия сәнгате гомумән 1620 еллардан соң юкка чыга һәм аның XIX гасырдагы яңарышы башка стильдә барлыкка килеп, 1801–1930 елларда яшәп, яңадан сүнә.

Китапның бу бүлегенә кергән ташбилгеләр текстлары барсы да Касыйм шәһәренең Иске Бистә зираты материаллары булып торалар.

## № 1
## Касыйм шәһәренең Иске Бистә зиратыннан табылган ташбилге
## Беренче ташбилге тексты, һиҗри 1009, милади 1600/1601 ел

1. قال الله تبارك و تعالى ان مثل عيسى
2. عند الله كمثل آدم خلقه من تراب ثم قال لا كن فيكون
3. قال الله سبحانه و تعالى كل نفس ذايقة الموت ثم الينا ترجعون
4. قال الله تبارك و تعالى باى ارض تموت ان الله عليم خبير
5. قال النبى عليه السلام الدنيا ساعة فجعلها طاعة
6. قال النبى عليه السلام الدنيا مزرعة الآخرة
7. قال النبى عليه السلام الدنيا جيفة و طالبها كلاب صدق رسول الله
8. تاريح [مينك]... توقوز ييلدا سولش اوغلى حابت ميرزا
9. دار الفنادين دار البقاعة رحلت قيلدى حق تعالى رحمت قيلسون

**Эпитафик текстның татар телендә язылган өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

8. Тарих [миң дә] ... тукыз йилда Сүлеш угылы Хабит мирза

9. Дарелфанадин дарелбакага рихләт кыйлды, Хак Тәгалә-и рәхмәт кыйлсун!

**Искәрмәләр**

Ташбилге Касыйм шәһәрендәге Иске Бистәдәге татар зиратында 1860 елда мәгърифәтче галим Хөсәен Фәезханов тарафыннан беренче булып табылган һәм өйрәнелгән.

Урыс тарихчысы В.В. Вельяминов-Зернов аны үзенең хезмәтендә тәрҗемәләре белән бастырып чыгарган. Ташның үлчәмнәре һәм аның физик хәленең тасвирламасы бирелмәгән.

Текст бу басмага В.В. Вельяминов-Зернов басмасыннан алынды[1]. Аның 1–7 юллары гарәп телендәге аятьләрдән гыйбарәт.

Текстның дата язылган 8 нче юлында бер урын ватылган, ләкин ташның эчтәлегеннән чыгып аны XVII гасырның башында язылган дип әйтергә мөмкин.

[1] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. Часть вторая. – С.-Петербург, 1864. – С.491–492.

## № 2
## Икенче ташбилге тексты
## Һиҗри 1009, милади 1600/1601 ел

تاريح مينك توقوزدا ايردكم قريم لى سولاش
بيك اوغلى حهان شا ميرز انتقال قيلدى
سكسان اوچ ياشنده وفات بولدى حق تعالى
رحمت قيلسون

Һәйкәлнең арткы стенасында

الله راضيسى اوچون بولوحنى اوراز محمدحان
دوستليق اوچون قريم لى جهان شا ميرزاغا
بنا قيلدوردى

**Текстның татарча өлешенең хәзерге язмада чагылышы**

1. Тарих миң тукузда ирдикем Кырыймлы Сүләш
2. бик углы Җиһаншаһ мирза интикаль кыйлдый
3. сиксән өч йәшендә вафат булдый Хак Тәгаля
4. рәхмәт кыйлсун

**Һәйкәлнең арткы стенасындагы текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Аллаһ разыйсы өчүн бу ләүхәне
2. Уразмөхәммәд хан дустлыйк өчүн Кырыймлы
3. Җиһаншаһ мирзага бина кыйлдурдый

**Искәрмәләр**

Бу таш һәйкәлне татар мәгърифәтчесе Хөсәйен Фәезханов 1860 елда Касыйм шәһәренең Иске Бистәсендәге зиратта эзләп таба, аның текстын беренче булып укый. Аны тарихчы В.В. Вельяминов-Зернов үзенең хезмәтендә Х.Фәезханов укыган халәттә кабул итеп, бастырып чыгара[1]. Ташның үлчәүләре мәгълүм түгел. Аның куелу датасы һиҗри 1009, милади 1600–1601 елга туры килә.

[1] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. – С.489.

Әлеге басмада ташбилге текстының гарәп телендәге юлларын китерү кирәк табылмаган.

Сүлеш мирза бине Аппак мирза Мәскәүдә Кырым ханлыгының илчесе булып хезмәт иткән[1]. Аппак мирза 1518 елда Мәскәүдә илче булып торган. Бу нәселнең дәвамчылары Казанда XVII–XXI гасыр башларында да яшиләр әле.

Сүлеш мирза Кырым ханлыгының атаклы нәселдән булган, аны Кырымда бәк дип йөргәннәр. Ләкин мирзаның Җиһаншадан туган балаларыннан берсе Мәскәүдә чукынып – Юрий Яншеевич Сулешев – Михайл Романов патша заманында бояр һәм князь булып хезмәт иткән.

Сүлеш мирзаның тагын бер улы Касыйм зиратында күмелеп калганлыкка дәлил булып бер таш билгедәге язма сакланган.

## № 3
## Өченче ташбилге тексты
## Һижри 1017, милади 1608 ел, июнь

1. قال الله تبارك و تعالى ان مثل عيسى
2. عند الله كمثل آدم خلقه من تراب ثم قال لا كن فيكون
3. قال الله سبحانه و تعالى كل نفس ذايقة الموت
4. قال الله سبحانه و تعالى باى ارض تموت
5. قال النبى عليه السلام الدنيه ساعة فجعلها طاعة
6. قال النبى عليه السلام الدنيا مزراعة الآخرة
7. تاريح مينك تقى اون ييتيدا ربيع الاوّل آينيك اوّ
8. لينده مصطفى على خان عيالى تاقبيلدى خانيش
9. اون ييتى ياشندا بو دنيادين نقل قيلدى

**Текстның татар телендә язылган өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

7. Тарих миң такый ун йитидә рәбигыль-әл-әүвәл айыныйң әүв-

8. әлиндә Мостафа Гали хан гайәли Такбилди ханиш

9. ун йити йәшендә бу дөньйадин нәкыйль кыйлдый.

[1] Ризаэддин бине Фәхретдин. Казан ханнары. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1995. – 86 б.

**Искәрмәләр**

Текстның баштагы 1–6 юллары гарәп телендәге «Коръән» айәтләреннән гыйбарәт. Ташбилгенең тышкы тасвирланышы бирелмәгән. Ул 1860 елда Касыйм шәһәре Иске Бистә зиратында Хөсәен Фәезханов тарафыннан табылып өйрәнелгән. Соңыннан урыс тарихчысы В.В. Вельяминов-Зернов бу мәгълүматны үзенең тарихи хезмәтендә файдаланган[1].

Ташбилгенең куелу вакыты һижри белән 1017 ел, рәбигыль-әүвәл аеның берендә, милади 1608 елның июнь аена туры килә.

**№ 4**
**Дүртенче ташбилге тексты**
**Һижри 1009, милади 1610, июнь**

1. قال الله تبارك و تعالى ان مثل عيسى
2. عند الله كمثل آدم خلقه من تراب ثم قال لا كن فيكون
3. قال الله سبحانه و تعالى كل نفس ذايقة الموت ثم الينا ترجعون
4. قال الله سبحانه و تعالى باى ارض تموت ان الله عليم خبير
5. قال النبى عليه السلام الدنيا ساعة فجعلها طاعة
6. قال النبى عليه السلام الدنيا مزراعة الآحرة قال ا
7. انبى عليه السلام الدنيا جيفة و طالبها كلاب صدق رسول الله
8. تاريح مينك اون توقوز ييلدا رمضان آى نينك اون آلتنجى كون اوندان
9. سلطان اوغلى اوراز محمد خان دنيادين نقل قيلدى حق تعالى رحمت قيلسون

Ташбилгенең ян кырыйларында XIV–XVIII гасыр татар эпитафияләренең кырларында еш языла торган шигъри юллар бар:

3. Күрәрмен дөньйаны вәйран бары,
4. Һәмишә бакый ирмәс йук карары.

**Текстның татарча өлешенең хәзерге татар язуында чагылышы**

8. Тарих миң ун тукуз йилда, рамазан айының ун алтынҗы көн Ундан

9. солтан углы Ураз Мөхәммәд хан дөньйадин нәкыль кыйлдый. Хак Тәгаля-и рәхмәти кыйлсун.

---

[1] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. – С.492–493.

**Искәрмәләр**

Себер ханлыгын яулап алганда урыс кулына әсир төшкән Ундан солтан углы Ураз Мөхәммәд Касыйм ханлыгында 1600 елның 20 мартыннан 1610 елның 22 ноябренә кадәр хан булып торган һәм Ялган Дмитрий II тарафыннан хыянәтчеләрчә үтерелә. Аның мәете Касыйм шәһәренең Иске Бистә зиратына күмелә, кабер ташы татар мәгърифәтчесе Хөсәен Фәезханов тарафыннан табылып, укылган һәм галимнең бу хезмәте урыс тарихчысы В.В. Вельяминов-Зерновның хезмәтендә файдаланылган[1]. Текст шул басмадан күчереп алынды. Анда ташбилгенең үлчәмнәре, үзенчәлекләре, материалы хакында мәгълүмат китерелмәгән.

Таштагы һиҗри 1019 ел, рамазан аеның уналтысы, милади 1610 елның 22 ноябренә тәңгәл килә. Тексттагы 1–7 юллар гарәп телендәге аятьләрдән тора.

**№ 5**
**Касыйм шәһәре Иске Бистә зиратында**
**сакланган бишенче таш тексты**

1. ﮬﻮ الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت
2. قال الله تبارك و تعالى ان مثل عيسى
3. عند الله كمثل آدم خلقه من تراب ثم قال له كن فيكون
4. قال الله سبحانه و تعالى كل نفس ذايقة الموت
5. قال الله سبحانه و تعالى باى ارض تموت
6. قال النبى عليه السلام الدنيا ساعة فجعلها طاعة
7. قال النبى عليه السلام الدنيا مرزعة الآخرة
8. تاريح مينك تقى اون توقوز ييلدا
9. يوسف بيك اوغلى ميرزا وايل
10. سكسن تورت ياشيندا دنيادين نقل
11. قيلدى حق تعالى رحمت قيلسون

[1] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. Часть вторая. – СП(б). В типографии Императорской Академии Наук, 1864. – С.486–488.

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

8. Тарих миң такый ун тукуз йилда
9. Йосыф бик углы мирза Ваил
10. сиксән түрт йәшиндә дөньйадин нәкыль
11. кыйлды, Хак Тәгаляи рәхмәт кыйлсун.

**Искәрмәләр**

Таш Касыйм шәһәрендәге Иске Бистә зиратында 1860 елда татар галиме Хөсәен Фәезханов тарафыннан табылып укылган булган. Аның тексты В.В. Вельяминов-Зерновның тарихи хезмәтендә нәшер ителгән[1]. Бу басмага текст аның китабыннан алынып кертелде.

Тарихның һиҗри 1019 тугыз, милади 1610–1611 елларга туры килә.

Ташның үлчәмнәре һәм физик халәте тасвирланмаган. Язуы сөлес стилендә һәм күпертеп язылган булуында шөбһә юк. Бу заманда Иске Бистә зиратында Әфган хан дөрбәсеннән башка, бер таш та күренми.

## № 6
## Касыйм шәһәре Иске Бистә зиратында сакланган алтынчы таш тексты

1. قال الله تبارك و تعالى ان مثل عيسى
2. عند الله كمثل آدم خلقه من تراب ثم قال له كن فيكون
3. قال الله سبحانه و تعالى كل نفس ذايقة الموت
4. قال الله سبحانه و تعالى باى ارض تموت
5. قال النبى عليه السلام الدنيا ساعة فجعلها طاعة
6. قال النبى عليه السلام الدنيا مرزعة الآخرة
7. تاريخ مينك تقى اون توقوز ييلدا ايدارمرزا اوغلى خان على مرزا
8. ييكرمى بيش ياشنده دنيادين نقل قيلدى حق تعالى رحمت قيلسون

[1] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. – С.495.

**Текстның татарча язылган өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

7. Тарих миң, такый ун тукуз йилда Әйдар мирза углы Хан Гали мирза

8. йигирми биш йәшендә дөньйадин нәкыль кыйлдый. Хак Тәгаля рәхмәт кыйлсун!

**Искәрмәләр**

Ташбилге Касыйм ханлыгы башкаласының Иске Бистәсендәге зиратта булган, ул күренекле татар мәгърифәтчесе Хөсәен Фәезханов тарафыннан 1860 елдагы фәнни эзләнүләр вакытында табылып өйрәнелгән һәм язып алынган. Аның бу хезмәте урыс тарихчысы В.В. Вельяминов-Зерновның тарихи хезмәтендә урын алган[1].

Ташның куелу вакыты һиҗри 1019, милади белән 1610–1611 нче елларга туры килә. Таш билгенең үлчәмнәре һәм физик халәте тасвирланмаган. Бу басмага текст В.В. Вельяминов-Зернов китабыннан күчереп алынды.

## № 7
## Касыйм шәһәре Иске Бистә татар зиратыннан алынган җиденче таш тексты

1. قال الله تبارك و تعالى ان مثل عيسى
2. عند الله كمثل آدم خلقه من تراب ثم قال له كن فيكون
3. قال الله سبحانه و تعالى كل نفس ذايقة الموت ثم الينا ترجعون
4. قال النبى عليه السلام الدنيا ساعة فجعلها طاعة
5. تاريح مينك اون توقوز ييلدا ... اون برنچى
چهرشنبه يومنده ... اوعلى اق
محمد ميرزا وفات قيلدى
الحكم الله الار اوچون بو لوح تاشنى
اوغل لارى بنا قيلدى

[1] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. – С.496.

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

5. Тарих миң ун тукуз йилидә ... ун беренчи
6. чәһәршәмбе йәүмендә ........... углы Ак-
7. Мөхәммәд мирза вафат кыйлды
8. Әлхөкем Аллаһ. Алар өчүн бу ләүхә ташны
9. угланлары бина кыйлды.

**Искәрмәләр**

Ташбилгенең тексты Касыйм шәһәренең Иске Бистә зиратында 1860 елда татар мәгърифәтчесе Хөсәен Фәезханов тарафыннан табылып, өйрәнелә һәм күчереп алына.

Аның күчермәсен урыс тарихчысы В.В. Вельяминов-Зернов үзенең китабына кертеп бастыра («Часть вторая». – 497 б.).

Текстның датасы һиҗри 1019, милади белән 1610–1611 елларга туры килә.

Ташбилгенең үлчәмнәре һәм физик халәте турында мәгълүматлар юк.

Текстның баштагы дүрт юлы традицион «Коръән» аятьләреннән гыйбарәт. Дүртенче юлдан татарча җөмләләр башлана, ләкин 5, 6 җөмләләрнең кайдан башланып, кайда бетүләре күрсәтелмәгән. Бу текстта башка татар эпитафик язмаларында очрамаган «ләүхә таш» гыйбарәсе кызыклы.

## № 8
## Касыйм шәһәренең Иске Бистә зиратындагы Әфган хан дөрбәсендәге эпитафик язма

1. تاريح منكدا ايلك توقوز يل جمادى الاوالننك توقوزنچى كوننده سچقان يلنده
2. محمد عرب حان اوعلى افعان سولطان دنيادين نقل قلدى
3. الا هلأ و سنه بو عمارتنى حلالى آلطون حانم حاجم صولطان عايه لى بنا قلدردى

**Текстның хәзерге графикада укылышы**

1. «Тарих мең дә иллик тукыз йыл җөмәди әл-әүвәлнең тукызынчы көнендә, сычкан йылында

2. Мөхәммәд Гарәб хан углы Әфган Мөхәммәд солтан дөньйадин нәкыль кылды.

3. Алла ... вә сәнә... бу гыймарәтне хәлали Алтын ханым Хаҗим солтан гайали бина кылдырды».

**Искәрмәләр**

Бу эпитафик язма Иске Бистәдәге зиратта сакланган Әфган хан дөрбәсенең ишек башында куелган 40х75 см. зурлыктагы таш плитәгә күпертеп язылып, стенага беркетелгән. Плитәдәге таш язма 6 см. киңлектәге үсемлек орнаменты төшерелгән тасма белән әйләндереп алынган.

Аның тексты 2005 елның августында эпиграфик истәлекләр белән танышкан вакытта күчереп алынды[1].

Өйрәнелгән Әфган хан дөрбәсе атаклы «Шәҗәрә-и төрек» китабын язган Әбел Газый Баһадир ханның энесе өстенә корылган булган.

Аның корылу датасы һиҗри 1059, милади ел исәбе буенча 1649 нчы елга туры килә.

## № 9
## Касыйм шәһәре Иске Бистәдәге Әфган хан дөрбәсендәге ташбилгеләр. Беренче ташбилге

Йөзлегендәге текст

1. بو طاشنى افغان محمد سولطان اوچون
2. حلالى الطون حانم بنا قلدردى
3. ... اوتوز يتى [ياشندا]
4. ... وفات بولدى

Арткы стенасындагы текст

1. ...
2. ايلك توقوز صيعر يلنده

[1] Әхмәтҗанов М. Касыйм шәһәрендәге татар дөрбәләре // Татар археологиясе. – 2006. – № 1–2 (16–17). – Б.201–202.

Ташның сул як стенасындагы тексттан

1. ... ان
2. ... محمد
3. ... حان ... ن عزی
4. ... حان ...
5. ... اعاطای حان
6. رحمت الله تعالی
7. ... كل ...

**Әфган хан дөрбәсе эчендәге беренче ташбилге язмаларының хәзерге графикада чагылышы**

**Әфган ханның ташбилгесе**
**Беренче язма**
1. Бу ташны Әфган Мөхәммәд солтан өчүн
2. хәлали Алтун ханым бина кыйлдырдый
3. [йәше] утуз йити....
4. ...... вафат булдый.

**Икенче язма**
2. иллик тукуз сыгыйр йылында

**Өченче язма**
1. [Әфган Мөхәммәд солт]ан
2. [бине] Гарәб Мөхәммәд
3. ........ хан ....... газый
4. ........ хан........
5. [бине...] Агатай хан
6. Рәхмәти Аллаһ Тәгаля-и
7. .......... гел ........

**Искәрмәләр**

Әфган Мөхәммәд ханның сондыгы (ташбилгесе) бик нык җимерелгән, язмалары уеп язылган, сөлес стилендә. Аның үлчәмнәре: 33х65х161 см. Таш тарих һиҗри буенча 1059 елда, сыгыйр йылында, милади буенча 1649 елда куелган. Әфган хан 37 яшьтә үлгән. 1648 елда.

Мәгълүматлар 2005 елның августында Әфган хан дөрбәсен өйрәнгәндә ачыкланды. Аның кабер ташы дөрбә эченә кергәч сул яктан беренче булып тора.

Әфган ханның кабер ташы хакында урыс телендә түбәндәге мәгълүматлар сакланып калган:

1. Авган-Мухаммед султан
2. Сын Араб-Мухаммед хана,
3. Сын Хаджим хана,
4. Сын Агатай хана,
5. Да будеть милость Божия над ним
6. На эту постройку пятьсот рублей истрачено[1].

**Әфган Мөхәммәд солтанның кабер ташының стеналарындагы язмаларның ватылмаган вакытында профессор Корш Ф.Е. (1843–1915) тарафыннан укылган текстлары:**

1. تاريح مينك اليك توقوز صعر يلنده
2. بو قبر تاشنى افغان محمد سلطان اوچون
حلالى التون خانم بنا قلدردى سلطان اكا
لرى اوتوز يتى ياشنده مسكاوده وفات قلدى

3. سلطان افغان محمد
سلطان ابن (عرب) محمد
خان ابن
حاجم خان
ابن اعاطاى خان
رحمت الله عليه
بو عمارت اوچون يش يوز
صوم حرج قلدى

**Текстларның хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих миң иллик тукыз сыгыр йылында

[1] Шишкин Н.И. История города Касимова с древнейших времен. – Рязань: Издание газеты «Благовест», 1999. – С.198.

2. Бу кабер ташны Әфган Мөхәммәд солтан өчүн хәлали Алтын ханым бина кылдырды солтан агалары утыз йити йәшендә Мәскәүдә вафат кылды.

3. Солтан Әфган Мөхәммәд
солтан ибн (Гарәб) Мөхәммәд
хан ибн Хаҗим хан
Рәхмәти Аллаһу галәйһи
бу гыймарәт өчүн биш йөз
сум хәреҗ кылды.

Корш тексты белән безнең текстларны чагыштырганда кайбер аермалар күренә. Мәсәлән, урыс тюркологы «газый» титулын төшереп калдырган һәм «Тәгаля-и» сүзен «галәйһи» белән алыштырган.

Ташбилгедәге язма текстлар «Труды Рязанской ученой архивной комиссии». TV. (К статьи, В.К. Трутовского) басмасының кушымтасыннан алынды.

## № 10
## Дөрбә эчендәге икенче таш – Түкә солтан ташбилгесе
## һиҗри 1059, милади 1649 ел

Бу ташбилгенең бүгенге көндә бер язу әсәре дә сакланмаган. Аның бер як кырыенда бераз геометрик орнамент эзләре күренә. Димәк, бу ташбилгенең әүвәлдә язулары гына түгел, орнаментлар белән стеналары да бизәлгән булган. Ихтимал, дөрбә эче дә әүвәлдә бизәлгән булып, анда ниндидер вандаллар кереп дөрбәне һәм кабер ташларын талап, җимереп киткәннәр, кабер ташларын баш түбән җиргә әйләндереп күмгәннәр. Татар кабер өсте дөрбәләрен болай җимерү, хурлау Мәскәүдәге XVII гасыр зиратындагы, Болгар, Казан шәһәрләрендәге дөрбәләрне, гомумән бүгенге Русиядә кайда татар зиратлары булса, шунда уздырылган.

Әлеге икенче ташның XIX йөзнең икенче яртысында әле язу галәмәтләре сакланган булып, аларны урыс галимнәре укып, урысчага тәрҗемә итеп калдырганнар:

«Дата 1059. год коровы, этот надгробный камень для Тюге-Султана, сына Ишима-Султана Хаджим-Хана, Алтын-Ханым велела соорудить. Тюге Султан».

Ташның үлчәмнәре 35x70x100 см.

**Дөрбә эчендәге икенче ташның профессор Корш укыган тексты**

1. تاريح مينك اليك توقوز صغر
2. يلنده بو مقبر تاشنى حاجم خان
3. اوغلى ايشم سلطان اوغلى
4. توكه سلطان اوچون التون خانم
5. بنا قلدردى توكه سلطان

**Таш эчтәлегенең хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих минг иллик тукуз сыгыр
2. йылында бу мәкъбәр(ә) ташны
Хаҗим хан
3. углы Ишим солтан углы
4. Түкә солтан өчүн Алтын ханым
5. бина кылдырды. Түкә Солтан.

**Дөрбә эчендәге өченче таш**

Бу табут ташның да язулары җимерелеп бетә язган. Анда бер кечкенә генә язма күренә:

1. ...........................
2. بنكده ايليك توقوزده آى خانم
3. حيات ايله بينا قلدردى

**Укылышы:**

1. ..................
2. бең дә иллик тукузда Ай ханым
3. хәйәти илә бина кылдырды.

Касыйм ханлыгы тарихына багышланган бер хезмәттә бу язманың бүгенге көндә югалган-беткән сүзләре дә сакланып калган:

«Дата 1059, в год коровы надгробный камень Ай-ханым сама, при своей жизни, велела соорудить»[1].

[1] Шишкин Н.И. История города Касимова. – С.193.

Әлеге тарихта янә бер кыска гына язу булганлык та теркәлеп, аның тик тәрҗемәсе генә сакланган:

«Дата 1062 в год дракона Ай-Ханым скончалась»[1].

Бу мәгълүматлар татар эпиграфикасы тарихында, конкрет шәхес турында мәгълүмат бирүдән тыш Татарстанда XVII гасырда куелган кабер ташларының, аларның ияләре тарафыннан үзләре исән чагында ук ташбилгеләр ясатып куюларын янә бер кат раслыйлар.

## № 11
## Ай ханым эпитафик язмаларының профессор Корш укыган тексты

Беренче язма

1. تاريح مينك التمش ايكى
2. لو يلنده حاجم سلطان
3. عيالى آلتون خانم اوز
4. لرى حيات ايلنده
5. بو لوحنى بنا قلدى

Икенче язма

1. تاريح مينك ايليك توقوز انك صغر
2. يلنده بو قبر تاشنى آى خانم اوزلرى
3. حيت ايلنده بنا قلدردى

Өченче язма

1. تاريح منك التمش ايكى لو يلنده آى خانم وفات قلدى

[1] Там же.

## Текстларның хәзерге графикада чагылышы

### Беренче язма

1. Тарих миң алтмыш ике
2. ләү йылында Хаҗим солтан
3. гайале Алтын ханым үз-
4. ләре хәййәт илендә
5. бу ләүхәне бина кылды[рды]

### Икенче язма

1. Тарих миң ... ллик тукуз
анығ сыгыр
2. йылында бу кабер ташыны
Ай ханым үзләре
3. хәийәт илендә бина кылдырды

### Өченче язма

1. Тарих мең алтмыш ике, ләү йылында Ай ханым вафат кылды.

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## Чуаш республикасы төбәкләрендә сакланган XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре текстлары

### Кереш

Бүгенге Чуаш Республикасының биләгән җирләре XIII–XIV гасырларда Алтын Урда һәм XV–XVI гасырларда Казан ханлыгы карамагындагы җирләр булалар. Бу территориядә болгарлар һәм татарларның янәшә яшәгәнлегенә XIV гасырдан калган татар кабер ташлары язмалары истәлекләре дәлил булып тора. Бу тарихи чыганаклар галимнәр тарафыннан өйрәнелеп, алар турында фәнни әдәбият бар.

Традиция буенча, Казан ханлыгы дәверендә дә төбәктә татарларның яшәгәнлегенә, сан ягыннан тагын да күбрәк булган кабер ташлары дәлил була ала. Казан ханлыгы җирләре басып алынгач та, анда татар халкының авыллар булып яшәү рәвеше дәвам итә. Ул татарлар монда Алтын Урда дәвереннән бирле яшәп, үзләренең традицион мәдәниятләрен саклап килгәннәр, бу мәдәни тормыш өлкәдә XVII–XVIII гасырның икенче яртысына кадәр сүнмәгән. Соңыннан – 1740 елларда тәре йөртүчеләрнең татар һәм чуашларны көчләп чукындыру сәясәте вакытында, татар мәдәнияте бу өлкәдә сүнүгә бара. Татарларның беркадәр өлеше чуашлар белән кушылып китә, беркадәр өлеше – татарлар күбрәк, тыгызрак яшәгән Гөбнә һәм Зөя буйларына күчеп китә. Мәсәлән, Күгәй авылында Чуашия ягыннан качып, күчеп килгән татар казаклар нәселләре булган.

Чуаш Республикасында XVII–XVIII гасырлардан калган кабер ташлары үзләренең сәнгати һәм архитектур композицияләре ягыннан Казан-Касыйм эпитафия сәнгате традициясенең нык саклангалыгын күрсәтәләр.

Бу дәверләрнең мирасы соңыннан христиан фанатикларының явыз тырышлыгы белән бик күбесе ватылып юкка чыга. Калган үрнәкләре XIX–XX гасырларда татар галимнәреннән Каюм Насыйри, Хөсәйен Фәйезханов, Һарун Йосыповлар тарафыннан эзләп табылып, өйрәнелгәннәр. Берничә борынгы татар кабер ташлары Совет чорында Чуашия башкаласы Чабаксарга алып китеп андагы тарих музеена саклануга куелганнар.

Бу хезмәттә китерелгән татар кабер ташлары, татар белән чуашның тыныч күршелек белән яшәгәнлегенә тарихи документлар булып торалар. Татарлар, татар имамнары беркайчан да чуашларга көчләп ислам дине тагып йөрмәгәннәр.

## № 1
## Урмар төбәге Биш авылы ташбилгесе тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و هو الحى سيموت قال ا
2. لنبى عليه السلام الدنيا ساعة فجعلها طاعة سدق قال النبى
3. [عاليه السلام الدنيا سجين المومن جنّة الكفير]
4. ... تاريح منكدا توقسان بشدا دیرلار
5. اورسَاك اوعلى قول محمدى
6. والد اسَنَك حلا اى زاىناب ايرانلاردين
7. [دعا] اوميد اوچون بو بيلكنى قويدى تمات

**1. Текстның татарча өлешенең хәзерге язуда укылышы**

4. ... Тарих миң дә туксан бишдә дирләр
5. Үрсәк углы Кол Мөхәммәди
6. вәләде Исәнәк хәлали Зәйнәб ирәнләрдин
7. [дога] өмид өчүн бу билгине куйды. Тәмам.

**Искәрмәләр**

Ташбилгенең үлчәмнәре 17х44х102 см. Аның куелу вакыты һижри 1095 милади 1683–1684 елларга туры килә. Ташны беренче булып эзләп табып, өйрәнгән кеше Һарун Вәли улы Йосыпов. Текст аның укылышы буенча алынды[1]. Текст күпертеп язылган.

## № 2
## Шемурша төбәге Турун ташбилгесе тексты

1. تاريح مينكدا يوزدا
2. سكزدا ايردى
3. تينچورا اوعلى بيك چورا
4. دنيادين اوتتى
5. بيكبولاط مرضا

[1] Мирасханә: 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.234.

**Текстның хәзерге татар язуында чагылышы**

1. Тарих миң дә йөз дә
2. сигездә ирди
3. Тинчура углы Бикчура
4. дөньйадин үтти.
5. Бикбулат морза

**Искәрмәләр**

Ташның үлчәүләре: 35x54x140 см. Ташның һиҗри куелу вакыты 1108 ел, милади 1696–1697 елларга туры килә. Текст ташка уеп язылган, татар телендә. Аны беренче мәртәбә Һарун ага Йосыпов табып укыган. Текст аның укылышы буенча алынды[1].

## № 3
## Ямаш авылы ташбилгесе тексты

1. ...
2. ...
3. تاريح منكدا يوز اونونچى يلدا
4. ...
5. ...

**Текстның хәзерге татар графикасында укылышы**

3. Тарих миң дә йөз унунчы йылда

**Искәрмәләр**

Ташның үлчәүләре мәгълүм түгел. Һиҗри 1110 ел, милади 1698–1699 нчы елларга туры килә.

Таш текстын беренче мәртәбә Каюм Насыйри табып укып, теркәп калдырган[2].

---

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.55.

[2] Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. – Казан, 1926. – Б.52.

## № 4
## Урмар авылында сакланган беренче ташбилге тексты

Ташның үлчәүләре: 24х52х170 см. Аның йөзлегендәге язма текст ашалып, юкка чыгып бетә язган. Аннан фәкать ای ягъни «и» хәрефе генә сакланган. Ташның үлчәүләре һәм кыяфәте буенча XVII гасырның икенче яртысында куелган дип фикерлибез. Аны беренче табып, өйрәнүче Һарун Вәли улы Йосыпов булды. Мәгълүмат аның хезмәтенә таянып бирелде[1].

## № 5
## Урмар авылында сакланган икенче ташбилге

Аның үлчәүләре: 20х52х80 см. Эпитафик текст ашалып беткән, аннан фәкать صبای дигән сүз генә калган. Ул Сабай дигән кеше исеме була. Бу хезмәттә текст Һ.Йосыпов тасвиры буенча бирелә[2].

## № 6
## Урмар авылында сакланган өченче ташбилге

Үлчәмнәре: 55х140 см.

Йөзлектә текст ашалып бетеп анда бер تاریخ , ягъни тарих дигән сүз генә сакланган. Һ.Йосыпов аны XVII гасыр истәлеге дип саный. Онда искәрмә аның мәгълүматына таянып бирелә[3].

## № 7
## Урмар авылында табылган дүртенче ташбилге

Үлчәмнәре: 35х43х100 см.

Текст тәмам ашалып бетеп, бер сүзе дә сакланмаган.

Таш Һ.Йосыпов тарафыннан табылып өйрәнелгән. Бу урында аның мәгълүматлары китерелә[4].

---

[1] Мирасханә: 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.223.
[2] Шунда ук. – Б.224.
[3] Шунда ук. – Б.226.
[4] Шунда ук. – Б.227.

**№ 8**
**Канаш төбәге Шигали авылы ташбилгесе тексты**

1. ...
2. ...
3. تاريخ منكدا يوز يكرمى آلطى يل اوزوب ايردى
4. ذو الحجه آيننك آحرندا ايردى كم من مى حال اوعلى
5. دانى لا دنيادين اوتى

**Текстның хәзерге татар графикасында укылышы**

3. Тарих миңдә йөз йегерме алтыйыл узуб ирди
4. Зөлхиҗҗә айының ахырында ирди кем мин Михал углы
5. Данила дөньйадин үтти.

**Искәрмәләр**

Ташбилгенең үлчәмнәре теркәлмәгән. Аның куелу елы һиҗри 1126 ел, милади 1714 елга карый. Бу истәлекне беренче табып укучы мәгърифәтче Каюм Насыйри булды[1].

Аның әсәре аркылы ташбилге Һарун Йосыповка да мәгълүм була[2].

**№ 9**
**Канаш төбәге Шигали авылы ташбилгесе тексты**

1. ...
2. ...
3. تاريخ منكدا يوز اوتوز يلدا
4. بيكبولات اوعلى حوجا ميرزا دنيادين اوتى
5. ...
6. ...

**Текстның хәзерге татар графикасында чагылышы**

3. Тарих миңдә йөз утуз йылда
4. Бикбулат углы Хуҗа мирза дөньйадин үтти

---

[1] Каюм Насыйриның моңарча басылмаган әсәрләре. – Казан, 1926. – Б.52.

[2] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.166.

**Искәрмәләр**

Таш күләменең үлчәүләре алынмаган. Бу көндә әлеге ташның язмышы билгесез. Андагы һиҗри 1130 ел, милади 1717–1718 нче елларга туры килә.

Бу эпитафик текстны беренче эзләп табучы һәм укучы татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри булган[1].

Каюм Насыйри мәгълүматларын соңыннан Һарун ага Йосыпов күчереп алган[2].

## № 10
## Ямаш авылында табылган ташбилге тексты

1. ...
2. ...
3. تاريح منكدا يوز قريق آلتى دا ايردى كم
4. يانبولات اوعلى ساۋين دنيادين اوتى
5. ...
6. ...

**Текстның хәзерге татар графикасында чагылышы**

3. Тарих миңдә йөз кырыйк алтыда ирди кем
4. Йанбулат углы Савин (Сүвин?) дөньядин үтти.

**Искәрмәләр**

Ташбилгенең үлчәүләре сакланмаган. Аны беренче мәртәбә табып, укып, язып алып калдырган татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри булган[3]. Аның куелу вакыты һиҗри 1146 ел, милади 1733–1734 елларга туры килә.

---

[1] Каюм Насыйриның моңарча басылмаган әсәрләре. – Казан, 1926. – Б.52.

[2] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.52.

[3] Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. – Казан, 1926. – Б.52.

## № 11
## Масловка авылы ташбилгесе тексты

1. تاريخ مينكدا يو[زدا] ...
2. قريق التى دا اير ...
3. كم من بامبو ...
4. اوعلى ساﯓ[ين]
5. دنيادين ...

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих миң дә йөз дә
2. кырыйк алтыйда ир[ди]
3. кем мин Бамбу........
4. углы Сав[ин]...........
5. дөньядин..................

**Искәрмәләр**

Ташның күләм үлчәүләре 27х26х150 см. Текст уеп язылган, оста итеп эшләнмәгән. Бу таш заманында Каюм Насыйри укыган, Ямаш авылында саклана торган таш билге белән бер булса кирәк. Ул ташта Масловка ташы да һиҗри 1146, миладите белән санаганда 1733–1734 елларга туры килә.

Таш Һарун Йосыпов тарафыннан эзләп табылган һәм укылган. Басмага текст аның укылышында бирелә[1].

## № 12
## Урмар төбәге Кавал авылында табылган беренче ташбилге тексты

1. تاريخ مينكدا يوز
2. د[ا] قرق يتيدا اير
3. ديكم من ايردي ا[و]
4. علي كيلاي ...
5. قاراي طاباي
6. ... باكاي طاباي

---

[1] Мирасханә. – 72 фонд. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б. 212.

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих миң дә йөз
2. дә кырык йитидә ир-
3. дикем мин Ирәй у.
4. глы Киләй...
5. Карай, Табай
6. Бәкәй, Табай.

**Искәрмәләр**

Ташның үлчәүләре: 26x57x113 см. Куелу вакыты һиҗри 1147, милади 1734–1735 елларга туры килә.

Ташбилгене беренче табып өйрәнүче Һарун Йосыпов. Текст аның укылышы буенча алынды[1].

## № 13
## Козловка төбәге Масловка авылы (беренче) ташбилгесе тексты[2]

1. تاریح مینکدا ...
2. [ا]یللی یتی دا
3. ... ی ... من
4. ... اوعلی
5. ...
6. ...
7. ...
8. ...

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. ... [тар]их миң дә..............
2. ... илли йитидә
3. .......... и ............ мен
4. ..................... углы
5. ...............................

---

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.216.

[2] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.236.

**Искәрмәләр**

Ташбилгедә сигез юл язу булып, баштагы дүртесендә генә беркадәр язу өлгеләре сакланган. Калган юллардагы язмаларны җил ашап бетергән. Үлчәүләре: 25х55х110 см. Истәлек һиҗри белән 1157 нче милади белән 1744–1745 елларда куелган. Ташбилге беренче мәртәбә Һарун Йосыпов тарафыннан табылып тикшерелгән. Текст аның укылышы буенча бирелде[1].

## № 14
## Урмар төбәге Кавал авылында сакланган икенче ташбилге

Ташбилгенең йөзлегендә язулар ашалып беткән, укырлык түгел. Чамалап 16 юл язу булганлыгын билгеләргә мөмкин. Андагы юллардан № 4 нче юлда «Аллаһ» һәм № 15 нче юлда «углы» дигән сүзләрне генә анык итеп укырга мөмкин. Ташбилгенең үлчәүләре 30х43х115 см. Аны беренче булып табып өйрәнүче Һарун Вәли улы Йосыпов булды[2].

## № 15
## Кавал авылында табылган өченче ташбилге

Истәлекнең язулары танырлык түгел. Аның үлчәмнәре: 25х45х70 см. Ул беренче тапкыр Һарун Йосыпов тарафыннан табып өйрәнелгән[3].

## № 16
## Масловка авылында табылган икенче ташбилге

Әлеге ташның үлчәүләре 25х55х80 см. Аның язулары беткән, ватылып ята. Беренче мәртәбә Һарун Йосыпов тарафыннан табылып өйрәнелгән[4].

---

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.236.
[2] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.217.
[3] Шунда ук. – Б.218.
[4] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.214.

## № 17
## Масловка авылында табылган өченче ташбилге

Чуаш Республикасы Масловка авылында табылган өченче ташбилге ватыклары, җимерелеп беткән[1].

## № 18
## Яльчик төбәге Байгылыч авылы ташы

**Искәрмәләр**

Ташның үлчәүләре: 23x40x80 см. Эпитафик текст тәмам ашалып тузган, укырлык түгел. Ташны беренче булып тапкан һәм өйрәнгән кеше Һарун Йосыпов. Ул аны XVIII гасырда куелган дип саный.

Мәгълүматлар аның хезмәте буенча алынды[2].

---

[1] Шунда ук. – Б.215.
[2] Шунда ук. – Б.230.

# ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

## Татарстан Республикасы Казан регионы, XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре текстлары

### Кереш

Казан төбәгенә Иделнең Тау ягы һәм Казан арты районнарында сакланган XVII–XVIII гасыр ташбилгеләре турындагы мәгълүматлар керәләр.

Казан төбәге XVII–XVIII гасыр ташларын өйрәнгәндә күренекле галимнәрдән Каюм Насыйрины, Гали Рәхимне һәм Һарун Йосыповның исемнәрен дога белән искә алып китү кирәктер. Чөнки бу дәвер ташбилгеләре тарихи чыганаклар буларак күп галимнәрнең игътибарын җәлеп итмәгәннәр. Бары Каюм Насыйри гына Тау ягы һәм бүгенге Чуаш Республикасы җирләрендә булган кабер ташларына да игътибарлы булды. Ул хәтта үзенең календарьларына да беренчеләрдән булып татар зиратларын өйрәнүгә багышланган мәкаләләрен матбугатта чыгарды.

Ләкин безнең өчен иң аяныч югалту Казан кебек татарның шәһәр культурасы булган үзәге ташбилгеләрен тикшерми калдыру булды. Казан шәһәренең «Иске Бистә» дип аталган урны (хәзерге Мәскәү, Тукай, Нариман, К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Фатих Кәрим, Татарстан, Кәрим Тинчурин урамнары) зонасында XVII–XVIII гасырлардан калган ташбилгеләрне саклаган зиратны XX йөз башында бөтенләй юкка чыгару, милли тарихыбыз өчен тагы да бер зур югалту булды. Шулай ук Яңа Бистә, Бишбалта зиратлары да тарихи хәбәрләрне саклаучы архивлар иде, аларны да аеруча XX гасырда вәхшиләрчә җимерделәр һәм җимерү процессы Яңа Бистә зиратында туктаганы да юк. Аның тарихи мирас икәнен Татарстан хөкүмәте башында утырган коммунистлар да аң-

ларлык кешеләр түгелләр иде. Аларның бу эшләрен татар милләтенең киләчәк буыннары да гаепләп чыгар әле. Борынгы авыл зиратларын авыл җирләрендә дә Советлар власте изге урыннар итеп санауны туктатты, аларны сөрү җирләре итеп сөреп, тырмалап, үзләренең бабаларының гүрләре өстендә кайдадыр хөрәсәнлектә йөргән зимагурлар, чиновниклар һ.б. өчен икмәк үстерә башладылар, һәм җинаять өстенә җинаятьләр эшләү чылбыры тагын да көчәеп китте. Ата-бабаларын хурлаган бәндәләрнең йортыннан бәхет, бәрәкәт качты...

Казан артының, Тау ягының XVII–XVIII гасырлардан калган ташбилгеләре дә безнең өчен кыйммәт булган тарихи хәбәрләр саклаганнар. Мәсәлән, без алардагы язмалардан Касыйм якларыннан алып Агыйдел буйларына кадәрле булган киң далаларда милләтебезнең унике еллык борынгы төрки календаребызның актив кулланылышта булганын беләбез, социаль терминнар, тарихи шәхесләребез турындагы иң ышанычлы мәгълүматлар шул ташбилгеләрдә саклаган. Алар безнең тарихыбыз да, әдәбиятыбыз да, фольклорыбыз да, сәнгатебез дә булып саналырга лаеклы истәлекләр. Алар безнең милләт булып оешкан тарихи географик чикләре безне күрергә күзләребезне ачалар.

Бу дәвер ташбилгеләрен өйрәнүнең кирәк икәнлеген белеп Совет дәверендә олуг галимебез һәм язучы Гали Рәхим эшне башлап җибәрде. Бу темага 1930 елларда бөек археограф Сәет Вахиди да керә башлый. Ләкин кызыл террор корбанына әйләнгән бу бөек шәхеснең архивы бик начар сакланган. Аның 1927–1930 елларда комплекслы археографик экспедицияләр вакытында ташбилгеләр турында җыйган мәгълүматлары эзсез югалдылар.

Шулай да XX гасырның соңгы чирегендә һәм XXI гасыр башында милләтебез эченнән чыккан аз санлы энтузиастлар тарафыннан татар ташбилгеләр сәнгатен өйрәнү, алар турында мәгълүматлар туплау эшчәнлеге җанланып китте. Иншалла, бу эшчәнлек дәвам итәр дип өметләнәбез. Бу өлкәдә Раиф Мәрдәнов, Ирек Һадиев, Нурулла Гариф, Венер Усмановларның хәзер үк инде күзгә күренерлек хезмәтләре мабугатыбызны һәм тарихи хәтеребезне бизәүче асылташлар булып торалар. Аларның тырышлыгы белән ташбилгеләр өлкәсендәге мирасыбызны барлау һәм исәпкә алыну процессы бара.

Безнең бу хезмәтебез XVII–XVIII гасыр ташбилгеләре хәзинәсен туплау юлында шулай ук зур бер хезмәт, ләкин энтузиазмга корылып, дәүләтебездән җитәрлек игътибар булмау безне гаҗиз итә. Бу китапны коллегаларыбыз тарафыннан табылган билгесез XVII–XVIII йөз ташбилгеләре хисабына баету, матди чыгымнарның күтәрә алмаслык булуы сәбәпле, мөмкин булмады. Чөнки Казан арты авылларында гына яңадан да ачылган уннан артык ташбилгеләр, Оренбург якларындагы зиратларда саклаган дистәләрчә XVIII гасыр ядкярләрен хезмәтебезгә кертүдән шулай ук гаҗиз булдык.

## № 1
## Әтнә төбәге Иске Өҗем авылы ташбилгесе тексты

1. قال الله تعالى و ماتدرى
2. نفس باى ارض تموت و قال سبحانه
3. و تعالى كل نفس ذايقة الموت
4. تاريخ مينك يل اوزوب يكرمى دا مبارك محرم
5. ايندا ايردى [مومن حوجه] يوچونى اولماس كا الله تعالى
6. رحمت قيلسون

**Текстның рус теленә тәрҗемәсе**

1. Сказал бог всевышний: и не знает
2. Душа, в какой земле она умрет. И сказал преславный.
3. и всевышний: всякая душа вкусить смерть.
4. По летосчислению – по происшествии тысячи лет в двадцатом, в благословенный месяц мухаррам.
5. то было, Ульмас йучунь [Мумин-ходжи], бог всевышний
6. да помилует ее

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада укылышы**

4. Тарих миң йыл узуб йегермедә мөбарәк мөхәррәм.
5. айында ирди [Мөэмин хуҗа] йүчүне Үлмәскә Аллаһу Тәгаля
6. Рәхмәт кыйлсун.

**Искәрмәләр**

Бу истәлек һижри 1020, милади 1611 елның март-апрель айларында үлгән кешегә куелган. Ташның үлчәмнәре 50x116 см.

Таш Иске Өҗем авылының Ашыт елгасы буендагы иске зиратында саклана. Аны беренче мәртәбә табып өйрәнүче татар галиме Гали Рәхим булды.

Бу басмага текст В.Һарун Вәли улы Йосыпов китабыннан алынды[1].

[1] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л: Изд-во АН СССР, 1960. – Таблица № 71.

## № 2
## Татарстан Республикасы Яшел Үзән төбәге Татар Танае авылы ташбилгесе

تاريح مينكدا يكرمى ...

**Текстның укылышы**

Тарих миң дә йегерме...

**Искәрмәләр**

Бу бер ташбилгенең кечкенә кисәге – калдыгы гына. Ташбилге үзе ватылып беткән. Аның үлчәүләре дә алынмаган. Ташны беренче табып, укучы кеше Һарун Йосыпов. Ташбилге үзе һиҗри 102 (?) ел, милади белән 1612–1620 еллар арасында куелган. Текст Һарун Йосыпов укылышында алынды[1].

## № 3
## Арча төбәге Түбән Мәтәскә авылы ташбилгесе

1. قال الله تعالى و ماتدرى
2. نفس باى ارض تموت قال الله سبحانه
3. و تعالى كل نفس ذايقة الموت
4. قال النبى عليه اليسلام الدنيا مزرعة الاحرة
5. تاريح مينك يل اوزوب يكرمي
6. سِكزدا مبارك رجب اينده ايردى
7. ماماى اوعلى قماش عا الله تعالى
8. رحمت قيلسون امين رب العالمين
9. حلا[لى] قركاى كا الله رحمت
10. رحمت قيلسون امين

**Текстның хәзерге татар графикасында укылышы**

5. Тарих миң йыл узуб йегерми
6. сигиздә, мөбарәк рәҗәб айында ирди,

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау беоәмлеге. – Б.25.

7. Мамай углы Камашга Аллаһу Тәгаля
8. рәхмәт кыйлсун, амин раббел-галәмин.
9. Хәлали Кыркәйгә Аллаһу рәхмәт
10. рәхмәт кылсун, амин.

**Искәрмәләр**

Һәйкәлнең үлчәмнәре: 19x56x140 см.

Ташбилге һиҗри 1028, милади 1619 елның июнь-июль айларында вафат булган Мамай углы Камашка куелган.

Текст Һ.В. Йосыповның Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1960. – Таблица 72.

## № 4
## Арча төбәге Кадрәк авылының беренче ташбилгесе тексты

1. قال الله تعالى و ماتدرى
2. باى ارض تموت و قال الله سبحانه
3. و تعالى كل نفس ذايقة الموت
4. قال النبى عليه السلام ...
5. تاريح مينك يل اوتوز يتى دا
6. مبارك ربع الاحر ايندا
7. قاذرك مرزا اوعلى اسَنَك مرزه
8. دار فنادين دار البقاعه
9. رحلت قيلدى الله رحمت قيلسون

**Һ.Йосыпов текстындагы татарча юлларның хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих миң йыл утыз йитидә
2. мөбарәк рабигыль-ахыр айында
3. Кадрәк мирза углы Исәнәк мирза
4. дарел-фәнадин дарел-бакага
5. рихләт кыйлды. Аллаһ рәхмәт кылйсун.

**Искәрмәләр**

Татар Кадрәге авылы Арчага 9 км. ераклыкта Чулпан тимер юл станциясенә өч км. ераклыкта урнашкан. Аның зиратында ике

борынгы таш бар. Аларның берсе Камай мирза Смиленевның улы Кадрәк улына куелган (ягъни Исәнәккә). Камай мирза Казан алынгач Иске Казан җирләрен алган, аның улы Кадрәк авыл корып үзенә җир биләгән. Камай улы Кадрәк һәм оныгы Исәнәкнең шәҗәрәдә исемнәре күренми иде әле. Исәнәк 1037 елда үлгән, миладибу дата 1627 елның 10 декабреннән 1628 елның 8 январена кадәр булган вакытка керә.

Ташның үлчәүләре: 12x60x125 см., язмалар күпертеп язылган.

Бу хезмәткә текст Һ.В. Йосыпов укылышы буенча алынды[1].

**№ 5**
**Әтнә төбәге, Иске Кишет авылыннан алынган ташбилге тексты**

1. تاريخ مينكدا اوتوز يتى دا
2. مبرَك ربع الاول ايندا
3. جان صارى اوعلى اقصارى
4. دار الفنادين دار البقاعا
5. رحلت قلدى الله
6. رحمت [قيلسون]

**Текстның Һ.В. Йосыпов теркәп калдырган баш өлеше (югалган)**

1. قال الله تعالى و ماتدرى
2. ..................قال سبحانه
3. ...
4. قال النبى عليه السلام [الدنيا مزرعة] الاحرة

**Хәзерге графикада укылышы**

1. Тарих миң дә утыз йитидә
2. мөбарәк рабигыль-әүвәл айында
3. Җансары углы Аксары
4. дарелфанадин дарелбакага
5. рихләт кыйлды. Аллаһу
6. рәхмәт кылсун!

[1] Мирасханә: 72 ф. 1 тасвир, 294 саклау берәмлеге. – Б.41–42.

**Искәрмәләр**

Әлеге ташбилге 1959 елда Әтнә төбәге Иске Кишет урамында торган. Аны ул вакытта Һарун Вәли улы Йосыпов күргән булган. Аның үлчәмнәрен ул алган: 15х60х130 см. Ул вакытта ташның өске өлешендә гарәп язуы сакланган дүрт юл язу элементлары күрелгән.

Ташның югары ягындагы тимпан бизәкләре һәм дүрт юл гарәп язуындагы аятьләр ашалып бетсә, аларның асыл кыяфәтләрен китерелгән мәгълүматлар белән реконструкцияләп карарга мөмкин.

Кайсыдыр елда, ләкин 1959 елдан соң ташның йөзлегендәге тимпанны һәм язулы өлешеннән күчермә ясап, аны Татарстанның сәнгать музеена тапшырган булганнар.

1996 елның 5 ноябрендә бу күчермә экспозициягә куелган иде (бу текст 5 см. калынлыгындагы ике плитәдән гыйбарәт иде). Копиядә дә ташның баштагы дүрт юлындагы язуның сакланышы начар булганлыгын күрергә мөмкин иде. Таш үзенең бизәлеше ягыннан Казан ханлыгы дәверендәге традиция кысаларында эшләнгән. Аның һиҗри 1037 нче елы, милади 1627–1628 нче елларга туры килә. Бу ташбилге Казан артында дәүләтебез җимерелгәннән соң куелудан сакланып калган дүртенче истәлек булып тора.

## № 6
## Яшел Үзән төбәге Норлат авылы ташбилгесе тексты

1. قال الله تعالى و ماتدرى
2. نفس باى ارض ...
3. .... كل نفس ذايقة ...
4. تاريح مينكدا اوتوز ...
5. ...
6. ...
7. الله رحمت [قيلعاى]

**Ташбилгенең татарча язмасының хәзерге язуда чагылышы**

4. Тарих миң дә утыз...
5. ....
6. .....
7. Аллаһ рәхмәт кылгай.

**Искәрмәләр**

Ташның күләменең үлчәүләре: 25х50х125 см. Таш Норлат тимер юл станциясе зиратында саклана. Аның текстының зур өлеше ватылган. Ташбилгенең куелу вакыты һиҗри 103(?) елда, бу вакыт миләди белән 1621–1631 нче еллар арасына туры килә.

Тау ягы төбәге өчен бу истәлек XVII гасырдан калган иң әүвәлге ташбилге. Аны беренче табып укыган кеше эпиграфист Һарун ага Йосыпов булды. Текст аның укылышы белән бирелә[1].

## № 7
## Лаеш төбәге Имәнкискә авылында сакланган XVII йөз ташбилгесе тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قال النبى عليه السلام
2. الدنيا ساعه ت فجعَاهَه طاعت صدق قال النبى عليه
3. اللسلام الدنيا سجن المؤمينا و جنت الكفر قال النبى عليه السلام
4. الدنيا جيفت و طالبها كلاب تاريح منكدا سكسن ايكيدَا
5. ديرلار ايردى قاراج اوعلى تويكيلدي حَفظ
6. نك اوز وَاقتندا اوشبو[بي]لكينى قويدي
7. مُسلمانلاردين دُعَا اوميد اوچون كورارمن
8. دنيانى ويران بارى باقى ايرماس هميشه يوق قارارى

كتبه كيلمحمد بن اشمان

**Текстның татар телендәге юлларының хәзерге графикада укылышы**

4. ... Тарих миң дә сиксән икидә
5. дирләр ирди, Караҗ углы Туйкилди хәфиз
6. ның үз вакытында ушбу [би] лгини куйды.
7. Мөселманлардан дога өмид өчүн. Күрәрмен
8. дөньйаны вәйран барый, бакый ирмәс

Һәмишә юк карары.

**Кырында**: Кәтәбәһү Килмөхәммәд бине Ишман.

---

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – № 73 саклау берәмлеге. – Б.15.

**Искәрмәләр**

Имәнкискә авылындагы борынгы кабер өстенә куелган бу ташбилге авыл культура йорты белән йәнәшә булган бер хуҗалыкның ындырында саклана. Аның белән беренче танышу 1974 нче һәм икенче мәртәбә 1983 елның 9 сентябрендә булды, ул вакытларда ташны өйрәнеп торырга төрле сәбәпләр белән вакыт булмады. Шулай да ул вакыттагы тикшерүнең нәтиҗәсен матбугатка бирергә туры килде[1]. Бары соңыннан 2002 елда гына бу истәлекне кабат барып өйрәнергә туры килде. Ул чакны укылып, танылып бетмәгән урыннарны ачыкладык. Таш известьняктан эшләнгән. Үлчәмнәре 20х48х95 см. Язмалары күпертеп язылган. Аның куелу вакыты һиҗри белән 1082 ел, милади белән 1671\1672 елларга туры килә. Ул ташны XVII гасырда күп татар эпитафик истәлекләр авторы булган Килмөхәммәд бине Ишман эшләгәнлеккә имза куелган.

## № 8
## Яшел Үзән төбәге Олы Шырдан авылы,
## № 2нче ташбилге тексты

1. قال الله تعالى و ماتدرى و
2. باى ارض تموت و قال سبحانه
3. و تعالى كُل نفس ذَايقة الموت
4. قال النبى عليه السلام الدنيا مزرعة لاحره
5. تاريح مينكدا سكسان يتى دا مبارك ذ
6. القعده ايى نينك سكزنده يلا[ن] يلى
7. ايش اوعلى دوساى دار الفنادين
8. دار البقاعا رحلت قلدى

**Ян ягында**

كورارمن دنيانى ويران بارى
هميشه باقى ايرمس يوق قرارى

[1] Ахметзянов М.И. Тайны эпитафии // История Лаишевского края. – 1997. – С.115–116.

**Олы Шырдан авылындагы № 2 ташбилгенең текстындагы язманың татарча өлешенең хәзерге татар графикасында чагылышы**

5. Тарих миңдә сиксән йитидә мөбарәк зө-
6. лкагъдә айының сигезендә йылан йылы
7. Айыш углы Дусай дарелфәнадин
8. дарелбакага рихләт кылды.

**Ян ягында**

Күрәрмен дөньйаны вәйран бары,
Һәмишә бакый ирмәс йук карары.

**Искәрмәләр**

Ташбилгенең үлчәмнәре 25х60х130 см. Куелу тарихы һиҗри 1087, милади белән 1677 елның январь аена туры килә.

Текст гарәпнең сөлес язу стилендә күпертеп язылган.

Ташбилге беренче мәртәбә 1959 елда татар эпиграфикасы белгече Һарун ага Йосыпов тарафыннан табып укылган. Текст аның укылышы буенча бирелә[1].

## № 9
## Саба төбәге Олы Нырты авылы зиратыннан

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قال النبى عليه السلام
2. الدنيا ساعه ت فجعلها طاعة صدق قال النبى عليه السلام
3. الدنيا جيفات و طالبها كلاب تاريخ منكدا سكسان سكيزدا ايردى
4. ديرلار چيروچى اوعلى كيل محمد اوز وختيندا تووردى مسلمانلاردين
5. دعا اوميد اوچون كورارمن دنيانى ويران بارى باقى ايرمس هميشه يوق قرارى
6. كتبه كيل محمد بن اشمان

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.6.

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

3. ....... Тарих миң дә сиксән сигездә
4. дирләр ирди, Чирүче углы Килмөхәммәд үз
вахтыйнда туурды мөселманнардин
5. дога өмид өчүн. Күрәрмен дөньйаны вәйран барый,
бакый ирмәс һәмишә йук карары.
Бордюрда язылган: Кәтәбәһү Килмөхәммәд бине Ишман.

**Искәрмәләр**

Таштагы текстны без укып чыгарга үтенү белән бирелгән фоторәсем буенча укыдык. Ташның куелу вакытын белдергән һиҗри 1088 нче ел, милади 1677–1678 нче елларга туры килә. Ташның үлчәүләре: 48x85 см.

Текст 2001 елның 7 августында укылды.

## № 10
## Мамадыш төбәге Дусай авылындагы әүлия ташы язмасы тексты

1. هو الحى لا يموت و كل حى سيموت قال الله عليه السلام
2. الدنيا ساعة فجعلها طاعة صدق
3. قال الله عليه السلام الدنيا جيفات و طالبها كلاب
4. تاريح منكدا سكسان سكزدا ايردى صُن قر اوعلى [حافظ او] زى
5. ... اوشبو بيلعنى ... مسلمانلاردين دعا اوميد اوچون ...
6. باقى ايرمس هميشه يوق قارارى كتبه كيل محمد اشمان اوعلى

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. Тарих миң дә сиксән сигиздә ирди
Сонкар углы [Хафиз ү]зи
5. ушбу билгини... мөселманнарда дога өмид өчүн...
6. бакый ирмәс һәмишә йук карары.
Кәтәбәһү Килмөхәммәд Ишман углы

**Искәрмәләр**

Ташбилге белән 1973 елның 26 августында археографик экспедиция вакытында таныштык. Ул авыл эчендә киртәләп алган хәлдә, XVII гасыр татар эпитафияләренең классик үрнәге буларак сакланган хәлдә тора иде. Текстлары күпертеп язылган язмалардан гыйбарәт. Ул вакытта аның текстын тулаем укып, төзәтеп чыгарга мөмкин булмады. Хәзер аның саклануы турында мәгълүмат юк. Ул вакытларда ташбилгеләрнең үлчәмнәрен дә алмаган идем. Шулай да аның укылышы гомумән дөрес, бары танылмаган берничә сүзләрнең булмавы бер җитешсезлек.

Таш һижри белән 1088, милади хисап белән 1677\78 елларда куелган.

## № 11
## Теләче төбәге Максабаш авылы ташбилгесе тексты

1. هو الخى الذى لايموت و كل حى سيموت قال النبى عليه السلام الدنيا سا
2. عه ت فجعلها طاعه ت صدق قال النبى عليه السلام الدنيا
3. الموت ... قال النبى عليه السلام الدنيا جيفات و طالبها كلاب
4. تاريخ مينكدا توقسان ايكيدا ... ايشتيراك حافظ
5. ايشاى سوفى نك اوعلى ايردى اتا اناسى اوچون ا اوز واقتندا بيلكنى قويدى
6. ايرانلاردين [دعا اوميد اوچون] كورارمن دنيانى ويران بارى باقى ايرمس هميشه يوق قرارى

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. Тарих миң дә туксан икидә ..... Иштирәк хафиз
5. Ишәй суфыйның углы ирди, ата-анасы өчүн үз вакытында билгене куйды.
6. ирәнләрдин [дога өмид өчүн]. Күрәрмен дөньйаны вәйран бары, бакый ирмәс һәмишә йук карары.

**Текстның рус теленә тәрҗемәсе**

1. Он живой, который не умирает, все живущее умрет,
сказал пророк, – да будет мир над ним, – мир есть
2. час, так используй его в богоугодных делах, истинно.
Сказал пророк, да будет мир над ним…
3. смерть… Сказал пророк, – да будет мир над ним, – мир есть падаль и желающие его – собаки.
4. По летоисчислению в тысяча девяносто втором…
хафиз Иштирак
5. сын Ишая суфи для отца и матери при жизни своей памятник воздвиг,
6. от людей [молитв ожидая]. Вижу мир развалиной по существу, не останется он продолжительно в покое.

**Искәрмәләр**

Ташбилге һиҗри 1092 нче, милади белән 1681 елда куелган. Һәйкәлнең үлчәүләре: 22х43х95 см. Ул известьняк доломиттан эшләнгән. Язмалары кабартып язылган, өстә тимпан орнаменты уеп ясалган. Текст һәм аның укылышы мәгълүматлары Һ.В. Йосыповның «Введение в булгаро-татарскую эпиграфику». – М.-Л.: Изд-во АН СССР. 1960. – Таблица № 10 хезмәте буенча алынды.

## № 12
## Кукмара төбәге Өлги авылында саклanган ташбилге тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت
2. قال النبى عليه السلام الدنيا ساعات فجعلها طاعات
3. قال النبى عليه السلام الدنيا سجين المؤمين جنت الكفر تاريح
4. منكدا توقسان ايكدا ديرلار ايردى حمباقتى اوعلى تويكا
5. باي قَاذان شحاريندين
6. اوزى واقتندا بو بِلكنى قويْدى ايرانلاردين دعا اوميد اوچون
7. كورارمن دنيانى ويران بارى باقى ايرماس هميشه يوق قارارى
كتبه كل محمد ايشمان اوعلى

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

3. ......... .... тарих
4. миңдә туксан икидә дирләр ирди Җамбакты углы Туйкә
5. бай – Казан шәхәрендин, үзи вакытында
6. бу билгини куйдый, ирәнләрдин дога өмид өчүн.
7. Күрәрмен дөньйаны вәйран барый, бакый
ирмәс һәмишә йук карары.
8. Язды Кил-Мөхәммәд Ишман углы

**Искәрмәләр**

Өлги авылындагы ташны 1984–1985 елларда барып өйрәнгән идем. Авыл халкы миңа аны гражданнар сугышында үлеп калган кеше кабере дип сөйләде. Мин бик ышанмый гына таш янына килеп аның борынгырак дәвер истәлеге икәнен чамалап аңладым. Аның һиҗри 1092 елга дип язылган датасы милади 1681 елга туры килгәнен ачыкладык.

## № 13
## Питрәч төбәге Тау Иле авылы зиратыннан алынган ташбилге тексты

1. ...
2. تاريح منكده توقسان[ده] بيشدا ديرلار ايردى ايشبولاط
3. اقمان اوعلى اوز وحتندا بيلكينى قويدى ايرانلاردين
4. دعا اوميد .... قلعايمو...

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих миңдә туксан биштә дирләр ирди
Ишбулат
2. Акман углы үз вахытында билгини куйды ирәнләрдин
3. дога өмид ... кылгайму...

**Искәрмәләр**

Мәгълүмат ташбилгенең ватыклары төшерелгән фоторәсемнән генә укылып алынды. Техник сәбәпләр аркасында текстны

укып бетереп булмады, аны тулырак уку өчен ташбилгенең үзеннән генә мөмкин эшдер.

Ташбилгенең куелу датасы һиҗри 1095, милади 1683–1684 кә туры килә.

## № 14
## Арча төбәге Кәче Иле авылы зираты ташбилгесе тексты

1. هو الحی ... ... قال النبی ...
2. ... السلام ...
3. ... قال ... ... فجعلها ...
4. تاریح مینکدا توقصان التدا ایردی قوربان اوعلی صار
5. بای تورالارکا بارالی خلایقغا رحملی ایردی اوز
6. وقتندا بو وبیکینی قویدی ایرانلاردین دعا اومید

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада күренеше**

4. Тарих миң дә туксан алтыда ирди Корбан углы Сар-
5 бай түрәләргә бар иле халайыкга рәхимле ирди, үз
6. вакытында бу билгини куйды ирәнләрдин дога өмид...

**Искәрмәләр**

Кәче авылы зиратындагы бу ташбилге авылдан тимер юлга таба, тимер юлны чыгып Казаннан Арчага бара торган юл буендагы, уң яктагы зиратның, юл буендагы киртәсенең урта бер җирендә аңа сыгынып ук тора. Таш бик тузган. Аны теше сызлап үлгән кызның ташы дип, ул таштан бер борчак хәтле генә булса ватып алып теш арасына кыстырсаң сызлаганны баса диеп ышанганнар һәм таш плитәнең өске йөзлегеннән уртасына хәтле язулы җирләрен ватып бетерә язганнар. Эпитафия тексты бу хезмәттә беренче мәртәбә укылып җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә. Аның хакында кайбер мәгълүматлар фәнни әдәбиятта чыкты[1]. Ташның куелу датасы һиҗри белән 1096 елда, милади белән 1684–1685 елда була.

Таш 1982 елның 30 июнендә өйрәнелде, ләкин аны тагын да кабат карап чыгу кирәк. Ташның үлчәүләре 21х43х100 см. зур-

[1] Ахметзянов М.И. О лексике татарских эпитафий XVII–XVIII вв... – С.75–83.

лыкта. Язулар кабартып язылган. Язмалар башка күп татар ташлары кебек үк турыпочмаклык эченә урнаштырылганнар. Әйләндерелгән кысаның эчке үлчәмнәре 8х37 см. Ике юл арасындагы бүлем кабартып эшләнгән, аның үлчәмнәре 2х3 мм. Нокталарның диаметры 8 мм, кабартылу 2–3 мм, хәрефнең сызыклар калынлыгы 9–10 мм.

Бу материалны әзерләп бетергәч, безнең Мирасханәгә күченеп, архив фондлары тәртипкә китерелгәндә безгә Һ.В. Йосыпов архивына күз салырга туры килде. Анда без Кәче авылы зиратындагы ташның Һарун ага 1959 нчы елда укыган текстына тап булдык[1]. Ул текст буенча ташта 1–7 юл язу бар. 1–3 нче юллар бөтенләй укылмаган. 6–7 нче юллар безнең укылышның дөреслеген күрсәтә. Аның укылышында 4–5 юлларда аермалар бар, алар өлешчә генә безнеке белән туры киләләр:

«4. Туксан алтыда ирди

5. ... йар Әхмәд халайык хәлале ирди үз».

Бу очракта без үз укылышыбызны дөрес дип санап калабыз.

## № 15
## Олы Мәнгәр авылы иле ташбилгесе тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قال النبى عليه السلام
2. الدنيا ساعه ت فجعلها طاعت قال النبى عليه السلام
3. الدنيا سجين المؤمين جنت الكافير
4. تاريح منكده يوز يل ايردى باتيك بيكا قزى
5. كيشَك بيكا بيلكنى قويدى اوز زقتنده ايرانلاردين دعا اوميد

Уң як янында

كورارمن دنيانى ويران بارى

Сул як янында

هميشه باقى ايرمس يوق قرارى

[1] Мирасханә. 72 ф. – 1 тасвир. – 294 саклау берәмлеге. – Б. 40.

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. Тарих миңдә йөз йыл ирди, Батик бикә кызы

5. Кишәк бикә билгини куйды үз вакытында ирәнләрдин дога өмид

**Ташның уң як янына:**

Күрәрмен дөньйани вәйран барый,

**Икенче як янында:**

Һәмишә бакый ирмәк йук карары (диелгән язмалар эшләнгән – *М.Ә.*)

**Искәрмәләр**

Язмаларда хәрефләрне күпертеп язганнар. Ташның йөзлегендә язмалар бик нык ашалганнар, уку өчен кыен.

Текст һижри ел белән 1100, милади белән 1688–1689 елларда язылган. Текст соңгы кабат 1998 елның 15 августына укылып, язып алынды. Аңарчы аны берничә мәртәбә укып тикшергән идек.

## № 16
## Арча төбәге ташы

1. هو الحی الذی لا یموت و کل حی سیموت
2. قال النبی علیه السلام الدنیا ساعات فجعلها طاعات
3. تاریح مینکدا یوزدا بر یل ایردی یاتای اوعلی حسن
4. مور[ظا] ...اتاسن دین اوزی اوچون ایرلاردین
5. ... [دعا] اومید اوچون

**Рус теленә тәрҗемәсе**

1. Он живой, который не умирает, и все живущее умрет.

Сказал пророк, – да будет мир над ним, – мир есть час, так используй его в богоугодных делах.

3. По летоисчислению в тысяча сто первом году было. Йатая сын Хасан

4. мурза … от отца и мужей

5. молитв ожидая.

**Текстның татар телендәге өлешенең чагылышы**

3. Тарих миң дә йөз дә бер йыл ирди, Йатай углы Хәсән
4. морза ... атасындин үзи өчүн ирләрдин
5. ... дога өмид өчүн.

**Искәрмәләр**

Ташның үлчәмнәре 22х59х91.

Истәлек Арча төбәгеннән алынган булып, Татарстан милли музеенда саклана. Мәгълүматлар Г.В. Юсуповның «Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1960» исемле китабының 73 нче таблицасыннан алындды.

Һиҗри 1101 ел, милади 1689–1690 елларга туры килә.

## № 17
## Яшел Үзән төбәге Олы Шырдан авылы зираты

1. قال الله تعالى و ماتدرى
2. نفس باى ارض تموت و قال سبحان ه
3. و تعالى كل نفس دايقة الموت
4. قال النبى عليه السلام الدنيا ... حره
5. تاريخ مينكدا يوزده بردا مبراك ر
6. بع الاول ايى نينك يكرمى
7. توقوزيده دوساي اوعلى
8. حسين دار الفنادين دار البقا
9. عه رحلات قيلدي

Ташбилгенең арткы стенасында

بو لوحنى اناسى حان بيكه سى
بنا قيلدوردى قوي يلى

**Таш йөзлегендәге текстның татар телендәге сүзләрнең хәзерге язуда чагылышы**

5. Тарих миңдә йөздә бердә мөбарәк ра-
6. бигыл-әүвәл айының егерме

7 .тукузыйда Дусай углы
8. Хәсән дарел-фәнадин дарбака-
9. га рихләт кылды.

**Арткы стенадагы текст укылышы**
1. Бу ләүхәни анасы Хан бикәсе
2. Бина кыйлдурдый, куй йылы

**Искәрмәләр**

Ташның үлчәмнәре 28x60x130 см. зурлыкта. Известьняктан ясалган. Язмалар күпертеп язылганнар. Ташны беренче булып тарих фәннәре кандидаты Һарун Вәли улы Йосыпов 1959 елда укыган. Текст галимнең шәхси фондыннан алынды[1]. Һиҗри 1101, милади 1689 елның декабре.

## № 18
## Биектау төбәге, Туктамыш авылы зираты ташбилгесе тексты

1. هو الحى الذى لا يمو و كل حى سيموت
قال النبى عليه السلام الد
2. نيا ساعات فجعلها طاعت قال النبى عليه
السلام الدنيا ... من المؤمن و جنت الكفر
3. تاريح بر منكدا بر يوزده اوج يل ايرديكيم ابايك ...
4. صوفى بو بلكنى قويدى اوز واقتندا دعا
اوميد اوچون ايرانلاردين

**Текстның татарча укылышының хәзерге татар графикасында чагылышы**
3. Тарих бер миң дә, бер йөздә өҗ йыл ирдиким
Әбайык...
4. суфый бу билгини куйдый үз вакытында
дога өмид өчүн ирәнләрдин.

[1] Мирасханә. – 72 фонд. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б. 4–5.

**Искәрмәләр**

Бу текст язылган плитә известьняктан ясалган. Үлчәмнәре 20х42х160 см. Язмалар күпертеп язылган, кыршылган урыннары бар. Ташның куелу датасы һиҗри 1103 ел, милади 1691–1692 елга туры килә.

Таш 1959 елда Һарун Йосыпов тарафыннан фәнни экспедиция вакытында табылган һәм укылган. Мәгълүматның чыганагы галимнең шәхси фондыннан алынды[1].

## № 19
## Мамадыш төбәге Олыяз авылы янында саклanучы борынга ташбилгесе тексты

1. هو الحي الذى لا يموت و كل حى سيموت قال النبى عليه
2. السلام الدنيا ساعات فجعالها طاعات صدق قال النبى
3. عليه السلام الدنيا سجنون المؤمن و جنات الكافر قال النبى
4. عليه السلام الدنيا جيفات و طالبه كالاب تاريح
5. منكدا يوزدا بشدا ديرلار ايردى بي محمدكا اوعلى دوسكا بيلكى
6. قويدى ايرانلاردين دعا اوميد اوچون

**Тексттагы татар телендә язылган өлешенең графикада чагылышы**

4. Тарих

5. миң дә йөз дә бишдә дирләр ирди Би Мөхәммәдкә
углы Дускә билге

6. куйды, ирәнләрдин дога өмид өчүн.

**Искәрмәләр**

Олыяз авылының бу истәлеген без барып күрмәдек. Аның фотосүрәтен безгә Олыязның, Кара бәк буыннарыннан Таңатар нәселеннән булган Рөстәм дигән егет китерде. Без шул сурәт буенча ташның язмасын укыдык. Ул авылда – Олыязда яшәүче әтисе һәм аның кордашлары белән борынгы ташны аякка бастырып, аның

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 294 саклау берәмлеге. – Б.9.

тирәсенә чардуган корганнар, борынгы истәлеккә – бабаларына халык ихтирамы уятканнар.

Ташбилгенең үлчәүләре 21х57х102 см., тексттагы һәр юл язу кабартып эшләнгән турыпочмаклы дүртпочмак эчендә. Дүртпочмакның иңе 44 см, биеклеге 7,5 см. Ике юл арасындагы кабартып эшләнгән бүлемнең киңлеге 3 см, озынлыгы 44 см. Таш известьнякта эшләнгән.

Текст 2009 елда укылып, матбугатка беренче мәртәбә хәзерләнде. Ташның куелу вакыты һиҗри 1105 ел, милади 1693–1694 елларда булган.

## № 20
## Кайдан табылуы турында мәгълүм булмаган XVIII йөз татар ташбилгесе тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قال النبى
2. عليه السلام الدنيا ساعات فجعلها طاعات
3. قال النبى عليه السلام الدنيا ... المؤمينا
4. و جنت الكافر قال النبى عليه السلام
5. الدنيا جيفات و طالبها كلاب تاريح مينكدا
6. يوزدا التيده ديرلار ايردى ... مورضا
اوعلى ... مورضا ...

**Текстның урыс теленә тәрҗемәсе**

Дата: 1694/95 г.

«1. Он живой, который не умирает, все живущее умрет.

Сказал пророк, –

2. да будет мир над ним, – мир есть час, так используй его в богоугодных делах.

3. Сказал пророк, – да будет мир над ним, – мир … мусульм[ан]

4. и рай неверных. Сказал пророк, – да будет мир над ним, –

5. Мир есть падаль, и все желающие его – собаки.

По летоисчислению в тысяча

6. сто шестом было … мурзы

7. сын … мурза …

**Текстның татарча өлешенең хәзерге татар графикасында чагылышы**

5. .......................Тарих миң дә
6. йөз дә алтыйда дирләр ирди.................. морза
7. углы................морза................

**Искәрмәләр**

Текст Һарун Йосыпов хезмәтеннән күчереп алынды[1]. Текстның язылу вакыты һиҗри белән 1106 ел, милади белән 1694\1695 ел.

## № 21
## Биектау төбәге Ташлы Кавал авылы уртасында, юл кырыеndагы ташбилге тексты

1. قا الله تعالى و ماتدرى
2. نفس باى ارض تموت قال الله سبحانه
3. ... الموت
4. ...
5. ...
6. تاريخ تمام منكدا ...
7. مبارك ربيع الاول ايندا ايرديكيم
8. اعيش باى اوعلى كيلدى باى
9. اوزى اوچون [بنا قي]لدى

Икенче як стенада

1. بو لوحنى باى كيلدى [بنا قيلدى]
2. ...

**Текстның татар телендәге өлешенең укылышы**

6. Тарих тәмам миң дә..........
7. Мөбарәк рабигыль-әүвәл айында ирдиким
8. Агыйш бай углы Килдибай
9. үзи өчүн [бина кыйл]дый.

---

[1] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л. – № 11 таблица.

**Икенче як стенада**

1. Бу ләүхәне Байкилде бина кыйлды
2. ...

**Искәрмәләр**

Таш – известьняк, текст язмалары кабартып эшләнгән. Үлчәмнәре 19х47х160 см, ул урталай сынып чыккан, такталар белән беркетелгән. Текстта еллар күрсәтелгән урын өлешчә ватылган. Анда Һиҗри ел мең дә дип бетә. Аның датасы 1680–1690 еллар тирәсендә булган дип фараз итәбез. Ташбилге 1959 елда Һарун Йосыпов тарафыннан табылган һәм өйрәнелгән[1].

Плитәнең икенче ягында күпертеп ясалган штампта, гарәп хәрефләре белән «Бу ләүхәне Байкилде...» дигән бозылып беткән ике юллык кыска җөмлә язылган булган.

## № 22
## Питрәч төбәге Чыты авылы ташбилгесе тексты

1. ...
2. ...
3. قال ... سبحانه ...
4. ...
5. تاريخ [مينكده] ...
6. التنجى ... بايسارى
7. ... حاجى دار الفنا
8. دين [دار البقاعا] رحلت قلدى
9. رحمت ... سون

**Ташбилге текстының хәзерге графикада чагылышы**

5. Тарих...
6. алтынҗы ...... Байсары...
7. ..... хаҗи дарел фәна-
8. дин [дарел бәнага] рихләт кылды.
9. рәхмәт... [әйлә]сүн.

---

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 294 саклау берәмлеге. – Б. 10–11.

**Искәрмәләр**

Ташның күләм үлчәүләре: 18x45x140 см. Аның куелу вакыты 1...6 ел XVII йөзнең ахыры.

Ташны беренче табып, укып һәм язып алучы Һарун Йосыпов булган. Текст аның архив кулъязмасыннан алынды[1].

## № 23
## Яшел Үзән төбәге Бакырчы (Әрә Бакырчысы) авылы ташбилгесе тексты
## Беренче таш (арткы стенасында)

1. بو لوحنی
2. ... تابان بك اوعلی
3. بالتاج ...

**Текстның хәзерге графикада чагылыш**

1. Бу ләүхәне –
2. ... Табан бәк углы
3. Балтаҗ...

**Искәрмәләр**

Үлчәүләре: 20x67x120 см. XVII йөз ташы, текстын тәмам җил ашап бетергән.

Ташбилге беренче мәртәбә Һарун Йосыпов тарафыннан табылып, аның тарафыннан өйрәнелгән.

Текст аның укылышы буенча алынды[2]. Г.Юсупов тарафыннан ташбилгенең фотосүрәтендә, аның сул як ягында язулар күренә. Ләкин алар укылмыйча калган.

## № 24
## Бакырчы (Әрә Бакырчысы) авылы. Икенче ташбилге тексты
## Арткы стенадагы язу

1. بو لوحنی حلالی یش بتِك بنا قیلدی

---

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.172.
[2] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.219.

**Язманың хәзерге татар графикасында чагылышы**

«Бу ләүхәни хәлали Йәшбатик бина кыйлдый».

**Искәрмәләр**

Ташның йөзлегендәге язма текстны җил ашап бетергән. Фәкать арткы стенасында гына бер җөмлә сакланып калган.

Ташбилгенең үлчәмнәре: 43x75.

Әлеге ташбилгене беренче булып Һ.В. Йосыпов эзләп тапкан һәм тикшергән. Текст аның укылышында бирелә[1].

## № 25

## Яшел Үзән төбәге, Норлат авылы зираты ташбилгесе тексты

1. قال الله تعالى و ماتدرى
2. نفس باى ارض تموت قال سبحانه
3. و تعالى كل نفس ذايقة الموت
4. قال النبى عليه السلام الدنيا مزرعة الاحرة
5. تاريح منكدا يوز يكرمى ايكيدا
6. ...

**Текстның рус теленә тәрҗемәсе**

Дата: 1710/11 г.

1. Сказал бог всевышний: и не знает
2. душа, в какой земле она умрет. Сказал преблагой
3. и всевышний: всякая душа вкусит смерть.
4. Сказал пророк, – да будет мир над ним, – мир есть пашня конечной жизни.
5. По летоисчислению в тысяча сто двадцать втором.
6. …

**Текстның татар телендә язылган өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

5. Тарих миң дә йөз йегерме икидә

[1] Мирасханә. – 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлге. – Б.220.

**Искәрмәләр**

Таш беренче мәртәбә татар галиме Һарун Йосыпов тарафыннан табылып, өйрәнелеп матбугатка чыгарылды. Аның куелу датасы 1710–1711 елга карый.

Норлат зиратында куелган бу таш Казан ханлыгы ташлары традициясендә эшләнгән һәйкәлләрнең соңгысы. Моннан тыш татар эпиграфик культурасының 40 елларга сузылган торгынлык чоры башлана. Норлат һәйкәле ак таштан кисеп, язмалары күпертеп эшләнгән. Аның үлчәмнәре 21x58x112 см. зурлыкта.

## № 26
## Биектау төбәге Сая авылы

1. هجرة النبى ...عليه السلام
2. تاريح بنكده يوز يكرمى اوچنچى
3. يلده شيح بحشنديار صوفى
4. دار فنادن دار بقايه كوچتى

**Текстның хәзерге татар графикасында укылышы чагылышы**

1. Һиҗрә-и нәби Галийәссәлам
2. Тарих беңдә йөз йегерме өченче

3 йылда Шәйех Бәхшәндийар суфый

4. дар фанадин, дар бакая күчти.

**Искәрмәләр**

Сая авылы кырындагы әүлия кабере ташы. Саядан читтә тау битендә, әйләнәсе рәшәткә белән әйләндереп алынган, янында кечкенә генә өй салып куелган, ике агач үсә. Кабер әйләнәсенә кечкенә генә җилкапкадан керәсе. Таш шактый җимерелгән, калкытып гарәп язуының сөлес элементы белән язылган. Янында текст тулы күчерелмәгән яңартылган ташбилге тора.

Таш 20 см. биеклектәге дүртпочмаклы күтәртмә өстенә куелган. Эпитафия үлчәмнәре 22x38,5x96 см.

Платформа (күтәртмәнең) үлчәмнәре 20x79x96 см.

Каберлек әйләсендә тотып алынган мәйдан 950x950 см.

Йорт алачык янында акча җыйнау (ягъни сәдака салуга) өчен калай сандык та ясап куелган.

Ташның куелу вакыты – һиҗри 1123 ел, милади белән 1711–1712 елларга туры килә.

## № 27
## Биектау төбәге Өлә-Казаклар авылындагы беренче ташбилгенең тексты

1. مرثيۀ بيك قل بن ابراهيم
2. برجوانچى تمعاسنك تربسيدور بو مزار
3. ايلمش نازك وجودين خاكدور روزكار
4. عَاجز ابياتم هم مسكينلاره لُطف موكّرام
5. ايْلا ايرلارى حَسْن خلقى تنميوب اى محترم
6. قل كر برديم سنكا كل كبى آچيب دهان
7. نحرم اولوب سَنِكين كونكيل غمكين اويردى شادمن
8. نچه مسجدلار بيردستان ملتبس كلا برلان
9. ايليوب هرايلاّره چيكمش ايردى رنجُ عنَا
10. نچه كز شاهننك حضورينه وار و بن عرض حال
11. ايا يدوب تابدى خَلايقينك مرادين مركمال
12. چقسه كراطّهَ بُنو بن شَوكتيله دوستان
13. فخر ايدوبلر اورنبورده عيرتندان دوشمان
14. عالم لر فاضل لار ايله يار اولب روان شَبان
15. دنكلار ايدى عِشِقلار وعْظر ايل هم معان
16. عاقبت دشمان الندان زهر اچون تاحر
17. كتدى بوُ دار فنادن بر دعا قيل اى قباد
18. ادى بيك قل اِتسى ابراهيم ايدى ادهام
19. تاريح اوشبو ١١٦٩ قرق بر ياشنده

**Текстның хәзерге татар графикасында чагылышы**

1. Мәрсийә-и Биккол бине Ибраһим
2. Бер җуаныч тамгасының төрбәсидүр бу мазар
3. Әйләмеш нәзек вөҗүдин хакдур рузгяр
4. Гаҗиз әбьйатем һәм мескинләрә лотыф мөккәрәм
5. Илә ирләри хөсне холкы тәнмийүб и мөхтәрәм

6. Колкяр бирдим сиңа гөл кеби ачыйб дөһан
7. Нәрем улуб сәникин күнгил гамькин ойырды шадмән
8. Ничә мәсҗедләр бир дәстән мөлтәбәс килә бердән
9. Әйләйүб һәм илләрдә чикмеш ирди рәнҗү гына
10. Ничә гиз шаһның хозурыйна варубән гарыз халь
11. Айа йидүб табды халайыкының морадин мирка-мал
12. Чыкса гәр атта бенүбән шәүкәтилә дустан
13. Фахир идүбләр Орунбурда гайрәтендән дошман
14. Галимләр, фазыйллар илә улыб рәван шәбан
15. Дыңлар иди гыйшыйклар вә Газраил һәм мәган
16. Гакыйбәт дошман әледән Зөһрәчүн Тахир
17. Китди бу дарфанадан бер дога кыйл и кобад
18. Ады – Биккол, әтисе Ибраһим иди Әдһәм
19. Тарих, ушбу 1169, кырык бер йәшендә.

**Искәрмәләр**

Бу кабер ташы Татарстанның Биектау төбәге Өлә-Казаклар авылы зиратында саклана. Аның куелу датасы һиҗри 1169 нчы, милади 1755\1756 елларда була. Таш тексты белән 1973 елда ук таныша башлаган идек. Тәмам текстны уку 2002 елда гына мөмкин булды. Таш куелган шәхес Батырша хәрәкәтендә катнашы булып, мәчетләр җимерү көчләп чукындыруларга каршы булып патша белән очрашуларга ирешкән зат булып, 41 яшендә Оренбургта үтерелгән. Аның кабер ташын бай эчтәлекле текст язып Татар Каргалысында имам, ташлар кисеп ясаучы, ювелир остасы булган Исхак бине Габделкәрим ясаган.

Ташның үлчәләре – 23х45,5х140 см. зурлыкта. Ак известь ташыннан кисеп ясалган. Язулары кабартып язылган, беркадәр өлеше җиргә баткан. Әүвәлдә аның зур кызыл яндырылган кирпечтән ачык дөрбәсе дә булган. Хәзер дә бер-ике ниргә стенаның калдыгын чамаларга була. Ташъязманың тексты матбугатта беренче мәртәбә 2006 елда басылып чыкты[1].

---

[1] XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 194–195.

## Сүзлекчә

1. Мәрсийә – үлгән кешеләргә, алар өчен кайгыртып язылган шигъри әсәр
2. Тамгасы – билгесе
3. Төрбәси – мавзолейсы
4. Мазар – зират
5. Вөҗүдин – туганын
6. Рузгяр – заман, яшәү
7. Гаҗиз – бердәнбер
8. Әбьйатем – бәйетем
9. Лотыф – гүзәллек, мәрхәмәт
10. Мөкәррәм – хөрмәтле
11. Илә ирләре – Өйлә авылы ирләре
12. Хөсне холкы – матур холкы
13. Тәнлийүб – үстерүб
14. Колкяр – колларча
15. Дөһан – авыз ачыб
16. Нәрем – кадерле
17. Гамькин – уйга чумып
18. Ойырды – рәхәтлектә йөрде, оеды
19. Шадмән – шатлык белән
20. Бир дәстән – бер кулдан
21. Мөлтәбәс – бозылды, кушылды
22. Рәнҗү – авырлык күрү
23. Тиз – рәт, кат
24. Гарыз халь – хәлне белдереп
25. Айа йидүб – айларга җитеп
26. Атта бенүбән – ат менеп
27. Мәукәтилә – куәт белән
28. Фахир идүбләр – мактап
29. Фазыйллар – галим, укымышлы
30. Рәван – уздыру, узу
31. Шәбанә – кичәләр
32. Мәган – бергә
33. Гакыйбәт – азагы
34. Әлендән – кулыннан
35. Дирфанадан – бу дөньядан
36. Кобад – бөек

## № 28
## Биектау төбәге Өлә-Казаклар авылы зиратыннан икенче ташбилгенең тексты

1. مرثیهٔ ابراهیم بن عَاَلْکَای
2. ای کچه ن عاملر یوزونده سیر ایدرسن روزکار
3. کَلسَ◌َنکز اوشبو حزنه ایلایوب بردم قرار
4. اچو بن عِبرات کوزنکنی جانب پرور دکار

5. بحش ايده رسن روحينه چون بر دعَاسن ايحتيار
6. ايسمى ابراهيم اتاسى ننك دَحى الكايجان
7. بينكده يوز يتمش بشنجى يلده تكاتدى جهان
8. سوردى يتمش التى يللار عمر دولتده معن
9. نعْمت ايله توُپلايوبن حاصَ عامى صبح شاد
10. تيكدى چون تيز اجل هم خاغان اولدى كباب
11. هچ وجودندان نشان قالمَايور اولدى تراب
12. كاتيبى اسحاق ايرور هم وَالدى عبد الكريم
13. يادين سن امت ايلاين يا عمِل فاضيل

**Ибраһим бине Әлкәй эпитафик (икенче таш) текстының хәзерге татар графикасында чагылышы**

1. Мәрсийә-и Ибраһим бине Әлкәй
2. И кичән гам гамьләр йөзүндә сәйер идәрсән рузгяр
3. Килсәңез ушбу хәзинә әйләйүб бер дәм карар
4. Ачубән гыйбрәт күзеңни җанәб пәрвәр дигәр
5. Бихиш идәрсән рухыйна чүн бер догасыйн ихтыйар
6. Исеме Ибраһим, атасыйның дәхи Әлкәйҗан
7. Биң дә йүз йитмеш бишенҗи йылда төкәтди җиһан
8. Сөрди йитмеш алты йыллар гомер дәүләтдә мәган
9. Нигъмәт илә туплайубән хассә гами сабах шад
10. Тигди чүн тиз әҗәл һәм хаган улдый кәбаб
11. Һич вөҗүдиндән нишан ка[л] майуб улдый тораб
12. Кятиби Исхак ирүр вәляди Габделкәрим
13. Йадин син өммәт әйләйен йа гамил-фазыйл

**Искәрмәләр**

Ибраһим бине Әлкәй кабер ташының табылу тарихы Өлә-Казаклар зиратындагы Биккол бине Ибраһимныкы белән бер вакытта, бергә булды. Бу ташның үлчәмнәре 22х46х134 см. Ташның язылу вакыты һиҗри 1175, милади 1761\1762 елларга туры килә.

Ибраһим бине Әлкәй мәдрәсә тоткан мөдәррис булып, аның хәтта ул үлгәч тә мәдрәсәсе аның исеме белән шөһрәтле була. Ибраһимның кабер ташын да Каргалы остасы Исхак бине Габделкәрим язган. Ул – ташларга язылган мәрсияләрнең авторы. Моннан тыш Исхакның язган мәрсияләре аның Каргалыда ясаган

ташларында язылганнар. Исхакның атасы Кукмара төбәгендә туган зур дин галиме Габделкәрим бине Балтай булуы мәгълүм.

Исхак тарафыннан Түбән Бәрәскә авылының атаклы мөдәррисе Ибраһим Бәрәскәвинең дөрбәсендә дә гарәп һәм татар телләрендә язылган гүзәл эшләнешле зур габаритлы кабер ташы сакланган.

Ибраһим бине Әлкәйгә багышланган мәрсия безнең тарафтан «XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия» китабында нәшер ителде[1].

### Сүзлекчә

1. Кичән – үткән
2. Сәйер идәрсең – тамаша итсәң
3. Рузгяр – узганнар
4. Пәрвәр дигәр – яратучы, бар итүче Аллаһ
5. Төкәтди – бетерде
6. Хассә – тоючы
7. Сабах – таң, иртә
8. Тигди – тиде
9. Кәбаб – яндый утта
10. Нишан – билге
11. Тораб – туфрак
12. Кятиби – язучысы
13. Вәляди – нәселе
14. Йадин – хатирәсен, ядкярен
15. Өммәт – берлек
16. Гамил – кардәш, туган

### № 29
### Яшел Үзән төбәге Мулла Иле зираты ташбилгесе

1. ١١٩٩ سنه وفى شهر محرم
2. و ما توفيقى الاّ بالله
3. الدنيا فنا و ما فيها فناء
4. انَّ هذه المتوفى عبدُ الحالق بن
5. عبد الباقى بن ملا سيد بن قاسم
6. بن اشمحمد حافظ بن اشبولاط بن
7. ايرحسين بن تلاش بن شيح بى بن
8. طامطى حطايى البلعارى

[1] XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – 195–196 б.

**Текстның урыс теленә тәрҗемәсе:**

Дата: 1784/85 г.

1. В 1199 году месяце мухаррам.
2. Благополучие только от бога,
3. мир тленен и все в нем тленно.
4. Этот покойник ʿАбд-ал-Хāлик, (его) сын
5. ʿАбд-ал-Бāки (его) сын мулла Сайид (его) сын Касым
6. (его) сын Ишмухаммед-хāфиз (его) сын Ишбулат (его) сын
7. Ирхусайн (его) Тилаш (его) сын Шайх-бий (его) сын
8. Тамты Хытāйи ал-Булгāри

**Текстның татар телендә язылган өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. ......... Габделхаликъ бине
5. Габделбакый бине мулла Сәйед бине Касыйм
6. бине Ишмөхәммәд хафиз бине Ишбулад бине
7. Ирхөсәйен бине Теләш бине Шәйех би бине
8. Тамти Хатайи әл-Болгари

**Искәрмәләр**

Бу таш борынгы татар кабиләсе Катай (Хатай) ыруларының Болгар Олысында яшәүләрен күрсәтүче документ.

Таш һижри 1199 елның мөхәррәм аенда, ягъни милади 1784 елның ноябрь 11 – декабрь 11 көннәре арасында вафат. Ташның үлчәүләре алынмаган. Фото һәм укылыш Һарун Йосыпов китабы буенча алынды[1].

## № 30
## Әтнә төбәге Югары Бәрәскә авылы зиратындагы дөрбә эчендәге ташбилге тексты

**Текстның укылышы**

1. بسم الله الرحمن الرحيم مبدى اسماء الحسنى القديم
2. و قال الله تعالى كل من عليها فان و يبقى
3. وجه ربك ذوالجلال و الاكرام و قال [ا]
4. لنبى صلى الله عليه و سلم ان اولياء الله

[1] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – Таблица № 76.

5. لا يموتون بل ينقلون من دار الى دار لاحول و لا
6. قوة الا بالله العلى العظيم فهذا مرقد
7. الشيح ابراهيم بن يوسف برسكايى انار الله
8. مضجعه و عفر لمن داره الى يوم القيمة تاريح
9. منكده يوزدا طوقسان سكيزنچى يل دا شوال
10. اى نك بشنچى كوننددا دار فنادين دار بقايه نقل
11. اتندى رحم الله عليه رحمة قيلسون

**Текстның рус теленә тәрҗемәсе:**

Дата: 1785 г., 23 августа, среда.

1. Именем бога милостивого, милосердного, начало красивых имен вечности.

2. И сказал бог всевышний: все, что на ней (на земле), бренно, и останется вечно (лишь)

3. лицо господа твоего, обладателя величия и почтения. И сказал

4. пророк, да благословит его бог и будет над ним мир, поистине святые бога

5. не умирают, а переселяются из мира тленного в мир вечности. Все изменяется от бога,

6. и нет силы, кроме бога великого, высокого. Это могила

7. шайха Ибрахима, сына Йусуфа Бараскайи. Да осветит бог

8. обиталище – место лежания его до дня воскресения (мертвых). По летосчислению

9. в тысяча сто девяносто восьмом году, шавваля

10. месяца пятого дня из мира тленного в мир вечности переселенный

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

8. Тарих
9. миң дә йүз дә туксан сигизинчи йылда шәүвәл
10. айның бишенче көнендә дар фанадин дар бакайа нәкыль
11. итенди. Рәхим Аллаһу галәйһи рәхмәтә кыйлсун.

**Искәрмәләр**

Югары Бәрәскә зиратында зур дөрбә эчендәге бу ташның үлчәмнәре 18х75х180 см. Ул тоташ известь таштан эшләнгән, саклanышы яхшы. Ләкин бу авылда зур мәдрәсә тотып XVIII гасырда 40–50 еллар дәрес әйткән Шәйех Ибраһим Бәрәскәвинең ядкяренә төкереп карыйлар, ташны бастырып куйган җиреннән аударып, аны чүп арасында аунатып яткыруга беркемнең дә эче пошмый, чөнки шушы кеше үз акчасына моннан 250 еллар элек салдырган таш мәчетенә дә игътибар юк. Яхшы адәмнәрен, аларның хезмәтләрен оныткан халыкка ни дисең...

Текст Һ.В. Йосыпов хезмәте буенча алынды[1].

## № 31
## Малмыж төбәге, Яңа Смәил авылы зираты ташбилгесе тексты

1. ... ... ...
2. شهر ذالحجه اوتاكان بن عيسى
3. فى سنه ٣٦٧١

**Малмыж төбәге, Яңа Смәил авылы зираты башбилгесе язмасының хәзерге графикада чагылышы**

1. ... ... ...
2. шәһр зөлхиҗҗә Үтәгән бине Гайсә
3. фи сәнә 1763.

**Искәрмәләр**

Бу таш турындагы хәбәр Киров өлкәсендә татар телендә чыгарыла торган «Дуслык» газетасы битендә Яңа Смәил авылы укытучысы Гадилә Габдерәхимова тарафыннан язып чыгарылган «Кабер ташлары тере тарих» исемле мәкалә һәм ташбилге фоторәсеме буенча алынды. Мәкаләдәге кайбер кимчелекләр фоторәсем буенча төзәтелеп бирелде[2]. Әлбәттә ташның фотосурәте яхшырак сыйфатлы булса, информация дә тулырак булыр иде.

[1] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – Таблица № 77.

[2] Габдерәхимова Гадилә. Кабер ташлары тере тарих // Дуслык. – 2007. – № 3 (887). – 15–21 гыйнвар.

# ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

## Минзәлә регионы XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре текстлары

### Кереш

Минзәлә төбәге турында сүз барганда, бу очракта барыннан да элегрәк әүвәлге Минзәлә өязенә кергән авыллар күз алдында тотыла. Моннан тыш Алабуга һәм Сарапул, беркадәр Бөгелмә, Бәләбәй өязләренә кагылышлы татар авыллары да Минзәлә ягы белән бәйләнгән. Минзәлә өязенең төп халкын нократ татарлары тәшкил итә. Алар белән янәшә Нугай Урдасыннан һәм Казан ягыннан күчкән татарлар саны да аз түгел. Бу материаллар төбәкнең зур гына шәҗәрәләр хәзинәләре мәгълүматларына таянып фикерләүләр нәтиҗәсендә әйтелә. Төбәк халкы традицион шәһәр һәм утрак тормыш алып барган мәдәният вәкилләреннән гыйбарәт. Шушы сәбәптән бу регионда традицион кабер ташлары культурасы да сакланган. Касыйм, Казан, Нократ якларындагы дәүләтчелек идеясе белән тәрбияләнгән татарлар культурасы Минзәлә төбәгендә төп элемент булып тора. Шул сәбәптән бу якларда мөстәкыйль татар дәүләтләре мәдәниятенең аерылгысыз бер өлешен тәшкил иткән ташбилгеләр кую традициясе XVII–XVIII гасырларда кискен өзеклекләр кичермичә сакланып килгәннәр.

Алабуга, Әгерҗе, Менделеев, Актаныш, Мөслим төбәкләрендә куелган XVII йөз кабер ташлары алар татар шәҗәрәләрендәге материаллар белән дә тәңгәлләшәләр. Төбәктәге ташбилгеләрдә татар шәҗәрәләреннән Кара бәк, Кирәйет би, Шәйех Дирбеш, Меңнәр шәҗәрәләренең бабаларының шактый гына исемнәре шул Алабуга, Менделеев, Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә, Азнакай, Ютазы төбәкләрендәге XVII–XVIII гасыр татар эпиграфик истәлекләрендә дә теркәлеп калганнар. Мөслим төбәгендәге Катмыш авылы

янындагы борынгы зират ташлары Татарстанның Арча, Балтач якларыннан XVII гасыр урталарында күчереп утыртылган нугайбәк татарлары тарихы чыганаклары булып сакланып калганнар. Кызганычка каршы татар эпиграфик истәлекләре дә, кулъязмалар кебек үк, соңгы дистә елларда табигый һәм кеше факторы сәбәпле тиз җимерелә һәм юкка чыга баралар. Моның мисалларын безгә аеруча Мөслим, Әгерҗе, Әтнә төбәкләрендә күрергә туры килде. Мисал өчен Әтнә төбәгендәге борынгы Иске Мәнгәр авылы кырындагы XVI гасыр зират ташбилгеләре безнең гомердә генә дә инде югалып бетә язды. Мөслим төбәгендәге Катмыш авылы кырында XVII–XVIII гасырлардан калган зиратның унбишләп ташыннан икесе калды микән инде?!

Кабер ташларының, дөрбә корылмаларының җимерелеп бетү хәлендә булуында аларның сакланышы турында Татарстанда татар мәдәниятенә карата бер кыргый битарафлык сәясәтенең чагылышы гаепле. Меркантилизм чире белән агуланып, барлык күзәнәкләренә кадәр сукырайган хакимнәр заманы – халкыбыз, мәдәниятебез өчен зур югалтуларга сәбәп булып тора. Татар таш сәнгатен өйрәнү буенча бер генә белгечнең дә хәзерләнмәве безнең дәүләтчелегебезнең башында очраклы, фикерсез һәм мәдәнияттан үтә ерак торган кешеләр утыруы белән бәйле.

## № 1
## Минзәлә төбәге, Бикбау авылы иске зиратындагы беренче ташбилге тексты

1.
2.
3.
4.
.5
6.
7.تاریح مینك دا آلتمش یتی دا ایردی
8. بیکباو اوعلی یوسوفننك بیلکوسی ترور
9. قوتلوع موبارك بولسون
10. دویش حافیضا یازدی

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

7. Тарих миң дә алтмыш йитидә ирди
8. Бикбау углы Йосыфның билгүси торур.
9. Котлуг мөбарәк булсын
10. Дәвиш хафиз йазды.

**Искәрмәләр**

Бу зираттагы ташбилге регионда мәгълүм булганнардан иң борынгысы. Анда ике таш булып, икесе дә бер кешенең балалары каберләре өстенә куелганнар. Ләкин бу беренче ташның формасы икенчесенекеннән нык аерыла. Бу беренче ташның формасы Әгерҗе төбәгендәге Салагыш авылы кырында сакланган әүлия кабере ташына ошаган Салагыштагы һәм Бикбау авылындагы ике ташның охшашлыгында зур бәйләнеш бар. Бу ташлар генетик яктан бер-берсенә бәйле булган авыл шәхесләренә карыйлар һәм бер үк вакытта диярлек куелганнар. XVII гасырның 50 нче еллары ахырында татар эпитафик ташларының башка үрнәкләре күренми.

Ташның үлчәмнәре: 12x40x90 см. Текст сай гына итеп уеп язылган. Гарәп телендәге «Коръән» аятьләрен мүк баскан. Вакыт

чикләнгәнлек белән аятьләрне укып, язуга төшерү мөмкин булмады. Аятьләр текстта алты юл тәшкил итәләр һәм вак кына Сөлес стилендәге язу белән беркетелгәннәр.

Ташның куелу вакыты һиҗри 1067, милади белән 1656–1657 нче елларга туры килә.

## № 2
## Әгерҗе төбәге, Салагыш авылы «Әүлия ташы» ташбилге тексты

1. الحی الدی
2. بیتدی تیلاش ... اوعلی دوسمت
3. لا یَموُتْ و هوُ
4. کل سَمُوت قال الله
5. سبُحانَه وَ تَعَالي وَ مَاتدری نفس
6. رض یموت
7. اَنه الله علیم خیر قال النبی علیه السلام
8. کل نفس ذایَقة قال نبی علیه السلام
9. الدنیه ساعة فجالعلها طاعة قا
10. ل النبی علیه السلام الدنیا میزاعة الاخرة
11. اري الدنیا حرابه یعتباري فلایبقی مداما بالقاراري
12. کورارمن دنیانی ویران بارو همیشه
13. باقی ایرماس یوق قراري تاریخ توکا
14. ل منك اوزوب التمش طوغوزدا دو
15. نکوز یلیندا سفرای نیك احریندا بکاش
16. اوعلی بك قول ایکي اوعلی برلا ایق ایدل اراسندا شهید
17. حق تغلا الفنادین البقغاغا رحمت قلسون کیج رسین

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

2. Битеде Тиләш углы Дусмәт

12. Күрәрмен дөньйаны вәйран бары, һәмишә

13. бакый ирмәс йук карары тарих төгә-
14. л миң узуб алтмыш тугузда ду
15. нгуз йылында сәфәр айының ахрыйнда Бигәш
16. углы Биккол, ике углы берлә Ыйкъ-Идел арасында шәһид.
17. Хак Тягаля әлфанадин әлбакага рәхмәт
18. кылсун, киҗерсин.

## Сүзлекчә

вәйран – җимерек
һәмишә – һәрвакыт
бакый ирмәс – мәңгелек түгел
сәфәр – һиҗри елның икенче аеның исеме
шәһид – үтерелде
Әлфанадин – бу дөньядан
Әлбакага – мәңгелек дөньяга
киҗерсен – кичерсен

**Искәрмәләр**

Салагышның «Әүлия» кабер ташы 1977 елның 2–4 июль көннәрендә халыктан барлыгы ачыкланды, табылды, укылды. Бу таш турында, ягъни эчтәлегенә кагылышлы мәгълүматлар беренче мәртәбә фәнни җыентыкта тел тарихы материалы буларак игълан ителде[1]. Шулай ук аның эчтәлегенә кагылышлы мәкаләләр газета һәм журнал битләрендә чагылды[2]. Салагышның «Әүлия кабере» ташы соңгы елларда башка белгечләрне дә кызыксындырды[3].

Салагышның «Әүлия кабере ташы» табылган вакытта ул бер ялгыз кабер буларак авылдан читтәрәк, чокырсыман җирдә ачылды, аңа якын килеп җитми күреп тә булмый иде. Куе, биек үлән һәм яшь, яңа утыртылган агачлар аны кеше күзеннән каплап торалар.

---

[1] Ахметзянов М.И. О лексике татарских эпитафий XVII–XVIII вв. // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983. – С. 75–83.

[2] Әхмәтҗанов М.И. Тарихи чыганаклар // Минзәлә. – 1993. – 5 гыйнвар. – № 2; Шул ук мәкалә: Идел. – 1994. – № 2. – Б. 64–65.

[3] Мәрданов Р., Һадиев И. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: «Тамга» нәшрияты, 2008. – Б. 93–95.

Ташның конструкциясе бик үзенчәлекле, ул үзенә бер көзгесыман итеп ясалган, йөзлеге шомартылган, йөзлекнең тирәли 5 см. киңлектә, 1 см. биеклектә кыса ясап әйләндерелгән. Ташның үлчәмнәре без тикшергән вакытта 9х50х100 см. булып теркәлде. Билгеле, аның биеклеген җиргә баткан өлешен дә искә алсаң тагын бер 30–40 см. арттырырга мөмкиндер. Таш плитәнең овал формада булуын искә алсаң, киңлеген дә кечерәйтеп тә, киңәйтеп тә күрсәтергә юл ачыла.

Текст сай гына итеп уеп язылган. Ул ике өлештән тора. Беренчесе гарәп телендәге «Коръән» аятьләре 1–11 нче юллар, аннан орнаментлар белән бүленгән татарча тарихи текст башлана. Анысы 12–17 нче юлларда бәййан ителә.

Бу таш татарларда истәлек өчен куелган беренче таш булса кирәк. Моңа хәтле истәлеккә мемориаль таш кую очрагы татар эпитафия сәнгатендә әлегә мәгълүм түгел.

Ташның татар тарихы, мәдәният һәм тел тарихы өчен кыйммәте зур.

Әлеге тарихи чыганакның куелу датасы һиҗри белән 1069 елның Сәфәр ае ахырында дип күрсәтелә, төрки-татар хайван календаре буенча дуңгыз елы була, милади белән күрсәткәндә дата 1658 елның 11 ноябренә, сишәмбе көнгә туры килә.

## № 3
## Минзәлә төбәге, Гөлек авылы
## «Изгеләр зираты» ташбилге тексты

1. هو الحى الذى لا يموت وكل حى سيموت قال النبى عليه السلام
2. الدينه ساعات فجعلها طاعات قال النبى عليه السلام الدنيه مزرعة الاحرت
3. ... ارى...[د]نيا حربا بعتيبارى
4. فلا يبقى مداما بالقرارى تاريح
5. مينك ده سكسن توروتدى
6. ...

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. ............................ Тарих
5. миң дә сиксән түр үтдә
6. .............

**Искәрмәләр**

Таш 2006 елның 14 июлендә өйрәнелде. Ул Гөлек авылы янындагы «Изгеләр зираты» дип аталган, өч-дүрт кенә агач үсеп утырган, киртәләп алынган җирдә урнашкан. Элек бу зиратка изгеләр дип халык адарынып йөри торган булган. Хәзер баручылар-килүчеләр күренми диләр.

Таш начар сыйфатлы материалдан комташтан эшләнгән, ярылгалап кубып төшкән урыннары бар, аның якын елларда язулары уалып бетү куркынычы шиксез.

Ташның үлчәмнәре 17x6x95 см. Аскы өлеше җиргә баткан язулары бик таушалган, алар кабартып язылган булган, ләкин эррозия көчле. Ташның тимпанында уеп ясалган традицион үсемлек орнаменты бар.

Аның куелу датасы һиҗри 1084 ел, руми белән 1673\1674 ел була.

Ташның палеографик үзенчәлеге, мәсәлән, әдәби «дүрт» сүзенең «түрүт» дип язылышы аның Нократ морзалары вәкиленә куелган булуын күрсәтә.

## № 4
## Менделеев төбәге, Песәй авылы зираты ташбилгесе тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قال النبى عليه السلام الدنيا ساعات
2. فجعلها طاعت صدق قال النبى عليه السلام الدنيا سجين المؤمن و جنت
3. الكفر قال النبى عليه السلام الدنيا جيفت و طالبها الكلاب
4. تاريخ منكدا سكسان سكزدا يلقى يلى دير لار ايردى جاديكار اوعلى آيتوعان

5. اوز وقتندا اوشبو بلکینی قویدی مسلمانلاردین دُعا اومید اوچون کورارمن دنیانی وایران باری
6. باقی ایرماس همیشا یوق قاراری کتبه کیل محمد ابن اشمان

**Таш текстының татар телендә язылган өлеше хәзерге графикада**

4. Тарих миң дә сиксән сигездә йылкы йылы

дирләр ирди. Җадигар углы Айтуган

5. үз вакытында ушбу билгини куйдый, мөселманлардин дога өмид өчүн. Күрәрмен дөньйаны, вәйран бары,

6. бакый ирмәс һәмишә йук карары.

Кәтәбәһү Килмөхәммәд ибнү Ишман

**Искәрмәләр**

Песәй авылы зиратындагы калай каплавыч белән капланып сакланган ташны 1978 елның 26 июлендә барып укып текстын язып алган идек. Аны укыганлыгыбыз турында, аннан мисаллар китереп матбугатта фәнни мәкалә дә язып чыктык[1].

Ташның үлчәмнәре 22x47x106 см. Ул акташтан кисеп ясалган, язмалар хәрефләрне күпертеп язылганнар. Сөлес стилендәге гарәп язуы.

Ташның куелу датасы һиҗри 1088, милади 1677–1678 нче елларда.

Ташның безнең тарафтан өйрәнелеп, фәнни мәкалә язып чыгуым да соңыннан бу регионда эпитафияләр өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләрендә искә алына[2]. Гомумән мин өйрәнгән ташларны әлеге хезмәттә барлыгын гына белдергән дигән фикер әйтелә. Ләкин ташларның даталарын, кеше исемнәрен, терминнарын фәнни мәкаләдә уку өчен, аларны өйрәнеп тикшереп чыгуны, фактларны мәкаләләрдә куллануны фәнни эшкә санамау тенденциясе күзгә ташлана мөхтәрәм яшь галимнәр хезмәтендә.

[1] Ахметзянов М.И. О лексике татарских эпитафий XVII–XVIII вв. // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983. – С.75–76.

[2] Мәрданов Р., Һадиев И. Борынгы ташлар ни сөйли? // Мәйдан. – 2006. – № 8. – Б. 157.

Кызганычка каршы безнең фотосурәтебез дә Песәй ташын төшереп матбугатка чыгарырлык хәлдә булмады.

## Татарстан республикасы Мөслим төбәге Катмыш авылы янында Ык елгасы буендагы иске зират ташлары

Бу зират ташлары Минзәлә төбәгенә Казан милли музееннан 1929 елның җәендә җибәрелгән комплеклы экспедиция әгъзасы Сәйет Вахиди тарафыннан табылып өйрәнелә. Галим бу хакта матбугатта хәбәр дә иткән. Ләкин кызганычка каршы әлеге экспедиция табышларының бәя биреп бетергесез материаллары эзсез югала.

Без Катмыш авылы зираты истәлекләрен 1983 елның 30 июль – 2 август көннәрендә археографик эзләнүләр вакытында өйрәндек.

Ул вакытта зират мәйданы чама белән 200х140 метр чамасы зурлыкта (340х240 адым). Ул вакытта без анда 14 кабер ташы барладык. Күп ташлар җиргә егылып, җир белән тигезләнеп батып яталар иде. Без аларның да үлчәүләрен алдык. Ләкин зират мәйданын көрәк яки очлы тимер белән капшап чыкканда тагын да ташлар табылу ихтималы бар.

Соңыннан 1998 елда Катмыш зиратын безгә яңадан карап чыгу максаты белән килгәндә, анда инде без язулы ташлар күрмәдек. Аллар юкка чыккан иде.

Шунлыктан зур үкенеч булды. Хәер, соңыннан ике язулы ташны без Мөслим район үзәгендә ташландык бер урында 1998 елның 4 августында күреп, аларның булса да текстларын яңадан карап чыктык. Калганнары каядыр, инде «Әй, Мөслим, инди нишлим!» – дияргә кала.

Бу басмада без Катмыш ягында табылган борынгы ташбилгеләрнең барсы турында да мәгълүмат биреп узарбыз.

Катмыш ташлары барсы да ак известь таштан ясалганнар. Бу зират Кама аръягында XVII гасыр ташлары сакланган иң зур зират булып тора.

С.Вахидиның язуына караганда, Мөслим төбәге Тугаш авылында да борынгы XVII ташбилгесе була. Ләкин безнең Тугашта аны эзләнүләребез нәтиҗәсез бетте.

## № 5
## Мөслим төбәге, Катмыш авылы янындагы иске зират, беренче ташбилге тексты

1. بسم الله الرحمن الرحيم
2. كل نفس ذا ٔيقة الموت
3. قال النبى عليه السلام الدنيا
4. ساعه تى فجعلها عتى تاريخ
5. منك سكسن توقوزده نوعاى
6. باق اوعلى جناباي تورور

**Текстның татар телендәге өлешенең кириллиөада чагылышы**

4. ….. тарих
5. мең биксән тукузда Нугай-
6. бак углы Җанбай торур

**Искәрмәләр**

Әлеге зират һәм андагы ташлар 1983 елның 2 августында безнең тарафтан өйрәнелде һәм ташлардагы текстлар укылдылар. Ташның үлчәмнәре: 11х29–45–49х77 см.

Кыргый ташка уеп язылган. Таш һиҗри 1089 милади 1678–1679 елларда куелган.

Бу ташны кабаттан Мөслим район үзәгендәге музей ишек алдындагы ташландык урында күрдек. Аның өстенә зәңгәр буяу агызып катырганнар.

## № 6
## Катмыш зираты, икенче ташбилге тексты

1. الكه
2. لا الله لا الله محمد رسول الله
3. كل [نفس] ذائقة الموت
4. ادانا اولار تاريح منكدا توقسان د
5. ا تؤقق يلينا تويقاى اوعلى توديقاى
6. [دار الفان]دين باقى دنيا
7. [رحلت ايت]دى تورت ياشيندا ايردى

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. ............Тарих мең дә
5. туксанда таwык йылыйнда
6. Туйкай углы Тудыйкай [дарел фана] дин бакый дөньйа-
7. [га рихләт ит]ди, түрт йәшиндә ирди

**Искәрмәләр**

Ташбилге калку урында җиргә баткан хәлдә ята. Күренгән хәтле өлеше 10\11x59x64 см. Башы дугаланып эшләнгән, язмалар уеп язылган. Куелу вакыты һиҗри 1090, тавык елында, милади 1679–1680 елга туры килә. Ташның эшләнеше гади, шомартылмаган.

## № 7
## Мөслим төбәге, Катмыш зиратындагы өченче ташбилге

Язулы йөзлеге ашалып беткән таш. Үлчәмнәре 23x70x103 см. Егылып җиргә баткан. Җирдән 15 см. күтәрелеп тора. Фигурасы эшкәртелгән ташка ошаган. XVII йөз.

## № 8
## Мөслим төбәге, Катмыш зиратындагы дүртенче ташбилге

Җиргә егылып баткан, өске ягы тигез, ләкин язу галәмәтләре юк. Аскы өлешне карар өчен, ташның әйләнәсен казып чыгып, әйләндереп карарга кирәк. Үлчәмнәре 14\15x55x107 см. зурлыкта, ялгыз кеше генә карарлык түгел. Ташның фигурасы эшкәртелгән. Ташбилгенең XVII гасырның соңгы чирегендә куелуына шөбһә юк.

## № 9
## Менделеев төбәге, Турай авылы зираты (беренче) ташбилгесе тексты

1. هو الحي الذي لا يموت و كل حي سيموت قال النبى عليه
2. السلام الدنيا ساعات فجعلها طاعات صدق

3. قال النبی علیه السلام الدنیا سجین المؤمین و جنت الکافر قال
4. النبی علیه السلام الدنیا جیفات و طالبها کلاب. تاریح مینکده توقصا
5. نده دیرلار ایردی تورای اوعلی چوواشای دنیادین اوتی ایرسه اوشبو
6. بیلکینی مسلمانلاردین دعا اومید اوچون حلالی توی سولطان
7. اوصتا بیکه بیلکی قویدی کورارمن دنیانی ویران باری باقی ایرماس
8. همیشا یوق قاراری

Ташның йөзлек кырында

کتبه کیل محمد ایشمان اوعلی ایردی

Ташның икенче сул як янында

چووشای
نك ایکی او
علی یوسف
ایشالی
ایر
دی

**Турай зираты**

**Текстның татар телендәге укылышы графикасы**

4. Тарих миң дә тукса-

5. -нда дирләр ирди, Турай углы Чувашай дөньйадин үтте ирсә ушбу

6. билгини мөселманлардин дога өмид өчүн хәлали Туйсолтан

7. остабикә билги куйдый. Күрәрмен дөньйаный вәйран барый, бакый ирмәс һәмишә

8. йук карарый.

**Ташның йөзлеге кырыенда:**

Кәтәбә Килмөхәммәд Ишман углы ирди.

**Ташның сулъяк янында:**

Чуввашай-
ның ики у-
глы – Йосыф

Ишәли
ир-
ди.

**Искәрмәләр**

Ташның үлчәмнәре: 17x57x147 см. Таш куелу датасы һиҗри 1090, милади 1679–1680 елга туры килә.

Бу таш куелган истәлек татар шәҗәрәсе «Шәйех Дирбеш» нәселенә карый. Әлеге зур нәселнең улы Турай Кама (Агыйдел) буена Иделнең Тау ягыннан күчеп килгән кешегә ошый. Алар XVI–XVII гасыр чикләрендә яшәгән адәмнәр. Бу нәсел йомышлы татарлар социаль төркеменә карый.

## № 10
## Менделеев төбәге, Турай авылы зиратындагы икенче борынгы ташбилге тексты

1. هو الحی الذی لا یموت و کل حی سیموت قال النبی
2. علیه السلام الدنیا ساعه ت فجعلها طاعه ت قال النبی
3. علیه السلام الدنیا سجن المؤمینه و جنت الکفر قال النبی
4. علیه السلام الدنیا جیفات و طالبها کلاب تاریح
5. منکدا توقصان بردا دیرلار ایردی بای صوبی بابا انینك او
6. علی بی بولدی انینك اوعلی ماسعوت دنیدین اوتی
7. ایرسه اعاسی بی مرضا بیك ایرنلاردین دعا اوچون قویدی
8. کورارمن دنیانی وایران باری بقی اِرماس همِیشه یوق قاراری

**Турай авылы зираты ташбилгесе текстының татар телендәге өлешенең хәзерге татар язуында чагылышы**

4. … …. … … …                                        тарих
5. мең дә туксан бердә дирләр ирди, Байсубы баба аныйң у-
6. -глы Бибулды. Аның углы Масгут дөньйадин үтте
7. ирсә, агасы Биморза бик ирәнләрдин дога өчүн
куйды.
8. Күрәрмен дөньйаны вәйран барый, бакый ирмәс
һәмишә йук карары.

**Искәрмәләр**

Бу ташка беренче булып игътибар иткән кеше Татар Сарсазы авылы крайны өйрәнүчесе Мирза ага Тарханов (1897–198...) игътибар итеп укыган. Аның укылышын студентлар диплом эшләренә кертеп кайбер галимнәргә биргәннәр... Аларның берсе шул укылыштагы ялгышлар белән текстны матбугатка да чыгарды. Без, татар эпиграфикасы белән хәбәрдар кеше буларак аның дөреслегенә шул вакытта ук шөбһә белән йөргән идек. Ниһаять, 1978 елның 28 нче июль көнендә юлыбыз төшеп Турай авылына килгәч (хәзер Турай Менделеев төбәгенә керә) безнең шөбһәләнү юкка түгел икәнен күрдек. Турай ташъязмасы хакында матбугатта йөргән шикле хәбәр ачыкланды.

Турай кабер ташы белән тирән кызыксынуымның сәбәбе аның татарның Шәйех Дирбеш шәҗәрәсендәге өч буыны тармакларын дөрес тәртиптә күрсәткән булуында да иде[1].

Турай зиратындагы бу ташның үлчәмнәре: 23х50х107 см. Ташны куючының текстта имзасы да бар: «Кәтәбәһү Ишман углы Килмөхәммәд».

Әлеге таш Турай авылы зиратында бер ачык дөрбә эчендә тора, дөрбә турыпочмак рәвешендә эшләнгән. Үлчәү мәйданы 380х316 см. Бу XVII гасырдан калган сирәк татар дөрбәләренең берсе – 1680 елда корылган.

Өйрәнелгән ташның куелу датасы һиҗри 1091, милади 1680 елга туры килә.

Ташта искә алынган Байсубы токымнары Туймазы ягы Тураенда, Баулы, Азнакай һ.б. татар төбәкләрендә яшиләр.

## № 11
## Катмыш зираты, бишенче ташбилге тексты

1. بسم الله اليرحمن الرحم
2. ذائقة الموت قال النبى عليه
3. السلام الدنيا ساعة
4. فجعلها طاعة تاريح
5. منك توقسان برده
6. براق ابن يخشمبات

[1] Әхмәтҗан М. Турай, Миякә арасы – бар да меңнәр баласы. – Казан, 2010. – Б.52–53.

**Татарча текстның кириллицада укылышы**

4. ....................... тарих
5. мең туксан бердә
6. Борак ибне Йахшымбәт.

**Искәрмәләр**

Текст кыргый ташка уеп язылган. Аның үлчәмнәре: киңлеге 41–44 см., озынлыгы 71 см, калынлыгы, җиргә нык баткан – җир өстеннән 8 см. чыгып тора, ихтимал, җиргә баткан өлеше бер 7–8 см. дан ким түгелдер.

Ташның куелу вакыты һиҗри 1091, милиди белән 1680 елга туры килә.

### № 12
### Алабуга төбәге, Иске Юраш авылы ташбилгесе тексты

1. ... الدنيا سجين المؤمن و جنت الكفر [تاريح]
2. منكدا توقصان بردا ايردى دولات ك...
3. [تن]كرى بردى چيروكًا بارب دنيادين اوتى ايرانلاردين دعا
4. [اوچون] بو بيلكينى قويدى كورارمن دنيانى [وايرا]ن [بارى]
5. باقى ايرمس
6. هميشه يوق قا[رارى]

**Текстның татар телендә язылган өлешенең хәзерге графикада күренеше**

1. ......................... [тарих]
2. Миң дә туксан бердә ирди Дәүләт-К[илди].....
3. ..... Тәңрибирди чирүгә барыб, дөньйадин үтти, ирәнләрдин дога [өмид]
4. [өчүн] бу билгини куйдый. Күрәрмен дөньйаны [вәйра]н [барый]
5. бакый ирмәс
6. Һәмишә йук карарый.

**Искәрмәләр**

Бу ташбилге Алабуга төбәгендәге Иске Юраш авылыннан читтә ялгыз кабер өстенә куелган булган. Аның өске өлешен һәм кырый җирләрен авыруларга шифа дип киртекләп ватканнар.

Ташны 1995 нче елны Алабуга музеена алып кайтып куйганнар. Ләкин Алабугадан музей хезмәткәрләренең миңа адресланган хатларыннан аңлашылганча, аны укый белүче табылмаган. Без аны 1996 елны укып, текстын язып җибәргән идек. Бу хакта район газетасында да хәбәр булган ахыры.

Кабер ташларын укый белүчеләрдән берәү текстны М.Әхмәтҗанов 1612 елда куелган дип язган, дигән хәбәр дә таратты. Бу дөрес түгел, мин әлеге таш 1091 нче елда куелган дип яздым. Бу дата һиҗри буенча, милади хисап белән ул төгәл 1680 нче елга туры килә. Безнең кулда ташның зурлыгы турында мәгълүматлар юк. Ләкин бу ташның язылыш стиле, почеркы танылган оста Килмөхәммәд бине Ишманныкына ошамый. Бу ләүхәдә Дим елгасы Чишмә станциясе янындагы ташбилгеләрне язган башка оста кулы чагыла. Таш гаскәри хезмәттә йөреп читтә һәлак булган кешегә истәлек итеп куелган.

**№ 13**

**Катмыш зираты, алтынчы ташбилге тексты.**

1. ته د ...ا ... ... ...
2. بسم الله الرحمن الرحم
3. الا الله محمد رسول الله
4. نفس ذائقة لا يموت ثم الينه
5. تورجعون تاريح مينكدا
6. توقسان ايكدا ...
7. ... ...

**Катмыш авылы янындагы таштагы текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

5. ..................Тарих миң дә

6. туксан икидә.......

**Искәрмәләр**

Таш кыргый, эшкәртелмәгән известь ташка уеп язылган. Аның үлчәүләре 8-?х59х76 см. зурлыкта. Өске өлешенең бер юл язуы бозылган, алтынчы юлдан соң язулар ашалып беткән. Куелу вакыты һиҗри 1092, милади белән 1681 елга туры килә. Ташта күз тамга ясалган .

Ташбилге җиргә егылып баткан һәм җир өстеннән 8 см. чыгып (күтәрелеп) тора.

### № 14
### Әгерҗе төбәге, Иске Эсләк ташбилгесе тексты

1. هو الحی الذی لا یموت و کل حی سیموت
2. ..ل النبی علیه السلام الدنیا ساعت فجعلها طا
3. عات...النبی علیه السلام الدنیا سجین ال مؤمین جنت ال کافر
4. ... النبی علیه السلام الدنیا جیفات و طالبها کلاب
5. تاریح مینکدا توقسان ایکیدا ایردی بورنا[ش]
6. اوعلی ساوالای ایرانلاردین دعا اومید اوچون بلکی قوی دی
7. کورارمن دنیانی ویران باری باقی ایرماسی همیشه یوق قاراری

**Иске Эсләк авылы таштагы текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

5. Тарих миң дә туксан икидә ирди Бурна[ш]
6 углы Сәвәләй ирәнләрдин дога өмид өчүн
билги куйдый.
7. Күрәрмен дөньйаны вәйран бары, бакый ирмәс
һәмишә йук карарый.

**Искәрмәләр**

Иске Эсләк (Песләк) авылында 1977 елның 9 июль көнне булып аның зиратыннан бер ике йөз метр читтә бер иске таш аунап ятканын күрдем. Аның өстеннән яңа гына, шул көннәрдә чылбырлы трактор узып китеп, аның йөзлегенең бер кырыенда язуны бозган иде. Моны таш янында, аның өстенә менгән тракторның сакланган эзләренә карап хөкем иттем.

Ташның үлчәмнәре: 15х48х130 см., ул яхшы доломит материалдан эшләнгән. Язмалары кабартып эшләнгән, тимпан орнаменты уеп эшләнгән. Аның зираттан читтә ятуын авыл кешеләре әйткән иде. Текстны укып бетергәндә минем янга үзе дә Әгерҗе егете, баянчы, Тел, әдәбият һәм тарих институты аспиранты Рәгъде Халитов машинасы белән мине алырга килгән иде. Аның фотоаппараты бар иде (минем аппаратым ул чакта ватылды), ул табылган ташның берничә ракурста рәсемен алды. Кызганычка

каршы безгә ул рәсемне күрергә туры килмәде. Таштагы ватылган урын мәрхүмнең атасының исеме булып чыкты. Исемнең баштагы биш хәрефе сакланып, ул «Бурна...» рәвешендә иде, аны Кара бәк шәҗәрәсендә улы исеме дә күрсәтелгәч, дөресләп «Бурнаш бине Сәвәләй», – дип уку мөмкин булды. Бу безнең укылыш турында маттбугатта да язылды[1]. Ташның һиҗри куелу датасы 1092 миладди 1681 нче елга туры килә.

Бездән соң бу текст кабер ташлары өйрәнүче галимнәр тарафыннан укылып бастырылып чыгарылды[2]. Ләкин алар безнең укылышка шөбһәләр белдереп һәм без өйрәнгән таш язмышына битарафлыкта гаепләп, хезмәтебезне шелтәләп тә чыктылар. Кызганыч, без табып, укып ул турыда язмасак, алар Иске Эсләк ташын эзләп таба алырлар иде микән әле.

Ташның соңыннан Сарапул музеена урлап алып китүләре ул законсыз күренеш. Аны теләгән вакытта каберлеккә кайтарып утыртырга Татарстан мәдәният министрлыгының бөтен вәкаләте бар һәм Иске Эсләк авыл советы да бу эшкә хокуклы. Закон буенча тарихи әйберләр табылган җирнең администрациясе карамагында булырга тиеш. Һәм аны Сарапулдан кайтартып авыл музеена, яки мәчет карамагына алдырырга мөмкин. Христиан республикасына мөселман рухи әйберләрен удмуртныкы итеп алып китү дөрес түгел. Аны алып киткәнгә рәхмәт әйтеп, М.Әхмәтҗановка шелтә белдереп язу килешкән эш түгел.

## № 15
## Әгерҗе төбәге, Ырыс авылы зиратындагы XVII гасыр ташбилге тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قال النبى عليه السلام
2. الدنيا ساعة فجعالها طاعت صدق قال النبى عليه السلام
3. الدنيا سجن المؤمن و جنت الكافر قال النبى عليه السلام

---

[1] Ахметзянов М.И. О лексике татарских эпитафий XVII–XVIII вв. // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983. – С. 75–80.

[2] Мәрданов Р., Һадиев И. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: «Тамга» нәшрияты, 2008. – Б. 57–58.

4. الدنيا جيفت و طالبَهَا كلاب تاريح منكدا تو
5. قصان ايكدا ايردى صقا اوعلى توتاچ اوزى بلكى وختيدا
6. ايرانلاردين دعا اوميد اوچون قويدى
كورارمن دنيانى ويران بارى باقي ايرمس
7. هميشه يوق قارارى

**Зур Ырыс авыл зираты ташбилгесе**

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. .......................Тарих мең дә ту-
5. ксан икидә ирдии, Сака углы Тутач үзе белеги вахытыйда.
6. ирәнләрдин дога өмид өчүн куйды.
Күрермен дөньйаны вәйран бары бакый ирмәс.
7. һәмишә йук карары.

**Искәрмәләр**

Зур Ырыс авылы, халкы 1977 елның беренче яртысында күрше авылларга таратылып (Салагышка һ.б.) күчерелеп бетә. Аның зиратын да кызыл балчыкка кадәр казып калдырып каберләрне бетерәләр. Зиратның зур бер борынгы ташы аның кырыенда аунап ята иде. Без аны 1977 елның 5 августында эзләнеп килеп таптык. Таш доломит, таза материалдан эшләнгән, яхшы сакланган, физик бозылмаган да иде. Үлчәүләре – 22x51x156 см. тәшкил итә, аның сырт ягын да күсәкләр белән әйләндереп карадык, ләкин ул якта язулар юк иде. Бу хакта Ырыстан Салагышка кайткач, Салагышта йортлар салып урнашкан Ырыс кешеләренә һәм авыл советы рәисенә бу ташны саклау, күчерү кирәклеге турында әйтелде. Ләкин моңа чара күрүче булмаган күрәсең, эпиграфика өйрәнүчеләр хәзер аның кайдалыгын белмиләр.

Кызганычка каршы минем фотоаппаратымда ташның сурәтләре сыйфатсыз чыкты. Матбугат өчен материал таштан мин танып укый алган дәрәҗәдә генә чыкты. Шулай да ташта мин укый алмаслык, танылмый калган урыннарның булмаганлыгын әйтергә кирәк. Бу таш Кара бәк нәселеннән булган бәкләр каберенә куелган. Ырыста яшәгән мәрхүм Сака угылы Тутач Иске Эсләк авылы кырында ташбилгесе сакланган Бурнаш углы Сәвәләйнең якын туганы.

Борнашның Сака, Сәвәләй исемле ике углы була[1]. Ырыс зиратында сакланган тарихи истәлек һиҗри 1092, милади 1681 елда куелган.

## № 16
## Катмыш зираты, җиденче ташбилге тексты

1. ... السه لام ...
2. كل نفس ذائقة الموت
3. لا الله الله محمد رسول الله تاريخ منكدا
4. توقسان ايكى دا ايردى ...
5. صادا اوعلى صااد ...
6. ...

**Катмыш ташбилгесе текстының татар телендәге юллары хәзерге графикада чагылышы**

3. ...................... Тарих мең дә
4. Туксан икидә ирди...
5. Садә углы Саад

**Искәрмәләр**

Ташбилге үлчәүләре 13x52x60 см. Аскы ягы ватылып, егылган хәлдә ята.

Өстәге юлы да бозылган, язмалар уеп язылган. Ташның язмышы билгесез. Куелу вакыты һиҗри 1092 ел, милади 1681 елда туры килә.

## № 17
## Катмыш зираты, сигезенче ташбилге тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت صدق قال
2. النبى عليه السلام الدنيا ساعات فجعلها طاعات
3. تاريح منكدا توقصان اوجدا ايردى چوراباتر اوعلى
4. ايردى تپتر اقاسى اوعلى
5. بو بلكنى قويدى ... احلاص
6. اچون ايرنلاردين دعا اوميد برلا بو بلكينى قويدى

[1] Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995. – Б.23.

**Катмыш зираты ташбилгесенең текстының татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

3. Тарих мең дә туксан өждә ирди
Чура Батыр углы
4. ирди. Типтәр акасы углы
5. бу билгене куйдый ихлас
6. өчүн ирәнләрдин дога өмид берлә
бу билгини куйдый.

**Искәрмәләр**

Ташбилге бу зиратта бердәнбер традицион стильдә эшкәртелеп Казан ханлыгы дәвере ташларына ошатып эшкәртелгән, бай эчтәлекле, һәйкәл ватылмаган, бөтен хәлдә басып тора иде. Аны соңыннан урыныннан кубарып Мөслимнең (район үзәге) бер чүплегенә кычыткан арасына ташланган хәлдә күрдем. Мөслим түрәләренең мәдәни мираска мөнәсәбәтләре Татарстан башкаласы түрәләренә якын икән. Аларга да татар мирасыннан бигрәк чиркәү кадерле дигән фикер кала. Таш күпертеп, борынгы сөлес стилендә язылган һәм Мөслим төбәгенең иң иске тарихи язма тексты. Аның куелу датасы һиҗри 1093, милади белән 1682 елга карый. Димәк, бу якларда шул елда үлгән кеше каядыр XVII гасыр башларында бу тирәдә туган була. Димәк, бу татар авылында типтәр сословиесенә караган катлау да яшәгән. Бу ташны атаклы таш кисү остасы Килмөхәммәд бине Ишман эшләгән булуы ихтимал.

**№ 18**
**Актаныш төбәге, Әҗәкүл авылы зиратындагы ташбилге**

1. هو الحى الذى لا يموت قال النبى عليه السلام الدنيا سا
2. عت فجعلها طاعات صدق قال النبى عليه السلام الدنيا سجنون المؤمينا جنا
3. ت الكفر تاريخ منكدا توقصان توروتدا ايردي اوته
4. كان ننك كيلدي بي ننك اوعلى ايشكاي اننك
5. بيلكسي تورور بو فايتكا كوليماكاي بيكا
6. بو بيلكني قويدي ايرانلاردين دوعا اوميد اوجون

**Әҗәкүл ташбилгесе текстының татарча өлешенең хәзерге графикада күренеше**

3. Тарих мең дә туксан түрүтдә ирди Үтә-
4. гәннең Килди [би]нең углы Ишкәй анының
5. билгиси торур. Бу Фәйткә Гөлимәкәй бикә
6. бу билгини куйдый, ирәнләрдән дога
өмид өҗүн.

**Искәрмәләр**

Әҗәкүл авылы зиратында сакланган бу таш 1998 елның 11 августында табылып укылды. Таш басып тора, беркадәр өлеше җиргә иңгән, соңгы юлны ташның төбен бер 15 см. казып чистартып укырга туры килде.

Авыл кешеләренең сөйләүләренә караганда зиратның бу төбәгендә шундый ике таш булып, берсе бу вакытка югалган иде, ләкин аны күрүчеләр булган һәм бар иде дип раслыйлар.

Таш турында беренче мәгълүмат 2010 елда матбугатка чыкты[1]. Бу җыентыкка без таштан алынган эстампаждан карап кайбер график билгеләрне төзәтеп бирдек. Бу ташта искә алынган Үтәгән авылын Нократ мирзалары нигезләгән. Үтәгән Әгерҗе төбәгендә бүген дә бар. Ташта искә алынган Фәйткә Гөлимәкәй Нократ татарлары, ягъни Вятка елгасы буеннан булган күрәсең, шунлыктан Фатыйманың кушаматы да тарих ача торган бер деталь.

Эпитафик текст нәселнең кыпчакларга катнашы барлыгын күрсәткән лингвистик детальне саклаган – әдәби ***өчүн*** сүзенең ***өҗүн*** рәвешендә, ягъни ***җ***-лаштырып язылуы шуның билгесе.

Таш известь – доломиттан эшләнгән язмалар кабартып язылган, тимпандагы орнамент уеп ясалган. Тексттагы һиҗри дата 1094 миладиي белән 1682\1683 елларга туры килә.

Ташның үлчәмнәре – 17х54х105 см.

## № 19
## Минзәлә төбәге, Гөлек авылы «Изгеләр зираты» ташбилге тексты

1. هو الحى الذى لا يموت وكل حى سموت قال النبى

---

[1] Әхмәтҗанов М. Әҗәкүлнең язулы ташы // Фән һәм тел. – 2010. – № 1. – Б. 47–48; Әхмәтҗанов М. Тамырлардан таныйрлар // Милли-мәдәни мирасыбыз. Актаныш. – Казан, 2010. – Б. 58–59.

2. عليه السلام الدنيا ساعات فجعلها طاعات
3. قال النبى عليه السلام كل نفس ذايقة الموت
قال النبى عليه السلام الدنيا مزرعة الاحرت
4. تاريح مينك ده توقصان بشده ... منه لار
5. اقچورا بيك تمراو على سيد غوجا اوز
وقتينده بولوحنى قلدى
6. اوشبو بلكنى اوز حياتنده ايرانلاردين دعا
اومد اوچون الدنيا

**Минзәлә төбәге, Гөлек авылы зираты ташбилгесе тексты-ның татарча өлешенең хәзерге язмада укылышы**

4. Тарих миң дә туксан бишдә ... менәләр

5. Акчура Биктимер углы Сәйед гуҗа үз вакытында бу ләүхәне кылды.

6. Ушбу билгене үз хәятендә ирәнләр-
дин дога өмид өчүн әд-дөнья....

**Искәрмәләр**

Таш тексты 2006 елның 13 июлендә беренче мәртәбә укылды. Үлчәүләре 17х47х90 см. зурлыкта, ташның сыйфаты начар. Аның өске өлешендә арка астында – тимпанда, бу дәвер татар кабер ташларына хас булган үсемлек орнаменты уеп ясалган.

Төп текст кабартып язылган. Текстның баштагы өч юл традицион «Коръән» аятьләреннән гыйбарәт, калган дүртенче, бишенче, алтынчы юллар татар телендә сөлес стилендә эшләнгән. Мәрхүмнең үлү датасы һиҗри 1095 ел, милади белән 1683\1684 елларга туры килә. Татарча өлеш тә традицион бер калыпта язылган.

**№ 20**

**Әгерже төбәге, Салагыш авылы эчендәге зираттагы ташбилге тексты (ташның баш, югары ягы ватылган, сакланган язмадан башлап күчерелде)**

1. الدنيا ساعة فَجَعَلها طاعة صدقا قال النبى
عليه السلام الد
2. نيا سجين المومين و جنت الكافر قال النبى

علیه السلام الدنیه جیفت و طالبها
3. کلاب تاریح مینکدا توقصان سکزدا یلقی یلی
4. دیرلار ایردی قوطلوعوجا اوعلی تلاوبردی
4. موللا اوزی وقتندا
5. ایرانلاردین دعا اومید اوچون. کورارمن دنیانی
ویران باری همیشه باقی ایرمس یوق قراری

**Салагыш авылы ташбилгесе текстының татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

3. Тарих миң дә туксан сигездә, йылкы йылы

4. дирләр ирди. Котлугуҗа углы Теләүбирде мулла үзи вакытында

5. ирәнләрдин дога өмид өчүн. Күрәрмен дөньйаны вәйран барый, һәмишә бакый ирмәс йук карары...

**Искәрмәләр**

Әлеге кабер ташы 1977 елның 3 июлендә Әгерҗе районы Салагыш авылының уртасындагы зиратында табылып өйрәнелде[1]. Ул вакытта ташның өске өлеше ватылып төшкән иде инде һәм аның язулары укырлык хәлдә түгел иде. Текст болай да урны-урны белән ватылып бозылган. Ләкин еллар күрсәткеченә зыян килмәгән. Коръән аятьләре язылган урыннарда җитешсезлекләр бар иде, ләкин алар стандарт – трафарет җөмләләр, җитешмәгән кисәк-сүзләрне реконструкцияләргә мөмкин. Безнең укылыш кеше исемнәрендәге аерым хәрефләрнең югалу сәбәпле, бездән соң бу ташны өйрәнгән башка галимнәрне беркадәр шөбһәләндереп, алар мәрхүмнең исемен башкачарак укыганнар – «Котлыгыш углы... ләүбирде»[2].

Ташның үлчәмнәре 16x47x65 см (ватылган кисәктән башка).

Текстның 4–5 юллары бик ашалган, уку читеенлек белән башкарылды.

Мәрхүмнең үлү датасы һиҗри 1098 ел, милади белән 1687 елга туры килә.

[1] Бу таш эчтәлегенә кагылышлы мәгълүматлар безнең «О лексике татарских эпитафий XVII–XVIII вв.» исемле 1983 елда басылган мәкаләбездә бар.

[2] Мәрданов Р., Һадиев И. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Б.79.

**№ 21**
**Катмыш зираты, тугызынчы ташбилге тексты**

1. ... ... سى
2. .... ترجعون ...
3. ... تولوش تاريح مينكدا
4. يوزدا يلان يل ...
5. ... ... الا ...

**Текстның татар телендәге өлеше**
3. Түлүш тарих миң дә
4. йөз дә, йылан йыл...

**Искәрмәләр**

Ташбилге бик ашалган, урта бер җирендә генә язулары калган. Язмалар уеп язылган. Таш төзек булмаган трапеция рәвешендә. Өске өлешнең киңлеге 75 см., аскы өлеш киңлеге 35 см. Калынлыгы 10 см. Ян яклары 80 әр см., известь таштан ясалган, егылып җирдә ята.

Куелу вакыты һиҗри 1100, татар-төрки календаре буенча йылан елы, милади буенча 1688–1689 елга туры килә.

**№ 22**
**Минзәлә төбәге, Бикбау авылы кырындагы икенче ташбилге тексты**

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قال النبى عليه السلام
2. الدنيه ساعة فاجعلها طاعة قال النبى عليه
3. السلام الدنيه جفة و طالبها كلاب ارى
4. تاريح منك دا يوز يل ايردى سلوك بيكباو اوعلى
5. اوز واقتندا بلوب ايرالاردين دوغا اوميد او
6. چون تمام ... قيلدى

Ташның сул кырында

1. بو بلکونی قویدی اوصتاز اوعلی آققوجاد
دوغا اومید اوجون

**Бикбау авылы иске зираты текстының татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. Тарих миң дә йөз йыл ирди, Сөлүк
Бикбау углы
5. үз вакытында белүб ирәнләрдин дога
6. өмид өҗүн тәмам ... кыйлды

**Ташның сул кырында:**
Бу билгүни куйды Остаз углы Акъкъуҗад
дога өмид өҗүн.

**Искәрмәләр**

Татарстан Республикасы Минзәлә төбәге, Бикбау авылы кырындагы тексты китерелгән таш язмалар кабартып язылган. Ташның үлчәмнәре: 16х45х95 см. Известь таштан кисеп ясалган һәйкәл 1992 елның сентябрь аенда беренче мәртәбә өйрәнелде, язмалары укылды. Минзәлә төбәгендә чыгарыла торган «Минзәлә» гәҗите хезмәткәре Дилфат Галиев ташның фотосурәтен алды.

Текстның баштагы өч юл язмасы «Коръән» аятьләреннән гыйбарәт. Дүртенче юлдан язма татар телендә башкарылган.

Ташның куелу тарихы руми хисап белән 1688\1689 елларга туры килә.

## № 23
## Менделеев төбәге, Бәзәкә авылы кырындагы XVII гасыр ташбилгесе тексты

1. هو الحی الذی لا یموت و کل حی سیموت
قال النبی
2. علیه السلام الدنیه ساعه ت فجعلها طاعه ت
صدق قال النبی علیه السلام الدنیه...

3. قال النبى عليه السلام ... جيفات...

...

4. تاريح مينكده يوز يل ايردى...

...يو بو بيلكنى ... ... ... اوعلى

5. ... اوز حلالى ايرانلاردين دعا اومد اوچون

6. كورارمن دنيا ...

...هميشه ... ... ... قارارى

**Эпитафик язма текстының татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. Тарих миң дә йөз йыл ирди, бу билгине ... углы

5. ................ үз хәлале ирәнләрдин дога өмид өчүн...

6. Күрәрмен дөньйаны...................... карары

**Искәрмәләр**

Бу текст язылган таш 1978 елда июль аенда археография экспедиция вакытында табылган иде. Ул вакытта экспедиция әгъзалары арасында әдәбиятчылар Әнвәр Шәрипов, Рәфис Әхмәтов һәм бу юлларның авторы бергә йөрдек. Ташны без Бәзәкә белән Песәй авылы арасындагы коры елга яры буенда таптык һәм аны бергәләп укып чыктык.

Таш Бәзәкәдән бер өч чакрым читтә иде. Аның зурлыгы 16х48х85 см., баш өлеше ватык, аннан эстампаж кисәге дә алдык. Кызганычка каршы аның яхшы фотосурәтен алу мөмкин булмады. Һиҗри 1100 ел, руми 1688–1689 елга туры килә.

Менделеев төбәге эпиграфикасын өйрәнүчеләр соңыннан бу таш турында ишетеп, ул табылган урынга килгәннәр[1]. Таш бу вакытта куелган урында булмаган инде. Алар аны Менделеев каласындагы төбәк музеенда икәнен ачыклаганнар. Ул вакытта ташның язулары тагын да таушалган булып, алар аны укый алмаганнар икән.

[1] Мәрданов Р. Һадиев И. Борынгы ташлар ни сөйли? // Мәйдан. – 2006. – № 8. – Б.157.

## № 24
## Әгерҗе төбәге, Наҗар авылы ташбилгесе тексты

1.هو الحي الذی لا یموت و کل حي سیموت
2. قال النبی غلیه السلام الدنیا ساغات فجعلها
3. طاعات صدق قال النبی غلیه السلام
4. الدنیه و سجین المؤمینا و جنت الکافیر
5. قال النبی غلیه السلام الدنیه جیفات و طالباها کلاب
6. تاریخ مینکده یوزده ایردی اوراز محمد اساي
7. خفظ اوغلي اوز واقتندا بلکي قویدي ایرانلاردین دعا اوچون

Ян кырыйларында

8. کورارمن دنیاني ویران باري
9. همیشا باقي ایرماس یوق قاراري

**Эпитафия текстының татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

6. Тарих миң дә йүздә ирди Ураз Мөхәммәд
Әсәй
7. хафиз углы үз вакытында билги куйдый
ирәнләрдин дога өчүн
8. Күрәрмен дөньйаны вәйран бары,
Һәмишә бакый ирмәс йук карары.

**Искәрмәләр**

Наҗар авылы зиратындагы XVII гасыр кабер ташы безнең тарафтан беренче мәртәбә 1977 елның 27 июлендә табылып укылды һәм аның буенча хәбәрләр дә басылып чыкты[1].

Аның куелу датасы һиҗри 1100, милади 1688–1689 елларга туры килә. Таш известьняк доломиттан ясалган, сакланышы яхшы. Аның югары өлешендә XVI–XVII гасырның башка эпитафик һәйкәлләрендәге кебек үк тимпанда үсемлек-чәчәк орнаменты ясалган. Орнамент уеп эшләнгән, эпитафик текст кабартып язылган.

Таш текстын бездән соң укучылар Әсәй исемен ялгыш укып – Исәк диеп таныганнар һәм язылышны архив чыганагында шулай

---

[1] Ахметзянов М.И. О лексике татарских эпитафий XVII–XVIII вв. // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983. – С.75, 78.

язылган дип эпитафик текстка үзгәреш кertкәннәр[1]. Хәлбуки текстны мондый очракта бозу ярамый, төзәтмәне астөшермәдә генә бирү кабул ителә. Исак булганда, бу сүзнең Исхак исеменнән ясалуына да фараз итәргә мөмкин.

Наҗар авылындагы бу тарихи таш янында кызыл кирпечтән бер кечерәк дөрбә дә корылган. Анда Наҗар авылының легендар ишаны күмелгән. Бу ишан турында халык телендә хикмәтле хикәяләр дә саклана. Һәйкәлнең үлчәмнәре: 21x46x110 см. тәшкил итә.

## № 25
## Әгерҗе төбәге Кодаш авылы ташбилгесе тексты

1. [الاد]نيا جيفات و طالبها كلاب تاريخ مينكد[ا]
2. يوزده ...س بالتاچ اوچون ايرانلاردين
دعا اوميد برلا اتاسى بيلكي قويدى الا
3. ...قالاسيندا ... اراق باستى كورارمن دنيانى ويران بارى باقى
ايرماس هميشه يوق قارارى

**Кодаш авылы ташбилгесе текстының татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

1. ................................ тарих миң дә
2. йөздә .... Балтач өчүн ирәнләрдин
дога өмид берлә атасы билги куйдый. Ала-
3. .......... каласында .... арак басты. Күрәрмен дөньйаны вәйран барый, бакый
ирмәс һәмишә йук карары.

**Искәрмәләр**

Кодаш авылының әлеге ташбилгесенең ватыклары белән 1977 елның 22 июлендә археографик экспедиция вакытында танышкан идек.

Ул вакытта таш яшь посадкадан бер 100 метрлар чамасы читтә ята иде. Тагын бер язусыз шул язулы ташның төбе булыр дип фараз ителгән, эшкәртелмәгән, 40x60 см. чамасындагы таш та шунда күренә иде. Кодаш кешеләре посадка эчендә ташның бер кисәге ята дигәч, анда эзләнүләребез нәтиҗәсез бетте. Бу кабер

---

[1] Мәрдәнов Р. Һадиев И. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: «Тамга» нәшрияты, 2008. – Б.74.

ташын шабашник әрмәннәр ватып бер кисәген мәктәп фундаментына файдаланганнар. Һәрхәлдә бу ташның язмышын авыл халкы белә иде. Без ташны мөмкин булган хәтле укып, фоторәсемнәргә төшереп, хәтта эстампаж да алып, аны авыл читендә калдырып киттек, минем яныма килеп сорашып торган кешеләр дә аны мин күтәреп китәрлек түгеллекне чамаладылар инде. Һәрхәлдә ул ташны мин менә 33 ел буе янына барып кабат күрә алганым булмады.

Ул ташның эчтәлеге белән кызыксынган университет галиме Раиф Мәрдәнов Мәскәү архивларында Балтач исемле һәлак булган затның тарихын эзләгәнен яза. Ул тапкан материаллардан Балтачның Кодаш янындагы «пүчинкәдә» яшәгән Балтач Колсары углы булуын фараз итәргә мөмкин. Чөнки аның кабере Кодаш белән Пүчинкә арасындагы уртаклык җиргә урнашкан булган. Текстта Балтач исеме янында, ватылган урында, «с» хәрефе элементы саклану шуңа ишарә итә.

Балтач XVII гасырның соңгы чирегендә һәлак булган.

Безнең Кодаш хакындагы мәгълүматларыбыз Р.Мәрданов һәм И.Һадиев китапларына да кертелделәр[1].

## № 26
## Менделеев төбәге Туйгуҗа авылындагы борынгы эпитафия тексты

1. هو الحی الذی لا یموت ...
2. ... ... ... ... ... ... ت الی ...
3. قال النبی علیه السلام الدنیا ...
4. الدنیا ساعة فَجَعلهَا طاعت ...
5. مزرعت الاخرت ا ساعات حرابا بعتبری
6. و لا یبقی مداما بالقراری تاریحی منکده یوز[ده]
7. توُروت ده دیرلار محرم ایندا صعر
8. یلندا ایردی بایکیلدی اوعلی اکیل اوعلی بالطا
9. ج اطاسنَا مُسلمانلاردن دُعا اومید
10. ...

[1] Мәрдәнов Р. Һадиев И. Әгерже төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: «Тамга» нәшрияты, 2008. – Б. 61–62.

**Текстның татар телендәне өлешенең укылышы хәзерге татар графикасында**

6. Тарих миң дә йөз дә
7. түрүтдә дирләр мөхәррәм айында, сыгыр
8. йылында ирди Байкилди углы Әкил углы Балта-
9. җ атасына мөселманнардин дога өмид...
10. .....................

**Искәрмәләр**

Туйгуҗа авылындагы бу тарихи таш 1978 елның июль аенда табылып, укылды. Ул вакытта кабер ташы колхоз фермасының капкасы төбендәрәк тимер-арматурадан эшләнгән чардуган эчендә тора иде. Язулары шактый уалган, алюминий порошогыннан ясалган буяу белән буялган иде. Бу таш һиҗри 1104 нче елның мөхәррәм аенда, ягъни ел башында куелган, милади хисап буенча ул 1692 нче елның декабрь ахырларына туры килә. Таш нык кына җиргә баткан, аны чардуган эченә кереп казып, соңгы юлындагы язуын укырга туры килмәде.

Ташта борынгы татарның унике еллык хайван календарыннан вакытның сыгыр (сыер) елында булуы теркәлгән. Сыер елы борынгы календарь циклының тәртип буенча икенче елына туры килә.

Ташның үлчәүләре: 27х58х115 см. зурлыкта, фотосурәтләре алынды.

Истәлек турында төп мәгълүматлар безнең 1983 елда басылган мәкаләбездә китерелә[1].

Бу таш белән кызынсынучылар соңыннан да булды[2]. Ләкин ул авторлар авылның исемен ***Тугыҗҗа*** дип язалар, чынлыкта ул Туйгуҗа дип атала, йөртелә. Исемнәрне болай бутау укучыларны ялгыштыруы бик мөмкин.

---

[1] Ахметзянов М.И. О лексике татарских эпитафий XVII–XVIII вв. // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань, 1983. – С. 79–81.

[2] Мәрдәнов Р., Һадиев И. Борынгы ташлар ни сөйли. – Б.158.

## № 27
## Менделеев төбәге, Татар Әхтиялы авылы ташбилгесе тексты

1.هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت
2. قال النبى عليه السلام الدنيا ساعات فجعلها طاعات
3. قال النبى عليه السلام الدنيا ... ...
4. تاريح منكدا يوزدا سيكزدا ايردى اسن بعابيكا حلالى
5. توق بيكه قويدى ايرانلاردين دعا اوچون

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. Тарих миң дә йөз дә сигездә ирди. Исәнбога биккә хәлали
5. Тукбикә куйды, ирәнләрдин дога өчүн.

**Искәрмәләр**

Татар Әхтиялы ташының датасы һиҗри 1108, милади 1696–1697 елларга туры килә. Материалы известняк, язулары күпертеп язылган, орнаментлар уеп эшләнгән. Ташның текстын без Татар Әхтиялы авылы яшьләренең теләген искә алып 2008 елның 18 февралендә фотосурәт аша укып яздык.

## № 28
## Әгерже төбәге, Яңа Акгуҗа авылы зиратындагы ташбилге тексты

1. هو الحي الذي لا يموت و كل حي سيموت قال النبي عليه السلام
2. الدنيا ساعه ت فجعلها طاعات صدق قال النبى عليه السلام
3. الدنيا سجن المؤمينه و جنت الكفر قال النبى عليه السلام
4. ...

**Искәрмәләр**

Яңа Акгуҗа (Акхуҗа) авылы зиратындагы XVII гасыр ташы 1977 елның 21 июлендә өйрәнелде. Ташның үлчәмнәре 20х45,0х64,0 см. Истәлекнең тимпанында гадәттәгечә XVII гасыр ташларына ошаган үсемлек орнаменты эшләнгән, ләкин Яңа Акгуҗа ташы орнаментының башкаларда очрамаган элементлары да күренә. Ташта кабартып язылган өч кенә юл «Коръән» аятьләрен-

нән гыйбарәт булган язма күренә. Текстның татарча өлеше югалган. Ләкин ташның Әгерҗе төбәгендәге башка XVII гасыр ахыры эпитафияләре белән үлчәмнәр якынлыгы, тимпандагы орнамент һәм шундый ук аятьләр кабатлануы Яңа Акгуҗа кабер өсте истәлегенең XVII гасыр ахырында куелган булуының саллы дәлиле. Кызганычка каршы бу истәлекнең 1977 елда фотосурәтен алу мөмкин булмады. Ташның аерым сүзләреннән эстампаж алынды.

## № 29
## Әгерҗе төбәге, Иж Бәйки авылы янындагы иске зират ташы фрагменты (әүлия ташы) тексты

کی قویدی ایرانلاردین دوعا اومد ...
[باق]ی ایرماس همیشه یوق قاراری

**Таш текстының хәзерге татар графикасында укылышы**

1. ки куйдый, ирәнләрдин дога өмид [өчүн]
2. [бак]ый ирмәс һәмишә йук карарый.

**Искәрмәләр (Әүлия ташы)**

Авыл кырыенда гына 3–4 каен агачы үскән бер кечкенә зират, рәшәткә белән әйләндереп алынган. 1977 елның июлендә әлеге ташны өйрәндек. Ул берничә кисәккә ваткаланган. Ташның өске өлешендәге бизәк урын сакланган бер зур кисәк һәм соңгы ике юл өлешчә һәм язуы булмаган аскы өлеше зур кисәк булып сакланган, алар 30х40 см. зурлыгындагы кисәкләр. Язмалар күпертеп гарәп язуының сөлес ысулында язылган. Һәр юл 2,5 см чамасы күпертмә сызык белән аерыла.

Сакланган хәтле тексттан фотокүчермә һәм ретушь ясап алынды. Таш XVII йөз ахырында куелган.

## № 30
## Мөслим төбәге, Катмыш зираты ташбилгеләре
## Унынчы ташбилге

Ташбилге утыртылган хәлдә тора, ләкин бер язу галәмәте дә калмаган. Известь таштан эшләнгән. Эшкәртелеп өске ягы дугасыман рәвештә. Үлчәүләре: 12х71х48 см. Аның шактый өлеше җиргә баткан, ныклабрак, казып өйрәнергә кирәк.

## № 31
## Катмыш зираты, унберенче ташбилге

Язуы беткән, өслеге шомартылган, ярты өлеше сынып җир астында калган. Үлчәмнәре: 11х45х51 см. Кабер ташы булуында шөбһә юк.

## № 32
## Катмыш зираты, уникенче ташбилге

Электр күчерү баганасы төбендә егылып ята, язулары ашалып беткән диярлек. Бары таш йөзлегендә ике урында الا‌ا һәм الموا кебек сүзләр танылалар. Язмалар уеп язылган булган.

Ташның калынлыгы 15 см, иңе 50, биеклеге диагональ буенча 98 см. Куелу вакыты XVIII йөзнең башы дип фараз итәргә мөмкин.

## № 33
## Катмыш зираты, унөченче ташбилге тексты

1. باهر ..د
2. ر... الموت
3. ر ... دار ...
4. ال...
5. سا...

**Искәрмәләр**

Ташта гарәп сүзләреннән калган аерым хәрефләр генә калган, текст юк.

Ташбилге басып тора. Үлчәмнәре 36х46–64х145 см. биеклеге. Калынлыгы 14–15 см. Начар гына эшкәртелгән ташбилге язулары уеп язылган булган. Куелу вакыты XVII гасыр башлары булса кирәк.

## № 34
## Катмыш зираты, ундүртенче ташбилге

Язулары тәмам кубып төшкән. Җирдә егылып ята, баткан. Кубарып, аскы ягын да карадым, язу юк. Таш турыпочмаклык рәвешендә: 11,7х44х104 см. Ташның калынлыгы 17 см.дан икенче башына юкара барып 11 см. кала.

## № 35
## Әгерже төбәге, Көчек авылы зиратындагы борынгы ташбилге

Көчек авылын һәм аның зиратындагы тарихи истәлекләр турындагы хәбәрләрне 1977 елның 28 июлендә өйрәндек.

Авыл зиратында без XVII гасырдан калган яззулы таш тапмасак та анда җирдә егылып яткан бер зур үлчәмле таш безнең игътибарны тартты. Ташның электә кабер ташы булганлыгын аның оч ягындагы фигурасы күрсәтеп тора. Без ул вакытта аның фотосурәтен дә төшереп алдык. Авылда бу ташның тарихын белүче булмады. Ташның җимерелү сәбәпле калынлыгы төрлечә. Без ул вакытлардагы үлчәүләр буенча аның үлчәүләре 15х58х188 см.

Бу ташка соңыннан башка белгечләр дә игътибар иткәннәр[1].

## № 36
## Катмыш зираты, унбишенче ташбилге тексты

1. هو الحى تعالى ...
2. قال ع.م المؤ منا ...
3. ن دار الفنادين دار البا ...
4. قال النبى الدنيا سعة ...
5. فجعنها طاعة ...ا ...حا
6. امئ لعق ... سفا
7. لا الله الا الله محمد رسول ...

[1] Мәрдәнов Р. Һадиев И. Әгерже төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: «Тамга» нәшрияты, 2008. – Б.63.

8. تاريح منكدا يوزدا اوتوز
9. بردا ايردى ...ا ... ات باى دنيا
10.... جمادى الاوّل اينده

**Катмыш ташбилгесенең эпитафик текстындагы татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

8. Тарих миң дә йөз дә утыз
9. бердә иде.

**Искәрмәләр**

Ташбилге егылып җиргә баткан, җирдән 10 см. югары күтәрелеп тора. Калынлыгын төгәл әйтеп булмый 15–20 см. булырга тиеш. Зурлык үлчәмнәре 67х115 см. Язулар уеп язылган. Дата һиҗри 1131, милади 1718 ел апрель башына туры килә.

Ташның аятьләр өлеше бик буталчык язылган, бу чукындыру дәвере, белем саегу күренеше белән бәйле булса кирәк.

Ташның тышкы күренеше: югары өлешендәге юлларда язулар ватылган. Таш формасы начар эшкәртелгән. Бу хәл бөтен Катмыш зираты ташларына карый диярлек.

**№ 37**

**Әлмәт төбәге, Габдерахман авылы зираты ташбилгесе**

1. بيكمحمد و[لد]
2. عبد الرحمن
3. ١٧٥٣ سنه نچى يل

Сул як кырыендагы язма

4. كتب عبد الرحيم

**Ташбилге текстының хәзерге графикада чагылышы**

1. Бикмөхәммәд вә [ләд]
2. Габдерахман
3. 1753 сәнә\нче йыл

**Сул як кырыендагы язма**

Кәтиб Габдерәхим

**Искәрмәләр**

Ташбилге Әлмәт төбәге Габдерахман авылы зиратында саклана. Аның үлчәмнәре: 30х100 см.(?). Ташбилге язулы йөзлек ягы белән чалкан егылып җиргә баткан. Шунлыктан аның текстының өстәге өч юл язмасы гына укырлык булып сакланган. Язмалар уеп эшләнгән. Һәйкәлнең тышкы сыны Азнакай төбәгендәге Сарлы авылы зиратында куелган 1783 елгы ташбилгегә ошаган. Бу ике истәлекнең бер оста кулы (Габдерәхим) белән эшләнүе ихтималы зур. Ташбилге атаклы Бикчура хан нәселеннән булган шагыйрь Габдрахман Тайсугани җәсаде өстенә куелган. Аны беренче мәртәбә 1997 елда табып укып, бу хакта матбугатта да язылды[1].

## № 38
## Азнакай төбәге, Чалпы авылының иске урнында табылган ташбилге тексты

1. ١٧٥٧ سنه يل
2. وفات بولدى
3. سعد تِمكا
4. اوعلى ... رمضان
5. ايندا جالبى آولیننك
6. جعفر ...د او ...یا

**Текстның хәзерге татар графикасында чагылышы**

1. 1757 сәнә йыл
2. вафат булды
3. Сәгыйдь Тимкә
4. углы ... рамазан
5. айында Җалбы авылыйның

Җәгъфәр ... ид... йа

**Искәрмәләр**

Бу ташның үлчәмнәре 14х40х83 см. Ул бүген Чалпы авылы дип аталган авылның беренче килеп утырган урнында булган.

---

[1] Әхмәтҗанов М.И. Үлгәннәрнең каберен бел. – Казан: «Мәгариф». – 2000. – Б.28.

Аны күреп, өйрәнеп калучы кеше Һарун Йосыпов була (1953 елда). Бу ташбилге хәзер югалган. Бу юлларның авторы аны 1976\77 һәм 2001 елларда ике мәртәбә күрсәтелгән тирәдән эзләп карады, ләкин таба алмаган иде.

Таш текстында искә алынган Тимкә исемле кеше XVIII гасырның башларында яшәгән, ул бу җиргә Шикәрле Каен авылыннан күчеп килгән булган. Аның исеме Чалпы шәҗәрәсендә дә сакланган. Ташбилге хакындагы мәгълүматларны Һарун Йосыпов хезмәтеннән алып кулландык[1].

## № 39
## Азнакай төбәге, Митрәй зиратыннан беренче ташбилге тексты

1. تاريح منكده يوزده
2. يتمش يدنچى يلده
3. اوفى اويزيننك
4. قازان يوليننك يوسف
5. كمانده سى ...ك
6. سـ ... نـى اوعلى قبر يدور

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих мең дә йөз дә
2. йитмеш йидинчи йылда
3. Өфе өйәзенең
4. Казан йулыйның Йосыф
5. камандасы .................... к
6. С ... ный углы кабридүр.

**Искәрмә**

Бу ташбилге 1979 елның июлендә Азнакай төбәгендә археографик экспедиция белән йөргән вакытта табылды. Язмалар ташка уеп язылган. Бу ташта да дини догалар бер дә язылмаган, гел тарихи хәбәрләрдән тора.

Аның һиҗри 1177 нче ел вакыты миладани 1763–1764 елга туры килә.

[1] Мирасханә. 72 ф. – 1 тасвир. – 73 саклау берәмлеге. – Б.243.

## № 40
## Азнакай төбәге, Митрәй авылы зираты икенче ташбилге тексты

1. معلوم اولنه
2. تاريح منكده يوزده
3. سكسان
4. اوچونچى يلننك اچنده
5. قازان اويازينك الاط
6. يولى يننك ميرضالار
7. اوروسيننك ملا رفيق
8. اوعلى خالد قبر يدور

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Мәгълүм улына
2. тарих мең дә йөз дә
3. сиксән
4. өченче йылның эчендә
5. Казан өйәзинең Алат
6. юлыйның Мирзалар
7. Оросыйның мулла Рафикъ
8. углы Халид кабридүр.

**Искәрмәләр**

Бу чыганак 1979 елгы археографик экспедиция вакытында Митрәй авылы зиратында табылды. Сакланышы яхшы, язулар уеп язылган, каллиграфиясе дә матур. Митрәй зиратындагы бу кабердә XVIII йөзенең башында атаклы татар мәгърифәтчесе Мортаза бине Котлыгыш мәдрәсәсенең шәкерте Рәфикъ бине Таиб әл-Курсави улы күмелгән. Рәфикъның бер углы Тубыл-Тара якларында кулъязма китаплар күчерү эше белән шөгыльләнә, өченче углы Ислам – Арча ягы Ташкичүдә яшәгән. Рәфикъ нәселеннән талантлы педагоглар, имамнар, галимнәр чыккан. Ташның һиҗри 1180 ел датасы, милади 1766–1767 елларга туры килә.

## № 41
## Ютазы төбәге, Бәйрәкә авылы
## иске зираты ташбилгесе тексты

1. اعلمو الله بسملله ... ... ... ... ... ... الرجيم
2. روفن طوابهون
3. الله اتيها العافلون
4. تاريح مسحيه ايله
5. ١٧٧٣ يلدا مرزه يوسف
6. قوتلوع محمد اوعلى
7. مشهد شهيد ... شير بتون نوش
8. قيلب ٥٥ عمر سوروب دار فنادين
9. دار البقايه رحلت قيلدى

Үлчәүләре 16/17 х 36/37 х 115 см

**Бәйрәкә зиратында ташбилге текстының укылышы һәм хәзерге татар графикасында чагылышы**

1. Әгүзе билләһи миннә шәйтани irražим
2. .................................................................

4. Тарих мәсихия илә
5. 1773 елда мирза Йосыф
6. Котлугъ Мөхәммәд углы
7. шәһид шәһидәнәт (кыйлынуб?)
8. кыйлыб 55 гомер сөрүбдар фанадин
9. дар бакайа рихләт кыйлдый

**Искәрмәләр**

Татарстан Республикасының Ютазы төбәге Бәйрәкә авылының иске зиратында бер фаҗигале хәлнең шаһиты булган гранит кабер ташы саклана. Аның дүрт ягыннан да гарәп хәрефләре белән язылган эпитафик тексты бар. Безгә ул ташның йөзлек ягындагы текстын 1997 нче елның 19 июлендә уку мөмкин булды. Язма ташка уеп язылган һәм граниттан укылышының кыенлыклары бар.

Ташта үзенең качкан крепостнойларын эзләп килеп Акбаш авылында алар белән очрашканда атып үтерелгән татар мирзасы Йосыф Тәфкилеф тарихы язылган. Үзе кешене кол итеп куюны максат итеп тоткан бу адәмне, аны яклаучылары үлгәч тә аклап – гадел эш өчен үлгән шаһид итеп игълан иткәннәр.

## № 42
## Әлмәт төбәге, Колшәрип авылы ташбилгесе тексты

1. اعوذ با الله من الشيطان الرجيم
2. بسم الله الرحمن الرحيم
3. سنه ١٧٨١ نچى ... قزان ...
4. ... بن عبد الله
5. ... ... ...

**Колшәрип авылындагы ташбилгенең тексты хәзерге графикадагы укылышта**

1. Әгузи билләһи миннә әш-шайтани әр-рәҗим
2. Бисмиллаһи әр-рахмани әр-рәхим
3. 1781 нче сәнә ............ Казан ................
4. ........................ бине Габдулла ........................
5. .......................................

**Искәрмәләр**

Бу ташбилгенең бик сирәк ташларда гына була торган бер үзенчәлеге бар. Ул бюстсыман рәвештә, йөзендә күз, борын, авыз, колак чалымнарын чамаларга мөмкин. Ихтимал, ул борынгы кыпчак, яки булмаса төрки балбаллары белән бәйләнештә ясалгандыр. Ташның үлчәмнәре: 31\38х51х85 см. зурлыкта. Язмалар гарәп язуының нәстәгъликъ ысулынча уелганнар. Аның турында мәгълүмат басылып чыкты[1].

[1] Әхмәтҗанов М. Үлгәннәрнең каберен бел. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2000. – Б.44.

**№ 43**
**Азнакай төбәге, Сарлы авылы борынгы ташбилгесе тексты**

1. سنه ١٧٨٣
2. يلندا ١١٩٧
3. ساراطاننك ١٣
4. ...ماهى رجب ننك ١٥
5. يومنده وفات بولدى
6. ايط ممت بن اشممت
7. بن اتناعول كل نفس ذأقات
8. الموت لا تدرى كل نفس باى ارض
9. لا فرت قال النبى ع م الدنيا مزرعت
10. ...جعلها طاعت قال النبى ع م
11. اليو تجلان فى قصور كم بين القوم
12. يحا وغدا تجلون ذوكم ...

**Текстның татар телендәге өлеше укылышы**

1. 1783 сәнә
2. 1197 йылында
3. Саратанның 13 дә
4. маһи рәҗәбнең 15-ндә
5. йәүмендә вафат булды.
6. Айыт Мәмәт бине Ишмәмәт
7. бине Атнагол

Эпитафик текстта барлыгы 15 юл язу бар, аларның 8–15 юллары дини фәлсәфә һәм «Коръән» аятьләре.

**Искәрмәләр**

Эпиграфик һәйкәл Сарлының иске зиратында, гадәти кабер ташларына ошамаган. Текстлар уеп язылганнар. Материалы яхшы сыйфатлы таштан эшләнгән.

Эпитафик истәлек 1979 елның 8 июлендә өйрәнелде, без аны яңадан 2002 елның җәендә карап узган идек, аның җиргә иңүе арта бара.

## № 44
## Әлмәт төбәге, Клементейкино авылы иске зиратындагы ташбилге тексты

1. ... الرحم ...
2. ... هجريه ...
3. تاريخ منك يتى
4. ... يوز سكسن يتينچى
5. ... ... ... ...

**Клементейкино авылы зиратындагы мәҗүсиләр ташбилгеләре арасында сакланган мөселман кабер ташы**

1. ................... әр-рәхим........
2. ........һиҗрийә
3. тарих мең йити
4. ... йөз сиксән йитинчи
5.

**Искәрмәләр**

Әлеге ташбилге бик начар гына итеп эшкәртелгән, үлчәмнәре 32х52х95 см. зурлыктагы дүрт кырлы таш плитәдән гыйбарәт. Аның соңгы юлында бер тамга да төшерелгән. Язмалар таш йөзлегенә уеп төшерелгән. Бу таштан ерак түгел тагын гарәп хәрефләре белән зур итеп «Аллаһ» дип язылган кабер ташы һәм тамгалы ташлар да бар. Ул ташлар да ныклап эшкәртелмичә генә куйганнар. Бу зиратны мәҗүси чуаш зираты дип таныйлар. Ул ташлар турындагы – безнең хәбәребез 2000 елда безнең хезмәтебездә басылган иде. Ләкин соңыннан ул ташларның 1993 елда Чабаксарда чуаш галиме А.А. Трофимов тарафыннан бозылып басылганын һәм аларга ялгыш интерпретация бирелгәнен күрергә туры килде[1]. Трофимов бу ташлардагы тамгаларны борынгы чуашлардан калган дигән фикер уздыра. Ләкин чуашлар Әлмәт якларына әле XVIII гасырларда гына килгәннәр һәм аларда кабер өстенә таш билгеләр кую 1870–1880 еллардан гына башлана.

[1] Трофимов А.А. Чувашская народная культовая скульптура. – Чебоксары: Чувашское книжное издательство, 1993. – С.62, 66, 67.

Борынгы болгарларның каберлекләрен өйрәнүче галимә Е.Халикова, аларда XII–XIII гасырда татарлар килгәнче кабер өсләренә агач яки ташбилгеләр кую турында бер мәгълүмат та булмаганлыгы турында яза[1].

## № 45
## Азнакай төбәге, Әсәй авылы иске зираты
## Чәүкә төбәге кабер ташбилгесе тексты

1. معلوم اولنور
2. تاريخ منكدا
3. يتى يوزدا تو
4. قسان التنچى
5. يلدا مرحوم
6. قمش سو
7. ... اوعلى

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Мәгълүм улыныр
2. тарих мең дә
3. йити йөздә ту-
4. ксан алтынчы
5. йылда мәрхүм
6. Камыш Су-
7. ... углы

.............

**Искәрмәләр**

Ташта текст уеп язылган, ташның үлчәүләре 15х40х60 см.

Материал 2000 елның августында уздырылган эпиграфик экспедиция вакытында табылды.

[1] Халикова Е.А. Мусульманские некрополи Волжской Булгарии X – начала XIII в. – Казань: изд-во Казанского университета, 1986. – С.124.

## № 46
## Әлмәт төбәге, Кама Исмәгыйль авылы ташбилгесе

1. فی ١٢١٢ سنه صاحب المرحوم فی التراب
2. ملا عبد الجليل بن ملا اشمحمد
3. البلعارى و بتاريح المسحية
4. فی ١٧٩٧ سنه

**Кама Исмәгыйль авылы зиратындагы ташбилгенең хәзерге татар графикасында укылышы**

1. фи сәнә 1212 әл-мәрхүм фи әт-тораб
2. мулла Габделҗәлил бине мулла Ишмөхәммәд
3. әл-Болгари вә би-тарих мәсхийәи
4. фи 1797 сәнә.

**Искәрмәләр**

Текст эшкәртелмәгән таш юка плитәгә уеп, каллиграфик язылган. Аны 1977, 1997 елларда табып өйрәндек.

## № 47
## Азнакай төбәге, Чалпы авылы иске зиратындагы ташбилге тексты

1. تاريح
2. مسحيه
3. ١٧٩٧
4. ...
5. ... بو قبر جعفر ...
6. ... ١٢١١ سنه

**Текстның татарча язылган өлешенең укылышы**

1. Тарих
2. мәшхия
3. 1797нче
4. ...

5. бу кабер Җәгъфәр
6. 1211 сәнә

**Искәрмәләр**

Ташбилгенең сакланышы начар, язулар бозылып беткән диярлек, алар уелып язылган. Мәрхүмнең Җәгъфәр исемле кеше баласы булуы аңлашыла.

## № 48
## Әлмәт төбәге, Габдерахман авылы зираты ташбилгесе

1. Гаденбану

**Ташның сул ягында**

1800 сәнә

**Искәрмәләр**

Таш начар сыйфатлы материалдан эшләнгән. Сакланган хәтле язмалары гарәп язуының сөлес стилендә язылган. Ташбилгенең үлчәүләре алынмый калган. Бу истәлек Әлмәт төбәгендә XVIII йөздән сакланган аз санлы эпитафияләрнең берсе. Ул 1977 елда беренче мәртәбә укылып, аның турында мәгълүматлар матбугатта чыгарылды[1]. Габдерахман авылы зиратында янә бер 1791 ел датасы гына сакланып калган ташбилге бар. Без аның ул вакытта фотосурәтен дә, үлчәүләрен дә алмаган идек (1977 елда).

[1] Әхмәтҗанов М.И. Үлгәннәрнең каберен бел. – Казан: «Мәгариф». – 2000. – Б.29.

# БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

## Урта Урал һәм Көнбатыш Себердәге татарларда XVII–XVIII гасырдагы ташбилгеләрнең текстлары

### Кереш

Урта Урал һәм Көнбатыш Себер төбәкләрендә табылган ташбилгеләр бу регионнарда, яшәгән һәм яшәүче татарларның рухи яктан бер халык булып, Казан һәм Касыйм ханлыкларындагы мәдәни традицияләрнең эчке бәйләнешен күрсәтүче кыйммәтле тарихи чыганаклар булып торалар. Бу регионда Урта Азия, Кавказ, Кырым яки Төркия мәдәни традицияләре гамәлдә булмыйча, Урта Иделдәге татар милли культурасының – Касыйм һәм Казаннан алып – Тубылга, Сафакүлгәчә бер платформада күтәрелеп үсеш нигезе чагыла.

Регион материалы Урта Урал һәм Көнбатыш Себер татар эпиграфика һәм эпитафия сәнгатенең XVII гасырдагы гомуммилли төс алуын ачыклау юлында мөһим бер баскыч булып тора. Без алардагы охшаш, һәм дә аермалы якларны да өйрәнергә тиешбез.

Бу регионнар материалын өйрәнү – татар этногенезына ревизия ясарга тырышкан аның милли дошманнарына һәм төрле дәгъвәләр күтәреп йөргән надан бәндәләрнең имансызлыгына альтернатив юнәлеш булып торган хәрәкәтдер.

Регионның эпитафик мирасы белән безгә кыр экспедицияләре юлы белән 2001–2002 елларда Дим буе татар төбәкләрендә, 2004–2005 елларда Оренбургта, Каргалыда, 2007 елда Троицкида, 2009 елда Чиләбе һәм Екатеринбургта, 2010 елда Курганда, Оренбург, Стәрлебаш якларындагы татар зиратларындагы материаллар аша танышырга туры килде.

Шулай ук без үзебезгә кадәр 1946–1967 елларда татар эпитафия сәнгатен системалы өйрәнеп хезмәт куйган Һарун Вәли улы

Йосыповның (1914–1968) фәнни мирасы белән танышып, файдаланып, аны бу хезмәтебездә даими күрсәтеп килдек.

Шулай ук үзебезгә кадәр татар эпиграфикасы һәм эпитафиясе проблемалары буенча хезмәтләр калдырган В.В. Вельяминов-Зернов, Каюм Насыйри, Гали Рәхим һәм бүгенге татар эпитафияләрен экспедицияләр юлы белән өйрәнеп килүче тарихчы-эпиграфист галимнәр Раиф Мәрдәнов, Ирек Һадиевлар, Венер Усманов һ.б. хезмәтләрен ихтирам итәбез. Аларның хезмәтләрендә XVII–XVIII гасыр татар эпитафияләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелгәнлеге күренә. Соңгы өч галим татар эпитафиясен өйрәнү өлкәсендә соңгы елларда иң зур активлык күрсәтәләр – китаплар һәм мәкаләләр язып фән дөньясына, халыкка җиткерәләр.

## № 1
## Благовар төбәге,Төркәй авылы татар зираты ташбилге тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت
2. قال النبى عليه السلام الدنيا ساعة فجعلها طاعة صدق
3. قال النبى عليه السلام الدنيا ...
4. تاريح مينكدا توقسان سكزدا ايردى بو بيلكنى
5. قوي[دى] محمد حافظ اوعلى ايكسان اتاسى اوچو
6. ن ايرانلاردين دعا اوميد اوچون تمام تمما

**Текстның татар телендә язылган өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. Тарих миң дә туксан сигездә ирди бу билгини
5. куйдый Мөхәммәд хафиз углы Иксән атасы
6. өчүн ирәнләрдин дога өмид өчүн...

**Искәрмәләр**

Ташның куелу вакыты һиҗри 1098, милади 1686\1687 елларга туры килә. Известьняктан ясалган XVII гасыр классик татар эпитафиясе үрнәге.

Бүгенге көндә Уфада крайны өйрәнү музее экспозициясендә тора. Укылыш бу хезмәт авторыныкы.

## № 2
## Йөрүзән елгасы тамагы ярында булган иске зират ташбилгесе тексты

7. 1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قا
8. 2. ل النبى عليه السلام الدنيا ساعة فجعلها طاعة صدق
9. 3. تاريح مينكده يوزدا بر يل ايردى الا ...
10. 4. مكاى اوعلى ثواب اوچون ايرانلاردين دعا او
11. 5. مد برلا بلك قويدى

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

3. Тарих миң дә йөз дә бер йыл ирди. Ала...
4. Мәкәй углы, саваб өчүн, ирәнләрдин дога ө-
5. мид берлә белек куйды.

**Искәрмәләр**

Таш известьняктан кисеп ясалган. Аның үлчәүләре – 21х44х 149 см. зурлыкта. Язмалары күпертеп язылган. Ташның тимпаны – орнаментлы классик татар кабер ташы үрнәгендә төшерелгән.

Куелу вакыты һиҗри 1101, милади 1689–1690 елларга туры килә. Бу ташбилге текстында татар эпитафияләрендә бик сирәк очрый торган ***саваб*** сүзе кулланылган.

Ташбилгене беренче булып Һарун Йосыпов ачкан, укыган һәм сурәткә алдырган, аның тарихыбыз өчен кыйммәте бәхәссез[1].

## № 3
## Аскын төбәге, Кыйгазы авылы иске зиратындагы беренче ташбилге тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت
قال النبى عليه السلام
2. الدنيا ساعة فجعلها طاعة صدق تاريح منكدا
3. يوزدا بر يل ايردى اشكاى اوعلى توى كيلدى بيلكى نى
4. قويدى اوز باقتندا ايرانلاردين دعا اومود اوچون

**Эпитафик текстның татарча юлларының хәзерге графикада чагылышы**

1. … … … … … … … Тарих миң дә
2. йөз дә бер йыл ирди, Ишкәй углы Туйкилди билгини
3. куйды, үз бакытында ирәнләрдин дога өмүд өчүн

**Искәрмәләр**

Бу ташбилгене Һарун Йосыпов 1956 елда Кыйгазы авылының иске зиратында таба. Ул вакытта ике эпитафик истәлек табылган була. Типологик яктан алар XVI–XVII гасыр татар кабер ташларыннан аерылмаган. Истәлекнең өске өлешендәге арканың тимпанында татар милли кабер ташларындагы шикелле үк үсемлек орнаменты эшләнгән. Текст язмалары күпертеп эшләнгән, орнаментлар уеп ясалган. Ләкин орнамент һәм язмалары җилдән ашалып бик начар сакланган. Таш известьняктан эшләнгән. Аның үлчәмнәре:

[1] Мирасханә: 72 ф. – 1 тасвир. – 30 саклау берәмлеге. – Б.31, 32, 83.

16,5x52–46 (өскә таба тараеп менгән)x125 см. Истәлекнең куелу вакыты һиҗри 1101 ел, милади 1689/1690 елга туры килә[1].

## № 4
## Чишмә төбәге, Түбән Тирмә ташбилгесе тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى
2. سيموت قال النبى عليه السلام و كل
3. نفس ذايقة الموت صدق الدنيا ساعة
4. فجعلها طاعة تاريخ مينكدا يوزدا يتدا ايردى
5. قوباونك ... اوعلى طقى بطورنك
6. بيلكوسى ... ايرانلاردين دعا
7. صدق الدنيا جفة طالبها [كلاب]

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. Тарих миң дә йөз дә йитидә ирди.
5. Кубауның ......... углы Такый батырның
6. билгүси ........ ирәнләрдин дога

**Искәрмәләр**

Ташбилге Чишмә станциясеннән 12 км. ераклыкта Тура хан дөрбәсе якынында, иске зиратта табылган[2]. Дөрбә тирәсе иске зират урны булганлыгы хәзер дә беленеп тора.

Ташбилгенең үлчәүләре: 28x58x150 см. Ул типологик яктан Татарстанда һәм Чуашиядә сакланган XVII гасыр татар ташбилгеләреннән аерылмый. Аның өсте почмаклы (очлы) арка белән төгәлләнә, тимпанда милли традицион татар эпитафия орнаменты, язмалар күпертеп язылган. Материалы ак известь ташы (керәч). Текстта «Кубау» дигән атама, кабиләне аңлата. Кырымда татар этнонимы меңнән алынган «Мәң-куб» дигән шәһәр атамасы белән таштагы Кубау этнотопонимы арасында генетик бәйләнеш

---

[1] Текст Мирасханәдән: 72 ф. – 1 тасвир. – 30 саклау берәмлеге, 33 биттән алынды.

[2] Бу истәлекне Һарун Йосыпов беренче мәртәбә 1953–1954 елларда табып өйрәнеп, аны фоторәсемгә төшереп текстны укып, күчереп алган (Мирасханә: 72 ф. – 1 тасвир. – 30 саклау берәмлеге. Б. 34–36). Текст һәм искәрмә материалы Һ.Йосыпов хезмәте буенча алынды.

бар. Димәк, Чишмә төбәгендә меңнәр исемле татар кабиләсе вәкилләре XVII гасырда да яшәп яткannar. Ташның куелу датасы һиҗри 1107, милади белән 1695–1696 елларга туры килә. Бу бик кызыклы дата, чөнки Чишмә станциясе янындагы зират ташларының күбесе шушы һиҗри 1107 елда куелганнар.

## № 5
## Чишмә станциясе янындагы борынгы татар зираты ташбилгесе тексты

1. هو الحی الذی لا یموت و کل حی سیموت
2. قال االنبی علیه السلام و کل نفس ذایقة الموت
3. صدق الدنیا ساعة فجعلها طاعة تاریخ منکدا
4. یوزدا یتی دا ایردی مینکنك یماش
5. اوعلی اردَقنینك بیلکوسیدور
6. ایرانلاردین دوعا اوچون

**Текстның татан телендәге юлларының хәзерге графикада чагылышы**

3. ................................Тарих миң дә
4. йөз дә йитидә ирди. Миңнең Йамаш
5. углы Ардакныйң билгүсидүр
6 ирәнләрдин дога өчүн

**Искәрмәләр**

Таш ак известь таштан (кырачтан) кисеп эшләнгән. Үлчәүләре: 27x64x120 см. Текстлар күпертеп язылганнар. Тимпан орнаменты XVI–XVII гасырлардагы милли татар үсемлек орнаменты, уеп төшерелгән. Арткы ягында уеп тамга ясалган  рәвешендә. Ташның куелу вакыты һиҗри 1107, милади белән 1695–1696 елларга туры килә.

Ташны 2001 елны укыган вакытта без аның текстындагы 5 юлда язылган исемне «***Артык***» дип укыган идек. Ләкин соңын-

нан кабаттан бу темага кайткач аны «*Ардак*» дип укуны билгелəдек. Баштагы укылыш безнең хезмəтебездə басылган иде[1].

## № 6
## Чишмə станциясе кырыендагы татар зиратыннан икенче ташбилге тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل
2. خي سيموت قال النبى عليه السلام
3. كل نفس ذايقة الموت صدق
4. الدنيا ساعة فجعلها طاعة تاريح
5. مينكدَا يوزدا يتيدا ايردى اسرْكاب
6. قزى شِن بكاننك بِلكوسى دور اوعلى
7. يونس بيقيلدى ايرانلاردين دوعا اومد [اوچون]

**Таш текстының татар телендəге өлешенең хəзерге графикада чагылышы**

4. ......................Тарих
5. миң дə йөз дə йитидə ирде. Исеркəб
6. кызы Шийүн бикəнең билгүсидүр. Углы
7. Йуныс би[на] кыйлдый, ирəнлəрдин дога
өмид [өчүн]

**Искəрмəлəр**

Таш беренче мəртəбə 2001 елның ноябрендə укылып, тексты күчерелеп, фоторəсемгə төшереп алынды. Ташның үлчəүлəре: 25х55х127 см.зурлыкта. Куелу вакыты һиҗри 1107 елда милади 1695–1696 елга туры килə. Язмалар күпертеп, ак известь таш өстенə язылганнар. Текст 2002 елда Казанда китапка кертелеп басылды[2].

Бу текстта Сөенбикə исеменең «ш»лаштырылып язылуы тел тарихчылары өчен бер кыйммəтле факт. Аның янə бер очрагын без тагын бер эпитафик текстта сакланган Шалтыйк исемендə дə очраткан идек инде. Бу фактлар мəрхүмнəрнең Нугай Урдасы татарлары булу ихтималын күрсəтəлəр.

---

[1] Əхмəтҗанов М.И. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: «Мəгариф», 2002. – Б.129.

[2] Əхмəтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: «Мəгариф», 2002. – Б.127.

## № 7
## Чишмә станциясе зиратындагы өченче ташбилгенең тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قال النبى
2. عليه السلام ... ... ... كل نفس ذايقة الموت صدق الدنيا
3. ساعة فجعلها طاعة قال النبى عليه السلام الدنيا
4. جفت و طالبها كلاب تاريخ مينكدا يوزدا
5. يتى دا ايردى ايل ممت قزى يوكا بيكا
6. بيلكوسيدر ايرانلاردن ...

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. .........................Тарих миң дә йөз дә

5 йитидә ирди, Илмәмәт кызы Йүкәбикә

6. билгүсидер, ирәнләрдин [дога өмид]

**Искәрмәләр**

Эпиграфик истәлек 2001 елның ноябрь аенда өйрәнелде. Истәлек ул вакытта җиргә чалкан авып, беркадәр җиргә баткан иде. Текстның аскы ягындагы юлы, таш сынган вакытта беркадәр бозылып, язма зыян күргән.

Ташның үлчәмнәре: 22х66х112 см. Текст известь ташка күпертеп язылган, 3–4 юллары нык бозылган хәлдә. Куелу тарихы һиҗри 1107-нчегә туры килә, милади 1696 елга карый.

Ташның тексты безнең тарафтан 2002 елда татарчага тулы тәрҗемәдә һәм кирилл хәрефләре белән матбугатка чыгарылды[1].

## № 8
## Чишмә станциясе янындагы татар зиратындагы дүртенче ташбилге тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل
2. حى سيموت قال النبى عليه السلام

[1] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: «Мәгариф», 2002. – Б. 128–129.

3. كل نفس ذايقة الموت صداق
4. الدنيا ساعة فجعلها طاعة صداق الدنيا جفة طا
5. لبها كلاب تاريخ مينكدا يوزدا بتى دا
6. ايردى منكنك اسرْكاب قزى طولنبى بلكوسى
7. كوره رمن دنيا وايران بارى همشه ايرمس
8. باقى يوق قرارى ايرانلاردين دوعه

**Язманың татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

5. ......... Тарих миң дә йөз дә йитидә
6. ирди. Миңнең Исеркәб кызы Тулынби билгүси
7. Күрәрмен дөньйа вайран барый һәмишә ирмәс [бакый]
8. йук карары. Ирәнләрдин дога

**Искәрмәләр**

Ташбилге ак известь таштан кисеп ясалган. Үлчәүләре: 23x38x126 см. Текст күпертеп язылган. Уң як кырында  тамгасы уелган. Ташның куелу вакыты һиҗри 1107, милади 1695–1696 елга туры килә. Текст беренче мәртәбә 2001 елда өйрәнелде һәм матбугатка беренче мәртәбә чыгарыла.

## № 9
## Чишмә станциясе иске зиратындагы Амангилде углы Шалтыйк байның ташбилгесе тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت
2. قال النبى عليه السلام و كل نفس ذايقة الموت
3. صداق الدنيا ساعة فجعلها طاعة قال النبى عليه
4. السلام الدنيا جيفة و طالبها كلاب
5. تاريخ مينكدا يوزدا يتى دا ايردى مينكنيك
6. اَمان كيلدى اوعلى شَالطَيق باي
7. نيك بلكوسى دور بو لوحنى اوعلى
8. يونس باى بيقيلدى ايرانلاردين دوعه

**Текстның татар телендәге юлларының хәзерге графикада чагылышы**

5. Тарих миң дә йөз дә йитидә ирди Миңниң
6. Аманкилди углы Шалтыйк бай-
7 ныйң билгүсидүр, бу ләүхәни углый
8. Йуныс бай би (на) кыйлдый, ирәнләрдин дога

**Искәрмәләр**

Ак известь таштан ясалган плита, габарит үлчәүләре: 21х47х127 см. зурлыкта. Ташның архитектура тибы XVI–XVII гасыр татар эпиграфика үрнәкләре белән тәңгәл. Язмалар эшләнү ысулы – күпертеп ясау – шулай ук татар кабер ташларыныкына охшаш. Текстлар структурасында да тик индивидуаль аермалыклар гына сирәк кенә күзәтелә. Татар эпиграфик истәлекләренең киң географик пространствода тотрыклы үзенчәлекләрне XVI–XVIII гасыр башларына кадәр тотрыклы сакланышта яшәтүе, аның инде тагын бер мәртәбә бердәм милли культура тәшкил итүенең күрсәткече. Кабер ташларындагы борынгы татар исемнәренең, казак һәм нугай халыклары антропонимикасы белән бердәмлеге дә тарихи узганның кадерле мирасын тәшкил итә.

Мәсәлән, анализланган тексттагы ***Шалтыйк*** антропонимы төрекләрдә һәм кырым татарларында мәгълүм булган ***Салтыйк*** этнонимы һәм антропонимы тәңгәллегенең бер очрагы буларак кызыклы.

Ташның язылу датасы һиҗри 1107, милади белән 1695–1696 елларга туры килә. Аның сул як яңагында  тамгасы уеп ясалган. Ул кыят кабиләсе тамгасының бер ыру вариантын тәшкил итә.

Текст эчтәлеге беренче мәртәбә 2002 елда матбугатта игълан ителде[1].

**№ 10**
**Чишмә станциясе иске зиратындагы**
**Мөхәммәдкол углы Йамаш байның ташбилгесе тексты**

[1] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: «Мәгариф», 2002. – Б.126.

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت قال
2. النبى عليه السلام و كل نفس ذايقة الموت
3. صدق الله الدنيا ساعة فجعلها طاعة الدنيا جفة
4. طالبها كلاب تاريخ مينكدا يوزدا يتى دا
5. ايردى مينكنك محمد قوُل اوعلى يماش
6. باى نك بلكوسى دور ايرانلاردين
7. دوعه

**Текстның татар телендә язылган өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

4. ......................Тарих миң дә йөз дә йитидә
5. ирди. Миңниң Мөхәммәдкол углы Йамаш
6. байның билгүсидүр, ирәнләрдин
7. дога

**Искәрмәләр**

Эпитафик язма 2001 елның 11 нояберндә беренче мәртәбә өйрәнелеп, сурәткә дә төшереп алынды. Ул ак известь ташка күперетеп язылган. Тимпан бизәге уеп төшерелгән.

Ташның үлчәмнәре: 27х64х145 см. Аның арткы стенасында  тамга уеп ясалган. Куелган вакыт һиҗри 1101, милади белән 1695–1696 елга туры килә.

Текст матбугатта бер мәртәбә игълан ителде[1].

## № 11

## Чишмә станциясе янындагы иске зираттагы Йамаш углы Нуркәй батырның кабер ташы (1695/1696) тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى
2. سيموت و قال النبى عليه السلام كل نفس ذا
3. يقة الموت صداق الدنيا ساعة فجعلها طاعة
4. تاريخ منكدا يوزدا يتى دا ايردى يماش
5. اوعلى نوركاى باطُورنك بلكوسدور
6. مينكنك ايرآنلاردين دوعه اومد

[1] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: «Мәгариф», 2002. – Б.128.

7. صداق الدنيا جفة و طالبها كلاب

**Нуркәй кабер ташындагы язманың хәзерге татар графикасында чагылышы**

4. Тарих миң дә йөз дә йитидә ирди, Йамаш
5. углы Нуркәй батырның билгүсидер
6. Миңниң ирәнләрдән дога өмүд

**Искәрмәләр**

Һәйкәл ак известь таштан кисеп ясалган. Габарит үлчәүләре: 24х65х142 см. зурлыкта. Текстлар күпертеп сөлес ысулынча язылган. Ташның сул як янында  рәвешендәге тамга сурәте төшерелгән. Куелу вакыты һиҗри 1107, милади белән 1695–1696 елларга туры килә. Ташның тексты беренче тапкыр матбугатта игълан ителде[1].

## № 12
## Чишмә төбәге Чишмә стациясе янындагы зират ташы тексты

1. هو الحى الذى لا يموت و كل حى سيموت
2. و كل نفس ذايقة الموت صدق الدنيا ساعة فجعلها طاعة
3. قال النبى عليه السلام الدنيا جفة و طالبها كلاب ارى الدنيا
4. حربا بعتبارى فلا يبقى مداما بالقرارى تاريح
5. مينكدا يوزدا يتى دا ايردى قوتلوبى اوعلى سولطان
6. بى بلكوسى دوعا

**Текстның татар телендә язылган өлешенең бүгенге графикада чагылышы**

4. ..................... Тарих
5. миң дә йөз дә йитидә ирди
Котлы би углы Солтан
6. би билгүси, дога

**Искәрмәләр**

[1] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: «Мәгариф», 2002. – Б.127.

Ташбилге ак известь таштан кисеп, шомартып эшләгән плитәне тәшкил итә. Аңа язмалар күпертеп, ә тимпандагы үсемлек орнаменты уеп төшерелгән. Архитектур төзелеше ягыннан уникаль үзенчәлекле XVI–XVII йөз (башы) татар ташбилгеләренең бер үрнәге. Аның үлчәүләре 24х50х94 см. габаритын күрсәтә.

Бу ташның бер яны ягында түгәрәк штампка, гарәп хәрефләре белән таш ясаучы оста исеме дә күрсәтелгән булган. Ул язмада «Миңниң... бу ләүхәне басты» дигән фраза күренә, кызганычка каршы останың исеме бозылган. Бу очракта без Петр I патшаның татарларга металл һәм таш эшләре белән шөгыльләнүне тыюны күрәбез.

Солтан би кабер ташы без 2001 елның 9 ноябрендә Чишмә зиратын өйрәнгән көннәрдә күренмәде. Аның текстын без Һарун Йосыпов хезмәтеннән күчереп алдык[1]. Ләүхәнең куелу вакыты һиҗри 1107, милади 1695–1696 елларга туры килә.

## № 13
## Чишмә станциясе янындагы зират ташбилгесе тексты

1. هو الحى الذى لا يموت
2. و كل حى سيموت
3. ...
4. ... محمد رسول الله
5. ... اقچورا
6. ولد ... ديار ...
7. ... حكم ...
8. دنيادين
9. باردى

**Текстның татар телендәге язылган өлешенең эчтәлеге**

8. дөньйадин
9. бардый

**Искәрмәләр**

Комташтан эшләнгән эпитафик истәлекнең үлчәмнәре 23х48х 108 см. Ул физик яктан бик ашалган, язулары да күп урыннан купкан.

[1] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.-Л: Изд-во АН СССР, 1960. – Таблица № 74.

Ташбилгенең габаритына һәм язу үзенчәлекләренә караганда, ул XVIII йөз башларында куелган дип фикер йөртергә мөмкин.

Язмалар гарәп графикасында уеп язылганнар.

Чишмә станциясендәге иске зираттагы борынгы бер ярым җимерек комташ эпитафия бар. Бу таш янында XVIII гасыр башларында куелган комташтан ясалган кабер ташбилгеләре булу, аны да шул ук дәвердән санарга мөмкин дигән фикердә калабыз. Аның габарит үлчәүләре 18х39х97 см. Язмалар уеп язылган. Ташның йөзлек ягында  тамгасы ясалган. Түбәндәге юллары тәмам җимерелеп беткән. Әлеге ташбилге мәгълүматлары 2001 елның ноябрендә өйрәнелеп, матбугатка беренче мәртәбә тәкъдим ителә.

**№ 14**
**Чишмә станциясе янындагы иске зират ташбилгесе тексты**

1. تاريخ بنكدا
2. يوزدا اون
3. بشدا دور
4. لا اله الله لا
5. محمد رسول الله
6. و ...
7. سكم
8. دنيادين
9. باردى

**Ташбилгедәге текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих биң дә
2. йөз дә ун
3. бишдәдүр
8. дөньйадин
9. бардый

**Искәрмәләр**

Ташбилгенең габариты үлчәүләре: 23х25х116. Сакланышы начар һәм уку да четерекле. Аның куелу вакыты һиҗри 1115,

милади 1703–1704 нче елларга туры килә. Йөзлек ягында өстә тамга сурәте –  бар. Ул татарларның Кыят кабиләсенең тамгасы санала. Материалы ак известь таштан, язулары уеп язылган, почеркы бик начар.

Аның өйрәнелеше 2001 елның ноябрендә булды.

## № 15
## Кушнаренко төбәге, Мәүлет авылы зираты ташбилгесе тексты

1. تاريح منك يوزدا
2. اون سكزدا ايردي
3. ايدل عوجا اوعلى قدر
4. بردى اوعلى سيتك
5. اوعلى يحشى بردى
6. اوعلى نركاى
7. زيارتى دوانى
8. ايلونك تمعاسى
9. قوش //

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих миң йөз дә
2. ун сигездә ирди
3. Иделгуҗа углы Кадер-
4. бирде углы Сәйтәк
5. углы Йахшыбирде
6. углы Нөркәй
7. зиарәте Дувани
8. илүнең тамгасы
9. кош II

**Искәрмәләр**

Бу таш Һарун Йосыпов тарафыннан БАССРның Кушнаренко төбәге Мәүлет авылында 1954 елны табылып укылган. Һарун Йосыпов бу авылда һәм аның тирә-ягында мишәр татарлар яшәгәннәрен билгеләп үтә.

Ташның тексты татар телендә язылган. Ул һиҗри 1118 елда, милади 1706–1707 елларда куелган. Язулар ташка уеп язылган. Ташның үлчәүләре 15х38х77 см. Татар мишәрләр бу якларга Пенза һәм Тамбов якларыннан килгәннәр. Аларның бер өлеше хәзерге Татарстан Республикасының Чүпрәле төбәге Иске Дуван һәм Яңа Дуван авылларында да туктап калганнар. Соңыннан Иске Дуваннан алар Чәрмәсән елгасының уң як ярларына да килеп утырып, үзләренең иске илләрен Дуванны да хәтерләрендә тотканнар. Аларның хәтта бу дәверләрдә тамгалары да сакланган булган, аның исеме «Кош кабыргасы» кыяфәте  рәвешле. Без бу тамганы Нугай Урдасыннан Меңнәр исемле татар кабиләсенеке (Урдаҗ бинеке) икәнен дә беләбез.

Г.В. Юсупов бу кабер ташын гомердә дә кабер өстенә ташлар кую традициясе булмаган башкортларга бәйләп ялгыша, Уфадагы сәясәткә хезмәт итә башлый.

**№ 16**

**Чишмә станциясе янындагы татар зираты ташбилгесе тексты**

1. ... ... ... ن
2. تاریح نینك هجرتنینك
3. مینکدا یوزیکرمی
4. یلیدا دونیادین باردی
5. قالو انا الله و اینا الَه
6. ... ... راجعون
7. لا الا اله الله محمد
8. رسول الله
9. 

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

2. ... тарихның һиҗрәтнең
3. миң дә йөз дә йегерми...
4. йылыйда дөньйадин барды.

**Искәрмәләр**

Эпитафик таш үлчәмнәре 30–10х56х73 см.зурлыктагы коңгырт төстәге комташтан ясалган. Һәйкәл түбәннән өскә таба очлаеп килә. Аның өске өлешендәге текст нык зыян күргән. Язмалар уеп язылган, гарәп графикасында сигез юл булган. Тугызынчы юл булып тамга төшерелгән. Тамга ике ыру тамгасын белдерә. Аның берсе  «кош кабыргасы» – татарның меңнәр кабиләсенеке, икенчесе ыргак тамга  – тамъйан кабиләсенеке. Аларның икесе дә Нугай Урдасы татарларында танылган булган. Ташның куелу вакыты һиҗри 1120, милади – 1708\1709 елларга туры килә.

## № 17
## Чишмә станциясе кырында иске татар зиратында сакланган Тиләкәй Акчура углы кабер ташы тексты

1. بسم الله الرحمن الرحيم
2. و هو حي لا يموت
3. كل شي سيموت
4. لا اله الا الله محمد رسول الله
5. تريخ مينكده يوزدا اوُطظ
6. جتيدا تيلاكاى اقچو
7. را اوعلى فانى
8. دنيادين نقل قيلدى

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

5. Тарих миң дә йөз дә утыз
6. җитидә Тиләкәй Акчу-
7. ра углы фани
8. дөньйадин нәкыль кыйлды.

**Искәрмәләр**

Таш – типик эшкәртелгән плитәдән нык аерыла. Ул кыргый комташтан беркадәр генә йөзлек ягы эшкәртеп ясалган. Аның габарит үлчәүләре – 40х78х120 см. зурлыкта, аңа сигез юл гарәп графикасының тәгъликъ ысулында уеп текст язылган. Аның фигурасы өскә таба конуссыман китә. Бу ташта инде без татар эпиграфикасының XVI–XVII йөзләрдәге классик формасының

Петр «Великий» реформалары нәтиҗәсендә тәмам юкка чыкканлыгын күрәбез. Шушы дәвердән Казан һәм Касыйм ханлыкларыннан бирле үсеп килгән борынгы традиция киселә. Икенче яктан бу дәвердә татар феодал катлавының юкка чыгарылуы да традициянең югалуына этәргеч була.

Ташның куелу вакыты һиҗри 1137, милади 1724–1725 елларга туры килә. Текст беренче мәртәбә 2002 елда маттбугатта дөнья күрде[1].

Ташбилгенең уң як яңагында  сәнәк тамга уеп ясалган. Ул «сиркә» тамга дип аталып, аны Уйшин Майкы бигә бирелгән тамга дип саныйлар. Майкы би нәселенең шәҗәрәләре татар арасында Буа, Саба, Ык, Дим елгалары буйларында мәгълүм.

## № 18
## Чакмагыш төбәге, Иске Бәшир авылының иске зиратыннан Тимербылат Муса углы ташы (1766–1796) тексты[2]

1. ١٧٩٦ سنه يلده
2. تمربلات موسى
3. اوعلى دارفنادين
4. دار بقايه نقل قيلدى
5. اوتز ياشنده
6. وقد قتل بضلم

**Текстның алты юлындан бишесе иске татар телендә, соңгы юл гарәп телендә (соңгысын тәрҗемә итеп бирәбез)**

**Текстның укылышы**

1. 1796 сәнә йылда
2. Тимербылат Муса
3. углы дарел-фанадин
4. дар бакайа нәкыль кыйлды

[1] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: «Мәгариф», 2002. – Б.130.

[2] Текст Һарун Йосыпов тарафыннан табылып өйрәнелгән. Аның хезмәте мирасханәдә: 72 ф. – 1 тасвир. – 30 сак.бер. – 52 бит. Материал шуннан алынды.

5. утыз йәшендә
6. кател бизолым белән үтерелде.

**Сүзлекчә**
Дарел-фанадин – фани дөньядан
Дар бакайа – мәңгелек йортына, теге дөньяга
Нәкыйль кыйлды – күчте
Кател бизолым – көчләп үтерелде.

**Искәрмәләр**

Бу таш татар мирзалары фамилиясеннән булган Еникеевларга кагылышлы кешегә куелган. Ташның үлчәүләре 12х47х140 см. Еникеевлар нәселе бүгенге Мордовия Республикасына карый торган Төмән (Темников) өязеннән булып, аларны «төмәннәр» дип атыйлар.

## № 19
## Иске Бәшир авылы зиратыннан кенәз Муса Җәнәкәев (1739–1804) кабер ташыннан текст

1. ١٨٠۴ سنه
2. نچی یلده موسی
3. ندر اوعلی التمش
4. بش یاشنده دار
5. فنادین نقل قیلدی
6. کناز موسی جنکایف

**Таш текстының хәзерге графикада укылышы**
1. 1804 сәнә
2. нче йылда Муса
3. Нәдер углы алтмыш
4. биш йәшендә дар
5. фанадин нәкыль кыйлды
6. Кенәз Муса Җәникәйеф.

**Искәрмәләр**

Ташның габарит үлчәмнәре: 14,5х52х145 см. Һарун ага Йосыпов үзенең хезмәтендә «төмәннәр» тарихына да тукталып уза[1].

## № 20
## Кыйгазыда табылган икенче ташбилге тексты

1. هو الحى الذى [لا يمو]ت و كل ح[ى]
2. سيموت قال النبى [عليه السلام الدنيا سه]
3. عه ت فجعا [لها طاعت] ...
4. تاريخ منك[دا] ...
5. [بو] بلكنى قويدى ... ايرانلاردين
6. [دعا] او[مد ...ا]وچون

**Таш текстының татарча юлларындагы сүзләрнең хәзерге графикада чагылышы**

4. Тарих миң [дә]...
5. [бу] билгини куйдый ..... ирәнләрдин
6. [дога] ө[мид ... ө]чүн

**Искәрмәләр**

Таш текстының җилләр белән нык ашалуы сәбәпле язуларның күп өлеше беткән. Ташбилгенең үлчәмнәре 16/22х44х128 см.

Истәлекнең типологик яктан да һәм беренче таш белән бер үк чорда куелганлыгына шикләнмичә, аны XVII гасырда бу якларга килеп утырып яшәгән татар халкы вәкилләренеке икәнлеге бәхәссез. Таш материалы итеп известьняк ташы алынган[2].

## № 21
## Тубыл музеенда саклanучы XVII гасыр ташбилгесе тексты

1. هوُ الحى الذى لا يموت كل حى سيموت
2. قال النبى عليه اللسلام الدنيا ساعة فجعلها طاعة

[1] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – С. 134–137.

[2] Текст һәм искәрмә материаллары Һарун Йосыпов архивы материаллары буенча алынды. Мирасханә: 72 ф. – 1 тасвир. – 30 саклау берәмлеге. – 33–34 б.

3. ایردی
4.
5. حیر دعالار
6.
7. تاریخ منکدا یوزدا اون یل ایردی محمد مرادا بن
8. عوض باقی دار الفنادین دار البقایه اینتیقال ایلادی

**Текстның татарча өлешенең хәзерге графикада укылышы**

7. Тарих миңдә йөз дә ун йыл ирди
Мөхәммәд Морад ибне
8. Гаваз Бакый дарелфанадин дарелбакайа
интикаль әйләде.

**Тубыл музеендагы кабер ташы**

Тубыл музеенда саклanучы XVII гасыр ахыры татар кабер ташы турындагы беренче хәбәр тарихчы Равил Фәхретдиновның инглиз телендә басылган «Татарлар тарихы» (Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2004) китабына иллюстрация рәвешендә бирелгән кабер ташы сурәтеннән мәгълүм булды.

Бу ташның кыйммәте татар мәдәнияте өчен кечкенә түгел. Ул таш XVII гасырда татар халкы арасында Касыйм шәһәреннән Тубылга хәтле – бердәм татар мәдәнияте яшәүнең билгесе булып тора.

Ташның текстын фото аша өлешчә генә өйрәнергә мөмкин булды, чөнки аның фоторәсемен эзләп, сорашып карасак та табып булмады. Шулай да аны өйрәнүдә кайбер казанышлар бар. Беренчедән, аның бөтен тышкы архитектура декоратив бизәлеш, ясаган материал, язу стильләре һәйкәлнед вертикаль хәлдә куелуы, аның үлчәмнәре Урал буйларында куелган татар эпитафик истәлекләре белән бердәм тәңгәл килә.

Таш текстының структурасына игътибар итсәң дә шул күренеш.

Текстның өске өлешендә шул ук орнамент, язулар – гарәп язуы. Язу юллары турыпочмаклы оялар эченә кабартып язылганнар. Календарь системасы һәм дә телләр дә шул. Текстлардагы

антропонимнар да гомуммилли байлыкка карый. Таштагы текст структурасы да бер тәртиптә бара.

Ташның 3–6 юлларын бөтенләй укып булырлык түгел. 7–8 юллар бераз танылдылар.

Татар тарихында Гаваз Бакый шәхесе бераз мәгълүм. Аның Гаваз Бакый Колмәмәтов исемле командир буларак Тубыл татарларыннан оешкан полк белән җитәкчелек итүе турында хәбәрләр бар[1].

Гаваз Бакый белән мәгълүм татар китап күчерүчесе, Казан арты Ташкичү авылыннан Мөхәммәдкәрим бине Рәфикъ та Тарада булу дәверендә таныш була.

Таш текстындагы һиҗри 1113 милади 1701–1702 елларга туры килә.

## № 22
## Курган өлкәсе, Сафакүл төбәге, Мансур авылы зираты ташбилгесе тексты

1. لا اله الا الله
2. محمد رسول الله
3. كل نفس ذائقة
4. الموت ١١٧٧ سنه
5. منصور بن
6. توقاى

**Искәрмәләр**

Ташбилге һиҗри 1177, милади 1763–1764 елларда вафат булган Мансур Тукай улына куелган. Таш үз вакытында 60х140 см. зурлыктагы гранит плитадан куелган. Соңыннан һәйкәл өстенә юан агач төшеп аны өч кисәккә ваткан. Ләкин язулы текст таштан калган бер кисәктә генә сакланган. Текстта татарча сүзләр юк. Ул гранит ташларны Верхнеуральск шәһәрендәге татар осталарыннан яздырып кайтарткannar. Мансур Тукай улының ташбилгесе XVIII гасырдагы мөселман татар эпиграфикасының иң көнчыштагы үрнәге булып санала. Язмалар уеп эшләнгән.

[1] Тычинская З.А. Потомки касимовских татар в Сибири // Сулеймановские чтения. – 2002. – С. 122–125.

# АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

## Оренбург төбәге һәм Каргалы (Сәгыйдь) бистәсе ташбилгеләре текстлары

### Кереш

Оренбург шәһәрен кору татар халкы тарихында зур әһәмияткә ия. Бу якларга милли колониаль изү үзәкләренә әйләнгән Касыйм, Казан, Нократ якларының иркенлеккә сусаган вәкилләре килеп утырып зур актив хуҗалык, сәүдә, һөнәрчелек эшләрен күтәрүгә тотыналар. Алар монда колонизаторлар тыеп торган таш, металл эшкәртү кебек һөнәрләргә дә керешәләр. XVIII гасыр башында Петр патша тарафыннан татар-мөселманнарга каршы тирән нәфрәт белән тулган чаралары уздырылу нәтиҗәсендә мөселман татарның ата-баба каберләре өстенә таштан истәлек кую йоласы тыелгач, алар монда каберлекләрендә бу йоланы тергезү эшен актив алып баралар. Оренбург, Каргалы, Үрге Чебенле, Балыклы, Стәрлебаш, Ибрай һ.б. татар авыллары зиратларында XVIII гасырның икенче яртысында ташбилгеләр барлыкка килә.

Ташбилгеләрнең ясалу һәм куелу төбәге буенча беренче урында Каргалы тора. Әлбәттә, Оренбургтагы бүгенге көндә шәһәр һәм өлкә җитәкчелеге эшчәнлеге белән җимерелгән **беренче татар зиратында** да борынгы дәвер, ягъни Оренбургны кору чорларыннан калган зират булып андагы бай эпитафик язмалар варварларча юкка чыгарылганнар. Хәзерге көндә шушы варварлыкны бүгенге Оренбург өлкә һәм шәһәр хакимнәре каланың икенче зур татар мөселман зиратын юкка чыгаруда күрсәтмәкче булалар. Оренбургны кору өчен хезмәт күрсәткән татарларга Россиянең бүгенге властьларының «рәхмәте» шулай белдерелә.

Каргалы (Сәгыйдь) бистәсенең бүгенге көндә бик зур өч зираты бар. Аларның иң борынгысы зур, биек, озын таш стеналар белән әйләндереп алынган. Анда нигездә XVIII гасыр һәм өзелмичә

XX гасыр дәвамында куелган ташбилгеләр һәм дөрбәләр дә бар әлегесен...

**Икенче зират** борынгысы белән янәшә, аларны бары тик Оренбург белән Каргалыны тоташтыручы зур трасса гына аерып тора.

Икенче зиратның ихаталары да бик сыек, аңа күрәсең таштан ихата корырга зобаниларның киртәләре комачаулагандыр. Анда да нигездә XIX йөзнең икенче яртысы һәм XX йөздә куелган ташлары патшалыгы – «шәһәре» корылган.

**Өченче зират** «Дүнә ягы зираты», Каргалыдагы татар казакларының 1878 елда Урыс-Төрек сугышыннан кайткач нигезләнә башланган каберлек. Анда да шул дәверләрдән күп ташлар калган. «Дүнә» дип аталуының сәбәбе Каргалыдан чыккан татар-казакларның Дунай елгасы буйларында булган сугышларда катнашу хатирәсе белән бәйле. Каргалының ул хәрби казак сословиесендә торган йорт-нигезләр корган ягын халык «Дүнә ягы» дигән исем биреп калдырган. Аларның зираты да шушы мөнәсәбәттә «Дүнә зираты» дип аталган.

Каргалы авылының данын, анда яшәгән атаклы таш кисеп, каберташлар ясаучы осталар да күтәргән.

Аларның иң беренчесе Ибраһим ахун бине Мөхәммәд Түләк Оренбурҗы (? –1761), ул Каргалы зиратындагы иң беренче ташны 1751/52 елда ясап куйган, бу дәвердән икенче атаклы эпитафик язулар остасы Исхак Габделкәрим улы (1731–1802). Исхак останың эшләре Каргалыда һәм аннан читтәге зиратларда да күп сакланган. Моннан тыш Каргалыда Гыймадулла, Хәйрулла Каргалый (XX гасыр башы) исемле таш кисеп язучы осталарның исемнәре мәгълүм.

Каргалыда XVIII–XIX йөзләрдә яңа тип татар эпитафик истәлекләренең стиле, эпиграфика формалаша, анда татар сәнгатенең таш кисеп язу осталыгы һәм аерым осталары да күтәрелә.

Каргалы зиратлары татар халкының тарихы белән бергә, таш кисеп эшләү сәнгатенең музейлары буларак та милләтебез өчен бәһа биреп бетермәслек урыннар.

Безнең тарафтан Оренбург регионына ике эпиграфик экспедиция оештырылды. Бу экспедицияләргә чыгу Каргалының җирле крайны өйрәнү энтузиастлары теләкләре белән туры килде. Алар – Рәшит һәм Әнвәр Искәндәров кебек үз якларының тарихлары белән тирән кызыксынучы затлар булдылар.

Әлбәттә, бу якларга килгәнче мин бу төбәкнең зиратлары белән Ризаэддин бине Фәхретдин, Миркасыйм Госманов, Мәдинә Рәхимкулова, Лерон Хәмидуллиннарның булып китүләрен белә идем.

Ләкин Каргалының зиратларына кергәч мин аларга бер галимнең дә системалы чыганаклар итеп карау билгеләрен күрмәдем. Күп кенә кызыклы ташлар, шул исәптән язучы Ишнияз бине Ширниязның да кабер ташы кызгылт мүк белән капланып укырлык хәлдә түгелләр иде. Миңа бик күп ташларны сак кына итеп мүкләрдән арындырып укырга туры килде. Соңыннан минем эздән йөреп исемемне дә әйтмичә ару ташларны укучылар хасыйл булды. Мин аларның яшерен теләкләрен яхшы аңлыйм, алар үзләрен беренче пионерлар итеп күрергә ашыгалар. Шунысы гаҗәп, нигә алар моңарчы ул зиратларны өйрәнергә теләк күрсәтмәгәннәрдер. Шунысы гаҗәп, минем арттан йөреп, мин укыган ташларны матбугатта чыккач та яңадан укыган булып кылану бер бозык фигыль дип уйлыйм.

Безнең экспедициябезнең беренчесе 2004 елның 22–29 июль көннәрендә булды. Ул вакытта мине этиле-уллы Рәшит һәм Әнвәр Искәндәровлар Каргалының Болгар дәүләте чорында ук кабер ташларындагы мәгълүматлар бармы-юкмы икәнен ачыкларга өндәгәннәр иде. Бу бурыч үтәлде, тотып күрсәтерлек бер ташъязма да табылмады. Беренче экспедиция барышында маршрутым түбәндәгечә булды. Безнең Оренбург төбәгенә экспедициябез фәнни максаттан чыгып оештырылды.

**22 июльдә (2004 ел)** – Оренбургтагы Степный зиратындагы Татар почмагын өйрәнеп чыктык. Андагы берничә йөз кабер ташлары арасыннан ун текст язып алдык һәм фотоларга төшердек.

**22 июльдә** Оренбургның Проспект Победы урамында XIX гасырның икенче яртысыннан калган зур, әйләнәсен калын һәм биек таш стена белән әйләндереп алынган зиратны өйрәнә башладык.

**23 июльдә** өйрәнүне дәвам иттек. Нәтиҗәдә Оренбург шәһәре Проспект Победы урамындагы татар зиратының алтыдан бер өлеш мәйданында утызлап ташларны укып һәм текстларын күчереп язып алдык. Дистәләгән ташларны укып кына китәргә туры килде.

**24 июль, 2004 ел.** Оренбургтан иртәнге якта Каргалыга килеп урнаштык. Безне Әнвәр Искәндәров бик зурлап каршы алып, бөтен эшебезгә киң мөмкинчелекләр бирде.

Килү белән Каргалының Больница кырыендагы кече капкасы янышнан өйрәнү процессын башладык. Бу зиратны, андагы сәнгатьле эшләнгән ташларны, аларда язылган тирән фикерле шигырьләрне укып тарихыбызда мәгълүм шәхесләребезнең исемнәрен очратып мин таң-гаҗәбләргә калдым, үз халкымның талантын күреп тагын да горурлыгым артты.

Мин бу килүемдә Каргалы зиратларында 120 ташны укып, текстларын язып алдым һәм тагын 300 ләп фоторәсем төшереп алдым.

Шул ук вакытта дөрбәләрен дә өйрәндем. Соңыннан ул дөрбәләр турында мәкаләләрем дә басылып чыкты[1].

Татар Каргалысы зиратларында 2004 ел, 30 июльгә хәтле көннәрдә эшләдем. Оренбург Каргалысына икенче мәртәбә фәнни экспедиция белән 2005 елның 14 июлендә килеп эшли башладым.

Каргалы зиратларында 48 ташны өйрәнеп язып алдым.

**8 июль, 2005 ел.** Оренбург шәһәре Проспект Победы урамындагы татар зиратын өйрәнүне дәвам итеп 15 ташны укып, күчереп алдым.

**19 июль, 2005 ел.** Сакмар районы Үрге Чебенле авылына киттем. Анда Рәшит Искәндәров белән йөреп таныштым. Бу зираттан 15 таш язып алдым.

**20 июль, 2005 ел.** Сакмар шәһәрендәге татар зиратын өйрәнүгә керештем. Анда мине транспорт белән Рәшит Искәндәров озатып йөрде. Сакмар зираты бик зур түгел. Анда 14 эпитафик язма күчереп алдым. Димәк, ике ел дәвамында уздырылган экспедицияләр барышында түбәндәге татар зиратлары эпиграфикасының бай хәзинәләре белән таныштык.

Без бу китабыбызда Оренбург төбәгендәге ташлардан бары XVIII йөзгә бәйле булганнарын гына сайлап алдык. Алар барсы 20 данә булды. Әлбәттә, Каргалыда тагын да 30–40 лап XVIII гасыр кабер ташларын табып булыр кебек. Ләкин аларның күбесенең тексты исем-фамилия һәм вафат вакытын күрсәтү белән чикләнә. Бу очракта текстлары ягыннан кыйммәтрәк язмалар сайланып алынды. Каргалы зиратлары система белән махсус өйрәнелергә тиеш.

---

[1] Әхмәтҗанов М. Татар Каргалысы дөрбәләре // Татар археологиясе ж. Казан. – 2006. – № 3–4. – 213–227 битләр.

## № 1
## Каргалы (Сәгыйдь бистәсе) Хәдиҗә Бикә ташбилгесе тексты

1. بسم اله الرحمن الرحيم
2. اشهد الله لا اله الا الله محمد رسول الله
3. و هو الحى الذى لا يموت البدة الحير و هو عزء كل سى ودى حمد
4. كل من عليها فان و يبقى وجا ربك ذو الجلال و الاكرام
5. قال النبى غليه السلام الدنيا ساغة فاجعلها طاغة
6. تاريح بنك يوز التمش بشنجى يلده جوزا بورج
7. رحمتدان واصل اولمش ايردى احرى انيڭ قل و بى
8. ملوك سولطاننك غمادى مكاديرقو
9. تلوع محمد مرزا توكلى زوجه سى ساخى
10. و حيرات فاتحه سى علا و سعادت ننك تحدى
11. حان حاجبى ابو صالحا عيده غشوره
12. مرحومه حه ديجه بيكه مرقدينده
13. بونى اوقعاندن رجا اولنور كى اكر
14. اولمش ايكى فاتحا و اوج اخلاصى باعشلاسا
15. كتبه ابراهيم احون الاورنبورجى

**Текстның татар телендәге өлешенең хәзерге графикада чагылышы**

6. Тарих бең йөз алтмыш бишенче йылда җәүзә борыҗи
7. рәхмәтдән васыйл улмыш ирди. Ахры аның кол вә би,
8. мөлек солтанның гомади мөкадир Ко-
9. тлуг Мөхәммәд мирза Тәүкили зәүҗәси сәхи
10. вә хәират фатихасы галя вә сәгадәтинең тәхеди
11. хан хаҗибе Әбү Салиха гаидә гашүрә
12. мәрхүмә Хәдиҗә бикә мәркадиндә
13. буны укыгандин риҗа улынур ки, әгәр
14. улмыш ики фатиха вә өч ихлас багышласа
15. Кәтәбәһү Ибраһим ахун әл-Орынбурҗый.

**Искәрмәләр**

Ташбилге Оренбург шәһәре янындагы Каргалы (Сәгыйдь) зиратындагы зур дөрбә эчендә егылып ята. Ул граниттан кисеп

ясалган. Язмалар туры сызыклар буенча уелып ясалганнар. Бу ядкярның тимпан урнында һәм бордюрларында вак кына хәрефләр белән тагын текстка кагылышлы язмалар бар. Текст беренче мәртәбә укылып, матбугатка тулысынча чыгарылды[1]. Ташның һиҗри тарихы 1165, миладе 1751/1752 елга туры килә.

Бу кабер ташы Оренбург шәһәрен нигезләүчеләрнең берсе булган Котлуг-Мөхәммәд Тәүкилинең хатыны кабере өстенә куелган булып, әлеге көндә җирдә егылып ята. Аны Урта Азиядә укып кайткан атаклы татар мирзалары нәселеннән булган Ибраһим ахун Түләков язып куйган. Ташбилгенең үлчәүләре – 37х68х146 см.

## Сүзлекчә

Һиҗри 1165 ел – милади 1752 ел
Җәүзә борыҗ – май/июнь ае
Гомади – таяныч
Мөкаддәр – кадерле
Зәүҗәсе – хатыны
Хәйрат – хәйерле
Галя – бөек
Сәгадәтнең – бәхетнең
Хан Хаҗибе – хан капкачысы
Әбү Салиха – пак
Мәркадиндә – каберендә
Риҗа – соралыр.

## № 2
## Каргалы татар зиратындагы Габделкәрим бине Балтай ташбилге тексты

1. بلطاى جولدش بلعارى و موضع وفات قارعالى
2. هَذه جَرتبِزَده عَدل تنكريمز بن
3. روزكارننك كر دله سه بوش كلسا جهان
4. ايل سروبن كوزيكا دوشسا بو ترباكاسان
5. سورهٔ رحمت الله دن عادل حان
6. بخس ايتب فرخنده قِل روح روايتى همان
7. اِسمدور عبد الكريم بالطاي اتاسى تعدازن

[1] Әхмәтҗанов М. Хәдиҗә бикә дөрбәсе // Татар археологиясе. – Казан. – 2006. – № 3–4. – Б. 214–216; Әхмәтҗанов М.И. Батырша хәрәкәте һәм Ибраһим ахун // Батырша җитәкчелегендә баш күтәрү һәм XVIII гасыр татар җәмгыятендә иҗтимагый-мәдәни тормыш. – Казан, 2007. – Б.109.

8. صاحب مِحراب امکنی هم دوعَا مال و طاعات
9. هَم حرمیدین بخاری مرشدلیك شیح الزمان
10. اسم ایشان محمد آستانی بداخشانی لا مَکَان
11. بنکده یوز یتمش برنچی یل اچنده ای فلان
12. التمش اوچ یاشیده نوباة شهادت ایتدی مردانك
13. عَالمنك حرامی بهاری آچولوب جنت نشان
14. بُلبُل اعازه کرلارْ ایدیوب زار و فعان
15. ایسمدی بارصْ یلنك ماه شِرلغی ز...عی میان
16. اعتکان اولتورمش الیدی مسجنك حمد بسم بنا قلعان
17. صبح صادِق ظاهر اولدوقچه قضایي آسمان
18. ایردن چون دردی ره ون ردی صلخ زقتسوه حان

Ташның арткы стенасындагы язманың укылышы тексты

1. کاتبی اسحاق ایرور بو مَیتننك فرذنده سی
2. قالبدن عمرنده بر کورکان جك دلبنداسی
3. والیده مرحومه سیید تربت جانب بشمال
4. بونلاری ایات اوقب شاد ایلاکل ای حوش حصمال

**Габделкәрим бине Балтай ташбилгесе тексты хәзерге графикада**

1. Балтай җулдаш Болгари вә мәүзыйг вафата Каргалый
2. Һәза җортыбызда гадел тәңримиз бән
3. Рузгярның керделәсә буш килсә җиһан
4. Ил сөрүбән күзигә дөшсә бу төрбәгә сан
5. Сурә-и Рәхман Аллаһдин гадел хан
6. Бәхәс итеп фәрхндә кыйл рух риваййәти һаман
7. Исмидүр Габделкәрим, Балтай атасы тәгъдәзан
8. Сахиби михраб имкяни һәм дога, мал вә тагать
9. Һәм хәрәмидин Бохари мөршидлик шәйхел-заман
10. Исеме ишан Мөхәммәд астани Бадахшани ля-мякан
11. Биңдә йөз йитмеш беренче йыл эчендә и фәлән
12. Алтмыш өч йәшидә нәүбәт шәһадәт итди мәрдәни
13. Галәмнең хәрами баһари ачулуб җәннәт нишани
14. Былбыл агаза гөрләр идийүб зар вә фиган

15. Исемди барыс йылыйның маһи ширлыгы з... мәййан

16. Игътикан ултырмыш илле йите мәсҗеднең хәмед бисем бина кыйлган.

17. Сабах садыйк заһир улдукча казаий асман

18. Ирдин чүн дәрби рәһван вакты сәваһхан.

**Ташбилгенең арткы стенасындагы шигырь**

1. Кятибе Исхак ирүр бу мәйетнең фәрзәндәси
2. Калебдән гомерендә бер күргәнҗек делбәндәси
3. Вәлидә мәрхүмә сәйид төрбәт җаныб бишмаль
4. Бунлари аять укыб әйләгел и хуш хисмаль.

**Искәрмәләр**

Бирелгән эпитафик язма XVIII йөзнең беренче яртысында яшәгән күренекле дин эшлеклесе Габделкәрим бине Балтай кабер ташына язылган. Бу шәхес үзе хәзерге Татарстан Республикасының Кукмара төбәге Адай авылыннан чыккан (1695–1758). Аның бабасы Ишмөхәммәд бине Тукмөхәммәд Хафиз атаклы изге булып танылган. Аның каберенә узган гасырларда күп халык адарынып йөргән. Габделкәрим Адайдан китеп Бохарага барып укыган, анда суфыйлар тәрикатенә кергән. Кабер ташында аның Бохарадагы остазы Мөхәммәд Бадахшани искә алына. Габделкәрим-Нократ бәкләреннән Кара бәк тармагыннан чыккан нәсел. Оренбургны төзегәндә Казан өязеннән күп кенә аның сәүдәгәр туганнары (мәсәлән, Аетовлар) шунда күчеп утыргач, Бохарадан Габделкәримне дә чакырып кайтарып, аны имам итеп беренче мәчеткә урнаштыралар. Кабер ташын аның улы Исхак (1730–1802) ясап, яза. Исхак атаклы таш кисеп язучы каллиграф һәм оста ювелир да була.

Ташның үлчәмнәре 27х42х138 см. зурлыкта. Ул ак известь таштан кисеп язылган. Язмалары күпертеп эшләнгән. Ташның арткы стенасына Габделкәримнең улы үзенең бер шигырен дә язып куйган.

Ташның арка түбәсендә диаметры 15 см, тирәнлеге 6–7 см. булган түгәрәк ритуаль уенты ясалган. Татар халкының борынгы ышанулары буенча кешенең җаны кош булып очып, үзенең гәүдәсе күмелгән урынга килеп куна икән. Шунлыктан андый җан кошларына кабер ташында су җыелып тору тиеш булган.

Ташбилгенең икенче ягындагы шигырь Исхак бине Габделкәримнең әнкәсенә дә багышланганга охшый. Ләкин аның кабер ташы булмаган яки сакланмаган булса кирәк.

Ташбилгенең куелу вакыты һиҗри 1171 ел, милади 1768 елга туры килә.

## Сүзлекчә

Мәүзыйг – урын-җир
Мәрданә – ирләрчә
Рузгяр – вакыт
Мөхи – терелтүче
Җиһан – дөнья
Баһары – язы
Сахибенә – түр
Нишан – билгесе
Имкяни – мөмкинлек
Фиган – үзәкне өзүб
Тәгать – буйсыну
Хәмед бисем – Аллаһ исменә
Хәрәмидән – изгедән мактану
Мөршидлек – туры юк күрсәтүче
Заһир улды – күренде
Шәйехел-заман – замана шәйехе, остазы
Каза-и – соңга калган
Әсна – вакты
Асман – күк йөзе
Ля Мәкян – урыны мәгълүм түгел
Ирдин – кешедән
Нәүбәт шәһадәт итди – үлде, җанын тапшырды
Дидар ордый – йөзен чөерде.

## Ташбилгенең икенче ягындагы текстка сүзлекчә

Кятибе – язучысы
Фәрзәндәсе – баласы
Калебдин – йөрәктән
Хисмаль – хисләнүче
Вәлидә – тудыручы
Сәийед – изге
Төрбәти – кабер

## № 3
## Эстәрлебаш төбәге Ибрай авылы зираты, Рәхмәтулла Мөхәммәдрәхим углы ташбилгесе (1770 ел)[1]

1. تاريح ١٧٧٠
2. رَمضان شريفننك
3. ٢٥ كون جمعه كجده

[1] Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр. Икенче китап. – Эстәрлетамак, 2005. – 218 б.

4. دلو برجی ننك ٢٨ كون ره
5. حمة الله محمد رحيم او
6. علیننك وفاتی اولدی
7. بیت
8. التماس اجلدان قلاسز دعا
9. جَنت ارزن ایلاسون حالق نكا

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих 1770
2. рамазан шәрифнең
3. 25 көн җомга кичә
4. дәлү борыҗының 28 көн Рә-
5. хмәтулла Мөхәммәдрәхим у-
6. глыныйң вафаты улды
7. Бәйет
8. Илтимас әҗәлдин кыласыз дога,
9. Җәннәт арзын әйләсүнә халикыңа.

**Искәрмәләр**

Бу ташбилгенең үлчәмнәре: 12х35х55 см. В.Усманов текстның 8–9 юлларын укымыйча калдырган. Ташбилгенең авторын фараз белән Ибраһим ахун Орынбурҗы диеп саный, ләкин ул бу вакытта инде 1770 елдан берничә ел элек үлгән һәм ташка язарлык хәлдә булмый.

Бу текстны В.Усманов китабыннан татар эпиграфикасы ареалының киңлеген күрсәтү өчен бу китапка керттек.

Ташның фотокүчермәсе булмаганлыктан, укылыш В.Усманов ясаган рәсем буенча гына кабул ителде.

**Сүзлекчә**

Рамазан шәриф – Мөселман ай календаренда тугызынчы айына февральнең 11-нә туры килә.

Дәлү борыҗы – мөселман кояш елы календарының беренче ае 11 февральгә туры килә.

Илтимас – инәлеп

Әйләсүнә Халикыңа – бирсенгә (Аллаңа)

Әҗәлдән – үлемнән

Җәннәт арзын – җәннәт теләген

## № 4
## Каргалы (Сәгыйдь) бистәсенең беренче зиратындагы Искәндәр һәм Әбүбүкер ташбилгесе тексты

1. ١١٨٧
2. حمل برجنده بکچنتای محمدقل
3. اوعلی کند فرزندلاری
4. اسکندر و ابو بکر بر کون
5. و بر سَاعة اچنده فنادن
6. بقایه رحلت قلدیلار
7. امید اولدر دوعانکی دمیع بوُیله

**Текстның хәзерге татар графикасында чагылышы**

1. 1187
2. Хәмәл борҗында (хәмәл йолдызында – *М.Ә.*) Бикчәнтәй Мөхәммәдкол
3. углы фәрзәндләри
4. Искәндәр вә Әбүбүкер бер көн
5. вә бер сәгать эчендә фанадин
6. бакайа рихләт кыйлдыйлар
7. өмид улдыр догаңый дәмигъ буйлә.

**Искәрмәләр**

Бу эпитафик язмада Каргалы бистәсендә Пугачев баш күтәрүе вакытында, аның гаскәре Каргалыга кергәч, һиҗри 1187, милади 1774 елның (март–апрель) айларына туры килгән бер фаҗига турында языла.

Тарихчылар язуына караганда, 1774 елның 26 мартында баш күтәрүчеләр Каргалыга килеп керәләр. Алар баш күтәрүчеләрне җәзага тарткан сәүдәгәр Мөхәммәдкол Бикчәнтәев һәм аның ике улын – Искәндәр белән Әбүбәкерне тотып алып бик тиз асып үтерәләр[1].

Шушы эпитафик язма, пугачевчылар асып үтергән Каргалы сәүдәгәре һәм аның ике улы кабере өстенә куелган булган. Ташның үлчәмнәре: 18x44x136 см. Һәйкәлнең түбәсендә кечкенә генә

[1] Искандаров Р., Искандаров А. Сеитов посад. – Казань: Татар. книж. изд-во, 2005. – С.86.

чокырланып торган урын ясалган. Борынгы татар ышанулары буенча мәетнең җаны кабер ташына кош булып килеп кунганда, таш чокырында ул эчәрлек су булырга тиеш дип каралган.

Кабер ташы ак известь таштан кисеп, шомартып ясалган. Хәрефләр күпертеп язылган. Бу ташларны кисеп ясаучы оста Исхак бине Габделкәрим исемле кеше була (1731–1802). Аның имзалары ул эшләгән ташларда күренгәли. Исхак ташлар кисеп ясауда Каргалыда Ибраһим Түләки тарафыннан 1752 нче елда башлаган эшне үзе яшәгән гасыр ахырына кадәр дәвам иткән. Каргалы, Оренбург, Чишмә, Троицк зиратларындагы кабер ташларын минем эздән яңадан тикшереп йөргән эпиграфика белгече В.Усманов Каргалы һәм Эстәрлебашлардагы Исхак Габделкәрим улы эшләрен ялгыш Ибраһим ахуннныкына саный[1].

**Сүзлекчә**

Хәмәл борҗында – 22 марттан 22 апрельгә кадәр тәгаенләнгән ай.
Кән фәрзәндләре – үз балалары.
Фанадин – бу фани дөньдан
Бакайа – мәңгелеккә
Рихләт – кыйлдылар – күчтеләр, үлделәр
Дәмигъ – күз яше.

## № 5
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Габдеррәфигъ бине мулла Габдулла әл-Каргалы ташбилгесе (1776 ел)

1. عهدا مرقد الشيخ ملا عبدل الرافع بن
2. ملا عبد الله القرعالى نور الله تعالى
3. مصبدحه عفر ... و ... ده يوم القيمة
4. تاريخ منك يوزده سكسان طوقزنچى يلده
5. شوال آيننك ٥ نچى كونندا دار فنه دين
6. دالر بقايه نقل ايتدى ايللى يتنچى ياشنده
7. رحمت الله عليه رحمت واسعة

[1] Усманов В.М. Тарихый ядкәрләр. 3-нче китап. – Бакча авылы, 2007. – Б. 18–19.

**Текстның татарча өлешенең хәзерге татар графикасында чагылышы**

1–2. Шәйех мулла Габдеррәфыйг бине мулла Габдулла әл-Каргалый

5. шәүвәл айының 5 нче көнендә дар-фанадин

6. дар-бакайә нәкыль итди илли йитинчи йәшендә

**Искәрмәләр**

Ташбилге известь таштан кисеп ясалган. Үлчәмнәре 17,5х52х140 см. Язмалар күпертеп гарәп язуының сөлес стилендә эшләнгәннәр. Ташның очында түбәсенә «җан кошы» өчен ясалган уенты чокыр бар. Һәйкәлнең куелу датасы 1189 нчы һиҗри, миладибелән 1776 елның 30 ноябренә туры килә. Эпитафия безнең тарафтан 2004 елның 28 июлендә беренче мәртәбә табылып, мүкләреннән чистартып укылды.

**Сүзлекчә**

Һазә – бу
Мәркад – кабер
Мәсабихга – яктылык чыганагы
Фанадин – бу дөньядин
Дар бакайа – мәңгелеккә
Нәкыль итди – күчте, үлде.

**№ 6**
**Оренбург Каргалысы борынгы зираты,**
**Гыйлемша Мирсәгыйди ташбилгесе (1779 ел)**

1. هو الخلاق البقى
2. علمشه مرسعيدى
3. وفات اولدى
4. ١١٩٣

**Текстның хәзерге графикада укылышы**

1. Һу әл-Халлякъ әл-бакый
2. Гыйлемша Мирсәгыйди
3. вафат улдый
4. 1193

**Искәрмәләр**

Текст ак известь плитәгә күпертеп язылган. Плитаның үлчәмнәре 14х30х90 см. Мәрхүмнең үлгән елы һиҗри 1193 милади 1779 елга туры килә.

Таш 2004 елда табылып, 26 июльдә укылды.

## № 7
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Габидулла бине Габдерәхим ташбилгесе (1781–1782 ел)

1. المرحوم المعفور
2. عبيد الله بن عبد الرحيم
3. ١١٩٦ سنه

**Текстның хәзерге графикада укылышы**

1. Әл-мәрхүм әл-мәгъфүр
2. Габидулла бине Габдерәхим
3. 1196 сәнә

**Искәрмәләр**

Текст известь плитага кабартылып язылган. Плитәнең үлчәүләре 17х32х100 см. Тексттагы һиҗри 1196 ел, милади 1781–1782 елга туры килә. Таш 2004 елның 26 июнь көнендә өйрәнелде һәм сурәткә төшереп алынды.

## № 8
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Миңлемөхәммәд Бикинҗә углы ташбилгесе (1784–1785 ел)

1. ١١٩٩
2. جمادىَ الوّل آيننك
3. ١١ كننده منكلى محمّد
4. بكنج اوعلى وفات اولدى

**Текстның хәзерге графикада укылышы**

1. 1199
2. җөмадийәл-әүвәл айының
3. 11 нчедә Миңлемөхәммәд
4. Бикинҗә углы вафат улды.

**Искәрмәләр**

Текст эшкәртелгән ак известь таштан ясалган плитәдә күпертмә гарәп язуы белән язылган. Ташбилгенең үлчәүләре – 16х37х60 см. Мәрхүмнең үлү вакыты һиҗри 1199, милади 1784 елның мартына туры килә. Плитә тексты 2004 елның 26 июлендә табылып беренче мәртәбә укылды һәм күчереп алынды.

## № 9
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Мөхәммәдшәриф Нәзир углы ташбилгесе (1784–1785)

1. تاريخ ١١٩٩
2. محمد شريف نظر
3. اوعلى

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Тарих 1199
2. Мөхәммәдшәриф Нәзир
3. углы

**Искәрмәләр**

Таш 2004 елның 26 июлендә өйрәнелде. Ул ак известь таштан кисеп ясалган плитәгә язылган. Аның үлчәүләре: 13х45х50 см. Язулары күпертеп язылган. Ташның куелу датасы һиҗри 1199, милади 1784\85 елга туры килә. Ташның баш өстендә «җан кошы» килеп эчәргә су җыелып торсын өчен чокыр ясалган. Текст беренче мәртәбә мүкләре чистартылып 2004 елда, 26 июльдә укылды.

## № 10
## Федоровка районы, Балыклы авылы зираты, Булатай Мансур углы ташбилгесе (1785 ел)

1. المرحوم المغفور
2. ١٧٨٥ سنه ثورننك
3. ٢٧ كونى بولاطاى منصور
4. اوعلى ٧٩ ياشنده

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Әл-мәрхүм, әл-мәгъфүр
2. 1785 сәнә сәвернең
3. 7 көнни Булатай Мансур
4. углы 79 йәшендә

**Искәрмәләр**

Бу текст Венер Усманов китабыннан алынды[1]. Алуның сәбәбе татар эпиграфика сәнгатенең таралу регионы киңрәк күрсәтү максатыннан иде. Ләкин текстта бер җитешсезлек күренә. Аңа искәрмә бирелмәү бу очракта килешмәстер. Ул түбәндәге фактка терәлә. Китап авторы ташның сурәтен кәгазьгә төшергәндә текстстагы дүртенче юлны өченче итеп билгеләп язып ялгышлык җибәргәнме, әллә югыйсә ташны язучы оста шулай ялгышканмы? – бу урында бер аңлашылмаучылык кала. Ник дигәндә текстның укылышын логик эзлеклелек белән үз язмасында биргәндә бер искәрмә бирү соралып тора. Әлбәттә, монда фотосурәт булса, мондый аңлашылмаучанлыкка урын калмас иде. В.Усманов бу очракта фото урынына күчереп ясалган сурәт белән канәгатьләнгән.

Икенче искәрмә: автор күп очракларда Оренбург ягы зиратларындагы ташларны Каргалы осталары эше дип тәгаенли. Ләкин XVIII гасырда кабер ташы кисеп эшләүчеләрнең исемнәр саны бик кыска. Монда конкрет останы да күрсәтергә мөмкинлек бар кебек.

Мәрхүмнең вафат көнен дә бу очракта төгәл күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, Булатай 1785 елның 19 маенда вафат була. Балыклы авылы – Төмән (Темников) ягы татарлары авылы. Сурәткә карагында текст күпертеп язылган. Вафат елы милади кояш елы белән күрсәтелә. Ташның үлчәмнәре 14х30х105 см. Бу ташның әһәмияте – татар халкында таш кую традициясенең Оренбург якларында XVIII йөзнең икенче яртысыннан ук киң таралуы күрсәткече.

**Сүзлекчә**

Әл-мәгъфүр – кичерелгән

Сәвер, гарәпләрнең кояш календаренда апрель-май ае, төгәлрәк әйткәндә 22 апрель – 21 май вакыты аралыгындагы көннәрне күрсәтә.

---

[1] Усманов В.М. Тарихи ядкәрләр. Икенче китап. – Эстәрлетамак, 2005. – Б.149.

## № 11
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Ишнийаз бине Ширнийаз ташбилгесе (1790–91 ел)

1. اشنياز افندي
2. ابن شيرنياز
حوارزمي
3. ١٢٠٥

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Ишнийаз әфәнде
2. ибн Ширнийаз
Хавәрезми
3. 1205

**Искәрмәләр**

Бу таш гомеренең соңгы елларын Каргалы (Сәгыйдь) бистәсендә укыту белән уздырган Харезмнан килеп татар язучысы булып киткән кешегә куелган. Ишнийаз әфәнде Хавәрезми башта Казан артында Кышкар, Шашы кебек авылларда укытып йөри дә Каргалыга килеп төпләнә.

Татар кулъязмалары битләрендә авторлыгы аңа нисбәт ителгән гыйбрәтле хикәяләр бар. Аларның бергә тупланып «Ләтаифе Ишнийаз бине Ширнийаз» исемле бер китап хәлендә булганнарына да танык булырга туры килде. Моннан тыш аның дини проблемаларны чишүгә багышланган «Гакаи де Болгария» исемле китабын да күргәнлегемә таныклык бирәм.

Язучының моннан тыш шигырьләр язуы да мәгълүм һәм аларның кайберләре кулъязма битләрендә дә сакланган. Ишнийаз әфәнде хиҗри 1205, милади 1790–1791 елда үлгән. Аның кабер ташының үлчәүләре 20х40х65 см. зурлыктагы известь плита, язу тексты уеп язылган.

## № 12
## Оренбург өлкәсе, Сакмар районы Үрге Чебенле авылы, Бөхәббәт бинте Биктимер ташбилгесе (1791–1792 ел)

1. المرحومة المغفورة
2. بُحبة بنت بكتمر النقراتى
3. وَفات دها تاريخ ١٢٠٦ سنه

**Оренбург регионы, Сакмар төбәге, Үрге Чебенле авылы зиратыннан текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Әл-мәрхүмә. әл-мәгъфүрә-и
2. [Бөхиббәт?] бинте Биктимер ән-Нократи
3. вафат фи дәһа[1] тарих 1206 сәнә.

**Искәрмәләр**

Ташбилге ак известь таштан кисеп ясалган. Язулары күпертеп язылган. Биктимер ән Нократи, Нократ (Вятка) елгасы буеннан килгәнлеген белдергән тәхәллүсе алган. Һиҗри 1206 ел, милади 1791–1792нче елларга туры килә. Ташбилгенең үлчәмнәре: 15х29х100 см. Ташның югары түбәсендә «җан кошы» өчен эчәргә су җыела торган чокыр ясалган.

Бу ташны Венер Усманов бер аерма белән укый. Ул анда Бөхиббәт исемен Мөҗәббәрә дип тәкъдим итә. Ләкин анда җим хәрефе астына читкәрәк куелган бер нокта исемне башкача укырга урын калдыра (Бөхиббәт?).

## № 13
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Хөсәенҗан бине Габделхәлим ташбилгесе (1794–1795 ел)

1. المرحومة المغفورة
2. حسينجان بن
3. عبد الحليم ١٢٠٩

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Әл-мәрхүм әл-мәгъфүр
2. Хөсәйенҗан бине
3. Габделхәлим, 1209

**Искәрмәләр**

Эпитафиянең үлчәмнәре: 19х32,5х55 см. Язмалар күпертеп язылган, материалы ак известьтән ясалган плитә. Ташның югары

[1] Дәһа (фарсы) – төгәл

очында «җан кошы»на су җыелып торсын өчен ясалган кечкенә уенты чокыр бар. Һиҗри 1209 ел, милади 1794–1795 елга туры килә.

## № 14
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Бикчәнтәй бине Габделгазиз ташбилгесе (1795 ел)

1. مرحوم
2. بيك چنتاى بن عبد
3. الغزيز ١٧٩٩
4. مرقده
5. ذولحجه بنت [ب]يك حسن
6. بن عبد العزيز ...
7. حاتونى مرحوم اولدى
8. تاريح ١٢٠٩ سنه ده ماهى ذولحجه ٢٣ يومنده

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Мәрхүм
2. Бикчәнтәй бине Габде-
3. лгазиз 1799 сәнә
4. Мәркадә
5. Зөлхиҗҗә бинте (Б)икхәсән
6. бине Габделгазиз...
7. хатыны мәрхүмә улды
8. тарих 1209 сәнәдә маһи зөлхиҗҗә
23 йәүмендә

**Искәрмәләр**

Эпитафик язма ак известь ташка уеп язылган. Плитәнең үлчәме 13x30x65 см. Таш түбәсендә «җан кошы» килеп ташка кунганда, аңа эчәр өчен су җыелып торырга түгәрәк сай гына чокыр ясалган. Һиҗри 1209, милади 1795 елның 1 июленә туры килә. Таш беренче мәртәбә 2004 елның 28 июлендә табылып, тикшерелде.

## № 15
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Габделмөлек бине Исмәгыйль ташбилгесе (1795–1796 ел)

1. هو الخلاّق البقى
2. المرحوم المعفور
3. عبد الملك بن اسماعيل
4. ١٢١٠ سنه

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Һу әл-хәллак әл-бакый
2. Әл-мәрхүм, әл-мәгъфүр
3. Габделмөлек бине Исмәгыйль
4. сәнә 1210

**Искәрмәләр**

Ташбилге известь таштан кисеп язылган плитә. Аның үлчәмнәре: 17х30х90 см., очында чокыр юк. Язмалар күпертеп язылган. Һижри 1210, милади 1795–1796 елларга туры килә. Ташбилге 2004 елның 28 июлендә табылып, тикшерелде, укылды.

## № 16
## Оренбург Карагалысы борынгы зираты, Сәйфула бине Хөснулла ташбилгесе (1797–1798 ел)

1. المرحوم المعفور
2. سَيْف الله بن حسن الله
3. ١٢١٢ سنه

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Әл-мәрхүм, әл-мәгъфүр.
2. Сәйфулла бине Хөснулла.
3. 1212 сәнә

**Искәрмәләр**

Ташбилге ак известь таштан кисеп ясалган. Үлчәмнәре: 14,5х29х40 см. Язмалар күпертеп язылган. Ташның югары ба-

шында, түбәсендә «җан кошы» очып килгәч, аның өчен эчәргә су җыела торган чокыр уеп ясалган. Ташны беренче булып 2004 нче елның 28 июлендә табып укыдык.

Һиҗри 1212 нче, милади 1797–1798 елда куелган.

**№ 17**
**Оренбург Каргалысы борынгы зираты,**
**Габдулла бине Мөхәммәдшәриф ташбилгесе (1798 ел)**

1. ا عبد الله بن
2. محمّد سريف
3. ١٧٩٨

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Габдулла бине
2. Мөхәммәдшәриф
3. 1798
4. сәнә 1210

**Искәрмәләр**

Эпитафик текст бик кыска эчтәлекле. Ул 1798 елда үлгән Габдулла бине Мөхәммәдзариф истәлегенә куелган. Аның үлчәмнәре: 13х30, 5х70 см. Язулар уеп язылган. Ташның түбәсендә «җан кошы» өчен су җыелырга түгәрәк уем ясалган. Ул 2004 елның 28 июлендә табылып укылды.

**№ 18**
**Оренбург Каргалысы борынгы зираты,**
**Мөхәммәдсадыйк бине Мөхәммәдшәриф ташбилгесе (1798 ел)**

1. محمّد صَاديق بن
2. محمد شريف
3. ١٧٩٨

**Текстның хәзерге графикада укылышы**

1. Мөхәммәдсадыйк бине

2. Мөхәммәдшәриф
3. 1798

**Искәрмәләр**

Ташның үлчәмнәре 14x29x85 см. зурлыкта. Текст уеп гарәп язуының сөлес стилендә язылган. Плитәнең очында «җан кошы» эчәр өчен су җыелырга түгәрәк чокыр ясалган. Таш 2004 елның 28 июлендә табылып укылды.

## № 19
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Муса углы Бәдри ташбилгесе (1799 ел)

1. المرحوم المغفور
2. موسى اوعلى بدرى قرق توقز
3. ياشده
4. وفات ايتدى ١٧٩٩ سنه

**Текстның хәзерге графикада укылышы**

1. Әл-мәрхүм, әл-мәгъфүр
2. Муса углы Бәдри кырык тукыз
3. йәшдә
4. вафат итди 1799 сәнә

**Искәрмәләр**

Ташбилге ак известьтән кисеп эшләнгән плитәдер. Аның үлчәмнәре 14x33,5x70 см. Язмалар күпертеп эшләнгән.

Истәлек 2004 елда 28 июльдә табылып, беренче мәртәбә укылды.

## № 20
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Мулла Әлмөхәммәд әл-Кирмани ташбилгесе (1800 ел)

1. ملا المحمّد بن
2. عبد الله الكرمانى
3. ١٨٠٠ سنه
4. دلوننك ٩

**Текстның хәзерге графикада укылышы**

1. Мулла Әлмөхәммәд бине
2. Габдулла әл-Кирмани
3. 1800 сәнә
4. дәлүнең 9.

**Искәрмәләр**

Ташбилге тексты известьтән ясалган плитага уеп язылган. Әл-Кирмани тәхәллүсе мәрхүмнең чыгышы Касыйм шәһәреннән килгән зат булуын белдерә. Дәлү гарәби кояш календареның беренче ае. Үлчәмнәре 16х33,5х100 см.

Текст 2004 елда табылып, 26 июльдә укылды.

**Сүзлекчә**

Дәлү – хәзерге январь аеның урталарыннан башлана.

## № 21
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Мөхәммәдсиддыйк бине Мөхәммәдшәриф ташбилгесе (1800 ел)

1. محمّد صدّيق بن
2. محمّد شَريفْ
3. ١٨٠٠

**Текстның хәзерге графикада укылышы**

1. Мөхәммәдсиддыйк бине
2. Мөхәммәдшәриф
3. 1800

**Искәрмәләр**

Эпитафик истәлек ак известь таштан кисеп ясалган плитәне тәшкил итә, аның үлчәмнәре 14,5х29,5х80 см. Язмалар уеп гарәп язуының сөлес стилендә язылган. Плитәнең өске, башы өстендә «җан кошы» килеп эчәр өчен су җыелып торырлык сай гына түгәрәк чокыр уелган. Истәлек 2004 ел 28 июльдә табылып беренче мәртәбә укылды.

## № 22
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Зәйнелгабидин бине Мулла Әлмөхәммәд ташбилгесе (1801 ел)

1. زين العبدين
2. بن ملا المحمّد
3. الكرمانى ١٨٠١ سنه
4. قوس برجنده

**Текстның хәзерге графикада чагылышы**

1. Зәйнелгабидин
2. бине мулла Әлмөхәммәд
3. әл-Кирмани сәнә 1801
4. кавәс борҗында

**Искәрмәләр**

Эпитафик текст 1801 елның кавәс, – ягъни ноябрь аен билгеләрә. Ташның үлчәмнәре 15x31x75 см. Текст известь плитәгә күпертеп язылган. Таш плитәнең түбәсендә «җан кошы» эчәр өчен су җыелырлык чокыр да ясалган. Бу чокыр татарның борынгы ышанулары буенча мәрхүмнең җаны кош булып очып гәүдәсе күмелгән җиргә килгәч, су эчсен өчен ясалган («Җан кошы»на ышану). 2004 ел, 26 июльдә табылып, өйрәнелде.

## № 23
## Оренбург Каргалысы борынгы зираты, Исхак бине Габдлекәрим ташбилгесе (1802 ел)

1. المرحوم المعفور
2. ملا اسحاق بن
3. ملا عبد الكريم روحنه فاتحه
4. ١٨٠٢ سنه حمل
5. ١٨ ياشى ٧٠

**Текстның хәзерге графикада укылышы**

1. Әл-мәрхүм, әл-мәгъфүр
2. мулла Исхак бине
3. мулла Габделкәрим рухына фатиха
4. 1802 сәнә, хәмәл
5. 18, йәше 70

**Искәрмәләр**

Атаклы татар таш кисеп ясау остасы Исхак Габделкәрим улының ташы (1732–1802). Ул XVIII гасыр ахырына кадәр Каргалыда мулла булып, дәрес әйтеп, кабер ташлары кисеп язып, ювелирлык эшләре башкарып яшәгән. Аның эшләгән ташлары Татарстан авылларында да табылды (Түбән Бәрәскә, Өлә Казаклар). Каргалы зиратында аның сәнгатьле эшләнеп, язылып куелган дистәләрчә ташлары безнең тарафтан табылып укылдылар. Татар энциклопедиясендә аның турында мәгълүмат игълан ителде[1]. Текст 2004 ел, 26 июльдә табылып, укылды.

Исхак бине Габделкәримнең ташы ак известь таштан эшләнгән, тексттагы язмалар күпертеп язылган. Ташның үлчәмнәре: 17x34,5x156 см. Ташның башы өстендә «җан кошы»на очып килгәч эчәргә су җыела торган түгәрәк чокыры да бар.

Исхак бине Габделкәрим 1802 елның 8 апрелендә үлгән.

**№ 24**

**Каргалы бистәсе, иске зираты ташбилгесе тексты**

1. المرحوم المغفور
2. عبيد الله بن عبد الرحيم
3. سنه 1196

**Укылыш**

1. Әл-мәрхүм әл-мәгъфүр
2. Гобәйдулла бине Габдерәхим
3. сәнә 1196

[1] Исхак ибн Габдулькарим // Татарская энциклопедия. Т.2. – Казань: Институт татарской энциклопедии. 2005. – С. 627–628.

**Искәрмәләр**

Ташбилге язмалары күпертеп язылган. Аның язу стиле атаклы таш кисеп язучы хаттат Исхак бине Габделкәрим эшенә ошый. Һиҗри 1196 ел, милади 1781/82 елга туры килә.

### № 25
### Оренбург губернасы,
### Гаянәямак авылы кырындагы ташбилге

1. بسم الله الرحمن الرحيم
2. لا الله الله محمد
3. رسول آلله فاتج ...
4. ... دار الفنادين
5. دار البقاعى انتقال ادتي
6. تاريج منك دا يوزدا قيرق
7. توقوزده توشقان
8. يلى حمل آحر آيننك 11

**Ташның текстының татарча өлешенең укылышы**

4. ... дар әл-фанадин
5. дар әл-бакага интикаль идти
6. Тарих миң дә йөз дә кырык
7. тукузда, тушкан
8. йылы хәмәл ахыр айының 11нче...

Текст язылган урын шул урында ватылган.

**Искәрмәләр**

Ташбилге Оренбург ягындагы иң иске истәлек санала. Аның рәсемен 2008 елда безгә В.Усманов җибәргән иде. Текст уеп язылган. Аның язулардан астарак өлешендә ая рәвеше бизәкле орнамент төшерелгән. Мондый бизәкләр Чуаш Республикасы җирлегендә сакланган татар ташбилгеләрендә һәм Татарстанның Азнакай төбәгендә берничә таш йөзлегендә сакланган. Һиҗри 1149 ел, милади 1736 елга туры килә.

# ЙОМГАК

Бу хезмәттә 150 берәмлек борынгы ташбилге язмалары өйрәнелде. Алар нигездә 1600–1802 елларда куелганнар. Әлеге ташъязмалар мәдәниятебез һәм халкыбыз тарихы, сәнгатебез, әдәбиятыбыз өчен күпкырлы тарихи мәгълүматларны тәшкил итәләр.

Тарихтан мәгълүм булуынча, Казан ханлыгында һәм Касыйм җирендә XVI гасырның беренче яртысында татар халкы эпитафик һәйкәленең классик бер формасы барлыкка килә. Ул архитектура, декоратив бизәлеш һәм эпитафик текст ягыннан камилеккә ирешеп, бердәм милли стандарт ташбилге тибы рәвешен ала.

Ләкин XVI гасырның икенче яртысында Казан ханлыгы тәре йөртүчеләр тарафыннан дөньяда тиңе булмаган вәхшилек белән тар-мар ителә. Бу һәлакәттән соң татар мәдәнияте зур югалтулар кичерә. Ничә буыннар дәвамында иҗади үстерелеп киленгән рухи кыйммәтләр талана, җимерелә, яндырыла. Шул исәптән 270 ел буена камилләштерелеп киленгән ташбилгеләр эшләү сәнгате дә туктап калу, гамәлдән чыгу дәрәҗәсенә җитә. Казан җимерелгәннән соң илдә 1670 нче елларга кадәр классик матурлыкка ирешкән 5–6 гына шундый ташбилге эшләнеп куела. Традиция өзелү дәрәҗәсенә җитә.

Инде Казан һәм Касыйм кебек татар мәдәни үзәкләре дә җимерелгәч, хәзерге Минзәлә төбәгендә булган Калморза дигән авылда Дәвеш хафиз, Остаз углы Аккуҗад һәм Салагыш авылында Тиләш углы Дусмәт хафиз исемле яңа буын эпиграфика сәнгатен яңартучылар тарихка килеп керәләр. Бераз соңырак XVII гасырның соңгы чирегендә классик татар эпитафик истәлекләре стилендә таш кисеп язу остасы Килмөхәммәд бине Ишман исеме күренә башлый. Килмөхәммәднең эшләгән ташбилгеләре XVII гасырның соңгы чирегендә Кама елгасының уңъяк ярындагы дистәләгән татар авылларында сакланып калалар. Соңыннан Килмөхәммәд останың исемнәре билгесез калган шәкертләре, XVII гасыр ахырында аның традициясе географиясен тагын да киңәйтәләр.

XVII гасырның икенче яртысында ике төрле ташбилгеләр стиле барлыкка килә.

Аларның беренчесе Казан һәм Касыйм ханлыкларында булган декоратив чәчәкләр уеп ясалган (тимпанда), икенчесе оваль түгәрәк юкарак көзге рәвешендә була. Болардан беренчесе XVIII гасырның беренче яртыларына хәтле яшәп килеп, 1740 елларда тәмам юкка чыга. Күрәсең, аңа тәре йөртүчеләр, сәнгать әйбере буларак түзеп тора алмаганнардыр.

Шул вакытлардан – 1750 нче еллардан соң, инде ташбилгеләрнең бизәлеше бик нык гадиләшә, декоратив тимпан бизәкләре урнына каллиграфик кыска дини фразалар яза башлыйлар.

Татар ташбилгеләре күрсәтелгән дәвердә, рухи культурабыз өчен гаять кызыклы булган борынгы уникееллык календарьны аеруча XVII гасырда әйләнешкә кайтаралар. Ташларда ***елан елы, елкы елы, сыгыр елы, ләү елы*** кебек ел исемнәре календарь функциясен үти башлыйлар. Шулай ук татарның борынгы төрки чыгышлы исемнәре аерча XVII гасыр ташбилгеләрендә арта. Истәлек ташларда эпитафик текст кысаларына сыймаган материаллар да кулланыла. Таштагы текстларга төрле тарихи топонимик мәгълүматлар да керә.

XVIII гасырның икенче яртысыннан эпитафия ясаучы ташчы осталардан Ибраһим ахун Түләки ( -1761) һәм Исхак бине Габделкәрим (1732–1802) шәхесләре күтәрелеп китәләр. Исхак хәзрәт үзе ювелир көмешче, шигырьләр-мәрсияләр язарга да маһир булып, үз дәверендә татар каберташ поэзиясен үстерә.

XVIII гасыр татар эпитафия сәнгате үсү өчен уңай чор булмый. Татарның традицион милли үзәкләре булган өлкәләрдә ташбилгеләр кую бик сирәк күренеш булып кала. XVIII гасырның икенче яртысында татарның иң зур рухи учагы буларак Каргалы (Сәгыйдь) бистәсе кала һәм ул үзенең беренчелеген әле XIX гасырның буеннан-буена саклап алып бара.

Каргалы таш кисү осталарының эшчәнлеге шулкадәр бай һәм зур ки, аны өйрәнү өчен дистә еллар кирәк булыр.

XVII гасыр ташбилгеләрен үстерүгә иң күренекле оста булып Килмөхәммәд Ишман улы мирасы беренче урынны били. Килмөхәммәднең эшләгән эшләре Лаеш ягындагы Имәнкискәдән алып Саба, Арча, Кукмара, Менделеев, Әгерҗе якларындагы авыллар зиратларында бүгенге көнгә хәтле сакланган. Безнең фаразыбыз

буенча бу оста Кукмара ягындагы Мәчкәрә авылы кешеләренең бабаларыннан берсе булган (кара «Ишман шәҗәрә»сен)[104].

XVIII гасырда кабер ташы эшләүче осталарның берсе Әлмәт төбәге Габдерахман авылында Габдерәхим исемле оста була (эше 1753 елда). Габдерәхимнең атасы Габдерахман бине Бикмөхәммәд. Габдерәхимнең улы Габдессәлам – Диния нәзарәтенең икенче мөфтие булып торган.

XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре сәнгате милләтебезнең Идел буендагы 750 елга сузылган мөселман эпитафиясе тарихында бай һәм кызыклы сәхифәләрен тәшкил иткән гүзәл чылбырының бер данлы дәверен тәшкил итә.

***Автор. 2011 ел, 4 январь.***

[104] Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1995. – Б. 111–116.

# ТАШБИЛГЕЛӘР СУРӘТЛӘРЕННӘН ҮРНӘКЛӘР

## (Сурәтләргә исемнәр)

## Беренче бүлек.

### Касыйм татарлары ташбилгеләре фотосурәтләрдә



**№ 1.** Касыйм ханы Шаһ Гали (1505–1567, 20 апрель) ташбилгесе.



**№ 2.** Габдулла солтан углы Будагали солтан (1558–1583, январь) ташбилгесе.





**№ 8.** Касыйм шәһәренең Иске Бистә зиратында сакланган Әфган хан дөрбәсенең (1649 ел) һәм ишек башына куелган эпиграфик тактаның фоторәсемнәре.



**№ 9.** Әфган хан кабере өстенә куелган таш сондыкның язулары сакланган бер стенасы, 1649 елда язылган, хәзерге көндә бик ташландык хәлдә.



**№ 10.** Әфган ханның якын туганы Түкә солтанның эпитафик сондык күренеше алгы планда.



**№ 11.** Әфган хан дөрбәсе эчендәге анын хәлале булган Алтын ханымның табуты (сондыгы), ул 1651\52 елда вафат.

# Өченче бүлек.
## Казан регионында сакланган кайбер XVII–XVIII гасыр ташбилгеләренең фотосурәтләре



**№ 7.** Лаеш төбәге, Имәнкискә авылы
Караҗ углы Туйкилде хафиз ташбилгесе.



**№ 9.** Саба төбәге, Олы Нырты авылы
Чирүче углы Килмөхәммәд ташбилгесе.



**№ 10.** Мамадыш төбәге, Дусай авылы Сонкар углы... ташбилгесе.



**№ 12.** Кукмара төбәге,
Өлги авылы Җамбакты углы Туйкә ташбилгесе.



**№ 13**. Питрәч төбәге, Тау Иле авылы
Ишбулат Акман углы ташбилгесе.



**№ 19.** Мамадыш төбәге, Олыяз Иле авылы,
Би Мөхәммәд ташбилгесе.



**№ 25.** Яшел Үзән төбәге, Норлат авылы ташбилгесе.



**№ 26.** Биектау төбәге, Сая Иле авылы
Шәйех Бәхшәндияр суфый ташбилгесе.



**№ 27.** Биектау төбәге, Өлә Казаклар авылы
Биккол бине Ибраһим ташбилгесе.



**№ 28.** Биектау төбәге, Өлә Казаклар авылы,
Ибраһим бине Әлкәй ташбилгесе.



**№ 29.** Яшел Үзән төбәге, Мулла Иле авылы
Габделхаликъ бине Габделбакый ташбилгесе.



**№ 30.** Әтнә төбәге, Югары Бәрәскә авылы.
Ибраһим бине Йосыф әл-Бәрәскә-и ташбилгесе.

# Дүртенче бүлек.

## Минзәлә регионы XVII–XVIII гасыр ташбилгеләренең фотосурәтләре



**№ 1.** Минзәлә төбәге. Бикбау авылы беренче ташбилге.



**№ 2.** Әгерҗе төбәге. Салагыш авылы «Әүлия ташы» ташбилгесе.



**№ 3.** Минзәлә төбәге, Гөлек авылы, Һиҗри 1084 елгы ташбилге.



**№ 5.** Мөслим төбәге, Катмыш авылы янындагы борынгы зират.
Нугай бәк углы Җанбай ташбилгесе.



**№ 6.** Менделеев төбәге, Турай авылы,
Турай углы Чувашай ташбилгесе.



**№ 10.** Менделеев төбәге, Турай авылы,
Байсубы углы Бибулды ташбилгесе.



**№ 12**. Алабуга төбәге, Иске Юраш ташбилгесе.



**№ 15**. Әгерже төбәге, Ырыс ташбилгесе.



**№ 17.** Мөслим төбәге, Катмыш авылы Чура Батыр углы ташбилгесе.



**№ 18.** Актаныш төбәге, Әҗәкүл авылы ташбилгесе.



**№ 19**. Минзәлә төбәге, Гөлек авылы, Сәйедгуҗа ташбилгесе.



**№ 20.** Әгерҗе төбәге, Салагыш авылы,
Котлыгуҗа углы Теләүбирде ташбилгесе.



**№ 22.** Минзәлә төбәге, Бикбау авылы,
Сөлек Бикбау углы ташбилгесе.



**№ 23.** Менделеев төбәге, Бәзәкә авылы ташбилгесе.



**№ 24.** Әгерҗе төбәге, Наҗар авылы ташбилгесе.



**№ 25.** Әгерҗе төбәге, Кодаш авылы, Балтач ташбилгесе.



**№ 26.** Менделеев төбәге Туйгуҗа авылы, Әкил ташбилгесе.



**№ 27**. Менделеев төбәге, Татар Әхтиялы ташбилгесе.



**№ 29**. Әгерҗе төбәге, Иж Бәйки авылы ташбилгесе.



**№ 34.** Әгерҗе төбәге, Көчек авылы ташбилгесе.



**№ 36.** Әлмәт төбәге, Габдерахман авылы, Габдрахман ташбилгесе.



**№ 38.** Азнакай төбәге, Митрәй авылы зиратыннан беренче ташбилге.



**№ 39.** Азнакай төбәге, Митрәй авылы зиратыннан икенче ташбилге.



**№ 41.** Әлмәт төбәге, Колшәрип авылы зираты ташбилгесе.




**№ 42.** Азнакай төбәге, Сарлы авылы ташбилгесе.



**№ 43.** Әлмәт төбәге, Клементейкино авылы ташбилгесе.



**№ 45.** Әлмәт төбәге, Камы Исмәгыйль ташбилгесе.



**№ 46.** Азнакай төбәге, Чалпы авылы иске зират ташбилгесе

# Бишенче бүлек.

## Урта Урал һәм Көнбатыш Себердәге XVII–XVIII гасырлардан калган татар ташбилгеләренең фотосурәтләре



**№ 5.** Уфа регионы. Чишмә төбәге, Йамаш углы Ардак ташбилгесе.



**№ 6**. Уфа регионы. Чишмә төбәге,
Исеркәб кызы Шийенбикә ташбилгесе.



**№ 7.** Уфа регионы. Чишмә төбәге,
Илмәмәт кызы Йүкәбикә ташбилгесе.



**№ 9.** Уфа регионы. Чишмә төбәге,
Аманкилди углы Шалтыйк бай ташбилгесе.



**№ 10.** Уфа регионы, Чишмә төбәге,
Мөхәммәдкол углы Йамаш ташбилгесе.



**№ 11.** Уфа регионы. Чишмә төбәге,
Йамаш углы Нуркай батыр ташбилгесе.



**№ 12.** Уфа регионы. Чишмә төбәге,
Котлы би углы Солтан би ташбилгесе.



**№ 13.** Чишмә станциясе янындагы зират ташбилгесе



**№ 16.** Уфа регионы. Чишмә төбәге, тамгалы ташбилге.

# Алтынчы бүлек.

## Оренбург регионындагы XVIII гасырда куелган татар ташбилгеләренең фотосурәтләре



**№ 1.** Каргалы бистәсе беренче иске зиратындагы Хәдиҗә бикә ташбилгесе.



**№ 17.** Уфа регионы. Чишмә төбәге,
Тиләкәй Акчура углы ташбилгесе.



**№ 21.** Курган регионы, Сафакүл төбәге,
Мансур бине Тукай ташбилгесе.



**№ 2а.** Каргалы бистәсе беренче иске зиратындагы Габделкәрим бине Балтай ташбилгесе.



**№ 2б.** Габделкәрим бине Балтай ташбилгесенең
икенче ягында язылган текст сурәте.



**№ 4.** Каргалы бистәсе беренче иске
зиратында Искәндәр һәм Әбүбәкер ташбилгесе.



**№ 5.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Шәйех мулла Габдеррәфыйк бине Габдулла әл-Каргалый.



**№ 6.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Гыйлемша бине Мирсәгыйди ташбилгесе.




**№ 7.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Миңлемөхәммәд Бикинҗә углы ташбилгесе.



**№ 9.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Мөхәммәдшәриф Нәзир углы ташбилгесе.



**№ 10.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Ишнияз бине Ширнияз Хавәризми ташбилгесе.



**№ 11.** Оренбург регионы. Сакмар төбәге, Үрге Чебенле авылы Бөхиббәт бинте Биктимер эн-Нократый ташбилгесе.



**№ 12.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Хөсәйенҗан бине Габделхәлим ташбилгесе.



**№ 14.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Габделмөлек бине Исмәгыйль ташбилгесе.



**№ 15.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Сәйфулла бине Хөснулла ташбилгесе.



**№ 16.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Габдулла бине Мөхәммәдшәриф ташбилгесе.



**№ 17.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Мөхәммәдсадыйк бине Мөхәммәдшәриф ташбилгесе.



**№ 19.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Әлмөхәммәд бине Габдулла Әл-Кирмани ташбилгесе.



**№ 20.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Мөхәммәдсиддыйк бине Мөхәммәдшәриф ташбилгесе.



**№ 21.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Зәйнелгабидин бине мулла Әлмөхәммәд әл-Кирмани ташбилгесе.



**№ 22.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират.
Исхак бине Габделкәрим ташбилгесе.



**№ 23.** Оренбург, Каргалы, Сакмар, Үрге Чебенле татар зиратарын өйрәнүдә зур матди ярдәм күрсәткән Искәндәровлар гаиләсе һәм бу китап авторы уңнан сулга Фирүзә, Рәшит, сулдан беренче Әнвәр Искәндәровлар. 2004 ел.



**№ 24.** Каргалы бистәсе. Беренче иске зират. Гобәйдулла бине Габдерәхим ташбилгесе. Һиҗри 1196, милади 1781/1782 ел.



**№ 25.** Оренбург губернасы Гайнәйәмәк авылы ташбилгесе
(һижри 1149, милади 1736/1731 елда куелган)

***Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы***

**XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре**

*Научное издание*

Оригинал-макет – *Р.Ф. Гатауллина*
Усл. печ. л. 16,25  Тираж 300 экз.
Подписано в печать  19.04.2011 г.

Отпечатано в множительном центре
Института истории АН РТ
Казань, Кремль, подъезд 5
Тел. (843) 292–95–68, 292–18–09